TÖREKÇÄ – TATARÇA
SÜZLEK

■

TÜRKÇE – TATARCA
SÖZLÜK

TÜRKÇE – TATARCA SÖZLÜK

20 bin civarında kelime ve ifade verilmiştir

Prof. Dr. Fuat Ganiyev'nin ve Asiye Rahimova yönetimi altında

Ahmet Veli Menger Vakfı yardımıyla basılmıştır

"İnsan" yayınevi
Kazan – Moskova
1998

TÖREKÇÄ – TATARÇA SÜZLEK

20 мең чамасы сүз һәм гыйбарәне үз эченә ала

Фәнни мөхәррирләре: Фуат Ганиев, Асия Рәхимова

**Әхмәтвәли Мәңгәр фонды
ярдәме белән бастырылды**

**"Инсан" нәшрияты
Казан – Мәскәү
1998**

ББК 81.2-4 Т 23
Т 23

Sözlüğü hazırlayanlar:

Koordinatör / Координатор: Prof. Dr. Fuat Ganiyev (Фуат Ганиев)
Redaksiyon / Фәнни мөхәррирләре: Prof. Dr. Fuat Ganiyev (Фуат Ганиев), Asiye Rahimova (Асия Рәхимова)
Yazarlar / Авторлары: Rifkat Ahmetyanov **(**Рифкать Әхмәтьянов), Rafayıl Muhammetdin (Рафаэль Мөхаммәтдинов), Fenüze Nuriyeva (Фәнүзә Нуриева), Fuat Ganiyev (Фуат Ганиев)

Т 23 Төрекчә-татарча сүзлек /турецко-татарский словарь/ **—** М.: ИНСАН, 1998. **—**560 *с.*
ISBN 5-85840-291-7

Сүзлек төрек һәм татар телләрен өйрәнергә теләгәннәр өчен төпле кулланма булып торачак, тәрҗемә эшендә дә файдалы белешмә булачак, аны сөйләшү процессында да кулланырга мөмкин. Сүзлектә 20 меңгә якын гыйбарә бар.

Sözlük Türk ve Tatar dillerini öğrenenler için esaslı öğretim aracı ve tercüme çalışmalarında da faydalı danışma kitabı olabilir, bu sözlük canlı konuşmalar süresinde de faydalanılabilir.

Словарь предназначается для желающих изучить турецкий и татарский языки, может быть использован в качестве учебного пособия и справочника, так же будет полезным при живом общении и переводе с одного языка на другой.

© Р. Әхмәтьянов.1998
© Р. Мөхәммәтдинов, 1998
© Ф. Нуриева,1998
© Ф. Ганиев. 1998

İçindekiler / Echtälek

Кереш сүз....6
Ön söz....9
Teşekkğrler / Räxmätlär....12
Сүзлекнең төзелеше....13
Кыскартылмалар исемлеге / kısaltmalar....16
Библиография....18
Төрек алфавиты....19
Татар алфавиты....20
A....21
B....51
C....83
Ç....89
D....109
E....127
F....138
G....148
H....160
I....173
İ....175
J....189
K....190
L....224
M....228
N....249
O....255
Ö....263
P....267
R....279
S....284
Ş....321
T....328
U....359
Ü....363
V....366
Y....371
Z....385

Кереш сүз

Төрекләр дип хәзерге татар телендә башлыча Төркиядә һәм аңа күрше өлкәләрдә яши торган төрки халыкны атыйлар. Электә бу төрекләрне «госманлы төрекләре» дип йөреткәннәр.

Төрек теле терки телләр семьялыгының угыз төркеменә керә. Бу төркемдәге телләрнең төп үзенчәлекләре — сүз башында кайбер авазларның, мәсәлән, гомумтөрки *к-, къ-* һәм *т*-ның еш кына *г-, гъ-* һәм *д* булып яңгыраулашуы (мәсәлән, *көн* урынына *гүн, таш* урынына *даш* дип әйтелү) һәм кайбер грамматик үзгәлекләр (мәсәлән, исем төрләнешендәге кушымчаларда — *н-* элементның булмавы; татарча *кызны* — төрекчә *кызы*). Угыз төркеменә, төрекләрдән тыш, азәрбайҗаннар, төрекмәннәр, гагаузлар һәм Иран төрекләре - кашкайлар, афшарлар һ. б. керә.

Бу халыкларның борынгы уртак бабалары V—VIII гасырларда *ун угыз, тугыз угыз* исемнәре астында хәзерге Монголиянең Көнчыгыш ягында борынгы "татарлар" белән күрше һәм бергәлектә яшәгән хәлдә искә алыналар. Ул угызларның чыгышы легендар Угыз ханга нисбәт ителә (бу турыда "Угызнамә" дигән героик дастанда сөйләнелә). X гасырда угызларның күпсанлы ишле төркемнәре Урта Азиядә, Көньяк Казакъстанда һәм Көнчыгыш Европада пәйда булалар: аларның сугышчан кавемнәре көнбатышка омтылалар. Угыз кабиләләренең Кара диңгез буйларына таба хәрәкәт иткән төркемнәре — баҗанаклар (бәҗәнәкләр, печенеглар), узлар һәм "торклар" төрле сугышларда тар-мар ителеп, ахыр чиктә кыпчак төркиләре составына керә (ул угызларның калдыкларыннан гагаузлар оешкан дип саныйлар). Угыз хәрәкәтенең көньяк юнәлеше генә уңышлы бара. Угызларның бер төркеме Сәбүктәгин җитәкчелегендә Әфганстанны яулап ала. Сәбүктәгиннең дәвамчысы Мәхмүт Газнәви — тарихта иң атаклы императорларның берсе була. Угызларның икенче зур төркеме -легендар Сәлҗук хан токымнары җитәкчелегендә Урта Азиянең Көнбатыш ягын һәм Ираннны яулап алалар. Иран буйлап таралган сәлҗукый угызларның бер төркеме тагын да Көнбатышка омтыларак, Византия чикләренә барып чыга һәм 1071-елда Византия гаскәрләрен тар-мар итеп, Көньяк Азәрбайҗанны яулап алалар (кайбер терки кабиләләр ул якларга V гасырда ук үтеп кергән була).

Күпгасырлык сәяси көрәш тәҗрибәләре булган Иран-фарсы феодаллары төркиләрне үз илләреннән кысрыклый башлыйлар. Угызларның бер өлеше Ираннан төньяк-көнчыгышка чигенеп, төрекмән халкының җәтдәләрен (бабаларын) хасыйл итә, ә көнбатышкарак киткән кабиләләр хәзерге азәрбайҗан һәм терек халыклары булып оешалар.

Хәрби оешмалары камил һәм җитәрлек дәрәҗәдә көчле булулары нәтиҗәсендә Анатолия угызлары (алар составына кайбер кыпчак кабиләләре дә кушыла) тиз арада бөтен шәрекъның диярлек хакимнәре булып әвереләләр. Бу вакытларда (XI гасырдан башлап) мөселманлыкка чыккан төрки халыкларга ислам дине яңа көч кертеп җибәрә.

Анатолия өлкәләренә бәреп кергән төрки кабиләләр башта таркау хәрәкәт итәләр. Алар еш кына үзара көрәшкә вакыт һәм көч әрәм итеп, гомуми процессны әкренәйтәләр. Ләкин XIII гасырда Анатолиядә берләштерүче көч - Госман би һәм аның варислары пәйда булып, XIV гасырда куәтле бердәм төрек дәүләте төзелә. Берничә гасыр дәвамында госманлылар Балкан ярымутравын, аннары барча гарәп илләрен диярлек яулап алалар. Нилның югары агымнарына барып чыгалар. Госманлы патшалар үзләрен барлык мөселманнарның башлыгы - хәлифә дип игълан итәләр.

Госманлы дәүләте тарихта күрелгән иң зур империяләрнең берсе була. Ләкин XVI гасырда ук госманлыларның тирән эчке зәгыйфьлекләре күренә

башлый: алар, сугышлар белән мавыгып, дәүләтнең эчке төзелешен камилләштерүгә, җитештерүчән хуҗалыкка тиешле игътибар бирмиләр һ. б. Ләкин төрекләрнең хәрби куәте әле XVIII гасыр башларында да Европа дәүләтләренең теләсә кайсыныкыннан көчлерәк була. Тик бу куәт ваклана, төрле юнәлештә хәрәкәт итә. XVIII гасыр урталарыннан башлап төрекләрнең барлык сугышлары җиңелү белән тәмамлана. Бу күңелсез "традиция" госманлы империясенең бетерелүе һәм Төркия җөмһүрияте төзелү белән генә туктала.

1920 елда атаклы "коткару сугышы" нәтиҗәсендә хәзерге чикләрендә яңа Төркия төзелә. Дәүләт башында торган Мостафа Кәмал (Ататөрек) һәм аның көрәштәшләре төрек халкына гасырлар буенча зыян китереп килгән эчке факторларны җую юлында катгый адымнар ясыйлар.

Төркиянең тәрәккыятын тоткарлап килгән факторларның берсе — язма телнең, әдәбиятның һәм укыту һәм идарә теленең халык массалары теленнән артык нык аерылуы була. Бу хәлнең тирән тарихый сәбәпләре бар.

Халыктан аерылган шушы тел госманлы теле дип аталган. Галимнәр госманлы теле үсешенең өч чорын билгелиләр. Иске госманлы теле чоры (XIII-XV гасырлар), урта госманлы теле чоры (XV-XIX гасырлар) һәм яңа госманлы теле чоры (XIX гасыр — гасырның башы).

"Иске госманлы теле" төрек дәүләтенең барлыкка килүе вакытында хасыйл була, ул угыз-сәлҗук кабиләләр телләренә барып тоташа. Бу чорда гарәп-фарсы сүзләре белән бик нык чуарланган, "югары стиль" дип аталган стиль барлыкка килә, Бу стиль тормышның барлык өлкәләрендә — дәүләт төзелешендә, фәндә, әдәбиятта, сәнгатьтә һ. б. кулланыла.

"Урта госманлы теле" Госманлы императорлыгының чәчәк атуы чорына туры килә.

"Яңа госманлы теле" XIX гасырның икенче яртысыннан алып XX гасырның башына кадәр дәвам итә. Бу чорда Төркиянең алдынгы эшлеклеләре, галимнәре халык теленнән ерак торган телгә реформа ясарга омтылыш ясыйлар, алар Европа телләренә, бигрәк тә француз теленә мөрәҗәгать итеп карыйлар. Әмма госманлы телен яңартырга тырышу уңай нәтиҗәләр бирми. Язу теле (әдәби тел) булган госманлы телен халык теленә якынайта алмыйлар. Бары Госманлы империясе җимерелгәч кенә, милли азатлык хәрәкәтенә бәйләнешле рәвештә тел өлкәсендә тирән үзгәрешләр ясарга мөмкинлек туа.

Шулай итеп, хәзерге төрек теле бик катлаулы тарихый һәм социаль лингвистик үсешнең нәтиҗәсе булып тора.

Хәзерге чорда төрек теле, үзенең табигый әсасында торгызылып, нык үсеш алган телләрнең берсен тәшкил итә, барлык функциональ стильләрдә киң кулланыла. Бүгенге көндә төрек телендә ун меңнән артык газет-журнал нәшер ителә, ел саен йөз мең исемдә китап дөнья күрә, мәсәлән, Истамбулда гына мең нәшрият эшли.

Хәзерге Төркия БДБ'нең барлык республикалары белән үзенең икътисадый, мәдәни бәйләнешләрен үстерүгә нык игътибар итә. Күпчелек республикаларда төрек лицейлары ачылды һәм ачыла, югары уку йортларында төрек бүлекләре эшли. Төркиядә чит ил төркиләреннән ун меңнәрчә яшьләр урта һәм югары уку йортларында укый.

"Шималь төрекләре" дип йөртелгән татарлар борыннан ук кардәш төрек халкы белән бәйләнештә булырга омтылганнар. Күп кенә татарлар Төркиягә китеп, икенче Ватаннарын тапканнар. XX йөз башында утыз-кырык мең татар Төркиягә күчеп китә. Яңа татар прозасына нигез салган Муса Акъегетзадә үткән гасыр азакларында Төркиягә китеп, төрек телендә икътисад һәм мәдәният тарихы буенча китаплар язган, газетлар чыгарган һәм җаваплы административ эшләрдә эшләгән. XX гасырда Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр булган Йосыф Акчура,

Садрый Максуди Арсал, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди Тоган, Акдәс Нигъмәт Курат, Абдулла Баттал Таймас, Рәшит Рәхмәти Арат, Әхмәт Тимер һ. б. төрек зыялыларының башында торганнардан саналалар: аларны XX гасырда Төркиядә эшләгән иң бөек затлар исәбенә кертәләр.

Хәзерге көндә, икътисадый һәм мәдәни бәйләнешләр кечәйган чорда тәрҗемәле сүзлекләрнең әһәмияте бик зур. Шуны истә тотып, 1997-нче елда "Татарча-төрекчә сүзлек" бастырып чыгарылды. Хәзер тәкъдим ителгән бу "Төрекчә-татарча сүзлек"тә татар һәм терек телләрен өйрәнүчеләр өчен нигезле кулланма, тәрҗемәчеләр өчен файдалы белешмә булачак. Аны җанлы сөйләшү процессында да файдаланырга мөмкин. Шуларны искә алып, сүзлектә төрек теле лексикасының барлык тармакларыннан диярлек актуаль сүзләр китерелде, һәр сүзгә грамматик характеристика бирелде, фәнни терминнарның кайсы тармакка каравы аерылып тамгалар белән күрсәтелде.

Сүзлекне төзегәндә төрек һәм татар телләренең аңлатмалы сүзлекләре, төрекчә-русча, русча-төрекчә сүзлекләр файдаланылды.

Сүзлеккә инструкцияне Фуат Ганиев төзеде.Эш авторлар арасында түбәндәгечә бүленде:

Рифкать Әхмәтьянов — A, B, C, Ç, D, E, F, G, T хәрефләре;

Фәнүзә Нуриева — I, İ, J, H, K хәрефләре;

Рафаэль Мөхәммәтдинов - L, M, N, O, Ö, P, R, S, Ş хәрефләре;

Фуат Ганиев — U, Ü, , Y, Z хәрефләре.

Сүзлеккә материал туплауда Хәлил Ачыкгөз, Асия Рәхимова катнашты.

Кереш сүзне Рифкать Әхмәтьянов белән Фуат Ганиев яздылар.

Сүзлеккә карата булган искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин: 121019, Мәскәү шәһәре, Гоголь бульвары, 6-нчы йорт, "Инсан" нәшрияты.

Ön söz

Türkler veya Türk halkı diye şimdiki Tatar dilinde öncelikle Türkiye'de ve ona komşu olan ülkelerde yaşayan Türklere derler. Eski zamanlarda bu Türklere "Osmanlı Türkleri" demişlerdir Türk dili, Türk dilleri ailesinin Oğuz grubuna dahildir. Bu gruptaki dillerin temel özelliği söz başında bulunmaktadır, meselâ, genel Türkçedeki "k", kalın "k" ve T sert sessizlerinin sık sık "g", gırtlak "g" ve "d" seslerine dönüşüp yumuşaması (örneğin, "kön" yerine "gün", "taş" yerine "daş" demesi) ve buna bazı gramer özellikleri de (meselâ, isim çekimindeki eklerde "n" harfinin olmaması; Tatarcadaki "kızını" Türkçede "kızı" olarak denilmesi) ilave edilebilir. Oğuz grubuna Türklerden hariç, Azerîler, Türkmenler, Gagauzlar ve İran Türkleri: Kaşkaylar ve Avşarlar ve saire dahildir

Bu halkların kadim ortak dedeleri V - VIII yüzyıllarda "On Oğuz", "Dokuz Oğuz" adlarıyla şimdiki Moğolistan'ın Doğu kısmında eski "Tatarlar" ile komşu olarak ve onlarla birlikte yaşamışlar diye anılırlar. O Oğuzlar aslen efsanevî Oğuz han'dan oluyor (Bunun üzerine *"Oğuzname"* adlı kahraman dastanında denilmektedir). X yüzyılda Oğuzların sayısı çok olan, kalabalık grupları Batı Türkistan'da (Orta Asya'da), Güney Kazakistan'da ve Doğu Avrupa'da peyda oldular: onların savaşkan kavimleri Batı'ya gitmeye çalışmışlardı. Oğuz kabilelerinin Karadeniz boylarına hareket etmiş grupları: Bacanaklar, Uzlar ve "Torklar", türlü savaşlarda kırılıp, nihayet, Kıpçak Türkleri bünyesine katılmışlardır (O Oğuzların döküntülerinden Gagauz halkı oluşmuş diye zannedilir). Oğuzların yayılması yalnız Güney taraflarında başarılı olmuştur. Oğuzların bir grubu Sebüktegin yönetiminde Afganstan'ı fethedip, Sebüktegin işini devam ettiren Mahmud Gaznevî, tarihte en ünlü imparatorlardan birisi olmuştur. Oğuzların diğer büyük kısmı, efsanevî Selçuk han evladları yönetiminde, Batı Türkistan'ın Batı kısmını ve İran'ı fethetmişlerdir. Hep İran topraklarına yayılmış olan SeİçukÎ Oğuzların bir kısmı daha ilerideki Batıya giderek Bizans sınırları yanına çıkmıştı ve 1071 yılında Bizans ordusunu kırıp Güney Azerbaycan'ı fethetmişlerdir (ama bazı Türk kabileleri o taraflara artık V yüzyılda sokulmuşlardır).

Asırlardan beri devam eden siyasî mücadele tecrübesi olmuş İran-Farsı derebeyleri Türkleri kendi illerinden etmeye başlamışlardır. Oğuzların bir kısmı İran'dan Kuzey-Doğu'ya çekilip, Türkmen halkının babalarını oluşturmuşlardır, ve Batı tarafına gitmiş kabileler şimdiki Azerî ve Türk halkları olarak oluşmuşlardır.

Askerî kurumlan kamil ve kâfi seviyede olmaları neticesinde Anadolu Oğuzları (onların bünyesine bazı Kıpçak kabileleri de katılmıştır) kısa sürede bütün Doğunun hâkimleri olmuşlardı, denilebilir. Bu zamanlarda (XI asırdan itibaren) müslüman olmuş Türk halklarına İslam dini yeni bir kuvvet vermiştir.

Anadolu bölgelerine baskınla girmiş Türk kabileleri önce birbirinden ayrı şekilde hareket etmişlerdir. Bu kabileler kendileri arasındaki oldukça sık savaşlar için boşuna vakit ve güç sarfederek genel süreci yavaşlatmışlardır. Ama XIII yüzyılda Anadolu'da birleştirici bir güç - Osman bey ve onun varisleri - peyda olup, XIV yüzyılda kuvvetli ve tek Türk devleti kurulmuştur. Birkaç yüzyıl zarfında Osmanlılar Balkan yarımadasını, sonra da hep Arap ülkelerini fethetmişlerdir. Nil nehrinin yukarısına kadar varmışlardır. Osmanlı padişahları kendilerini tüm müslümanların başkanı - halife olarak - ilân etmişlerdir Osmanlı devleti tarihte olmuş en büyük imparatorlukların birisidir. Ama artık XVI yüzyılda Osmanlı'ların derin iç eksiklikleri görülmeye başlanmıştır: Anadolu Türkleri savaşlara aşırı gönül vererek, diğer taraftan devletin iç yapısının mükemmelleştirilmesine ve üretim ekonomisine gereken dikkati vermemeye başladılar ve saire. Ama Türklerin askerî kuvveti, daha XVIII yüzyıl başlarında da herhangi Avrupa devletininkinden daha güçlüydü. Ama bu kuvvet gittikçe küçüldü, çeşitli istikamette hareket etti, XVIII yüzyıl ortalarından itibaren Türklerin bütün savaşları yenilme ile tamamlanmaya başladı. Bu acıklı "geleneğe" ancak Osmanlı

İmparatorluğu'nun yok olması ve Türkiye Cumhuriyetinin kurulması son vermiştir.

1920 yılında meşhur Kurtuluş Savaşı neticesinde şimdiki sınırlar içinde yeni Türkiye kurulup, devlet başında duran Mustafa Kemal Atatürk ve onun savaş arkadaşları Türk halkına asırlar boyunca ziyan getirmiş olan iç faktörleri kaldırma yolunda kati adımlar atmışlardır.

Türkiye'nin ilerlemesini geciktiren etkenlerin birisi, yazı dilinin, edebiyatın, öğretim ve yönetim dilinin halk kütleleri dilinden pek fazla ayrılmasıydı. Böyle olayın derin tarihî nedenleri vardır.

Halktan ayırılmış olan bu dil Osmanlı dili olarak adlandırılmıştır. Bilim adamları Osmanlı dili gelişiminin üç devrini belirlemektedirler. Eski Osmanlı dili devri (XIII - XV asırlar), Orta Osmanlı dili devri (XV —XIX) ve Yeni Osmanlı dili devri (XIX — XX asrın başı).

"Eski Osmanlı dili" Türk devletinin meydana gelmesi zamanında oluşmuştur, bu dil Oğuz-Selçuk kabileler dillerine inmektedir. Bu devirde dilin Arap Farsı sözleriyle aşırı karıştırılmış "yüksek tarzı" denilen bir tarzı (stili) oluşmaktaydı. Bu tarz hayatın her alanında: devlet kuruluşunda, bilimde, edebiyatta, sanatta kullanılırdı.

"Orta Osmanlı dili" Osmanlı İmparatorluğu'nun inkişaf devrine rastlıyor.

"Yeni Osmanlı dili" XIX yüzyılın ikinci yarısından itibaren XX yüzyılın başına kadar devam etmiştir. Bu devirde Türkiye'nin ilerici şahısları, bilim adamları halk dilinden ayrılmış olan dile reform yapmaya çalışmışlardır, bu alimler Avrupa dillerine, ayrıca Fransız diline yönelmeye teşebbüs ediyorlar. Ama Osmanlı diline yenileme çabaları olumlu sonuçlar vermemiştir. Yazı dili (edebî dil) olan Osmanlı dilini halk diline yakınlaştırmaya çok çalışsalar da, yakınlaştıramamışlardır. Ancak Osmanlı İmparatorluğu yıkıldıktan sonra, Millî Azatlık Hareketi dolayısiyle dil sahasında temel değişiklikler yapmaya imkânlar peyda olmuştur.

Böylece, şimdiki Türk dili, çok karışık tarihî ve sosyal lengüistik gelişimin meyvesidir.

Şimdiki zamanda Türk dili, kendi doğal temelinde geliştirilip, çok gelişmiş dillerin arasında bulunmaktadır, bu dil hep görevsel tarzlarda da geniş şekilde kullanılmaktadır. Günümüzde Türk dilinde on binden fazla gazete ve dergiler yayınlanır, ancak İstanbul'da iki bin civarında yayın evi var, Türkiye'de her yıl yüz bin isimde kitap çıkar.

Bugünkü Türkiye, Bağımsız Devletler Topluluğu'nun (BDT) bütün devletleriyle kendi ekonomik, kültürel ilişkilerini sağlamlaştırma meselesine çok dikkat ediyor Cumhuriyetlerin çoğunda Türk liseleri açıldı ve açılıyor, üniversitelerde Türk şubeleri çalışıyor. Türkiye'de dış Türklerden on bin civarında gençler lise ve üniversitelerde tahsil alıyorlar.

"Kuzey Türkleri" olarak adlandırılan Tatarlar eski zamanlardan beri kardeş Türk halkı ile ilişkide olmaya çalışmıştırlar. Oldukça çok Tatarlar Türkiye'ye gidip, ikinci vatanını bulmuşlardı. XX yüzyıl başında otuz-kırk bin Tatar Türkiye'ye geçtiler. Yeni Tatar nesir edebiyatına temel atmış Musa Akyiğitzade geçmiş asrın sonunda Türkiye'ye gidip yerleştikten sonra, Türk dilinde ekonomi ve kültür üzerine kitaplar yazmış, gazeteler çıkarmış ve sorumlu yönetim işlerinde çalışmıştır. XX yüzyılda Türkiye'ye geçmeye mecbur olan Yusuf Akçura, Sadrî Maksudî, Ayaz İshaki, Akdes Nimet Kurat, Abdullah Taymas Battal, Reşit Rahmeti Arat, Ahmet Temir ve saire, Türk aydınlarının başında duranlardan sayılırlar: bu şahısları XX yüzyılda Türkiye'de çalışmış en büyük zatlar arasına sokarlar.

Bugünkü zamanda, yani ekonomik ve kültürel ilişkiler sağlamlaştığı devirde, tercümeli sözlüklerin önemi çok büyüktür. Bunu göz önünde bulundurarak, 1997 yılında "Tatarca-Türkçe sözlük" yayımlandı. Şimdi sunulan bu "Türkçe-Tatarca sözlük" te Tatar ve Türk dillerini öğrenenler için esaslı öğretim aracı, tercümanlar için faydalı danışma kitabı olacaktır. Bu sözlükten canlı konuşmalar süresinde de faydalanmak mümkündür.

Bunları göz önünde bulundurarak, sözlüğe, Türk dili kelime hazinesinin her alanından en aktüel (en gereken) sözler sokuldu, her söze gramer nitelemesi verildi, her bilimsel terimin hangi branşa ait olduğu ayrı işaretler ile gösterildi.

Sözlük hazırlanırken Türkçe ve Tatarca anlatmalı sözlüklerden ve Türkçe-Rusça, Rusça-Türkçe sözlüklerden faydalanıldı.

Sözlüğe talimatı Fuat Ganiyev yazdı.

Sözlüğü yazma işi dilciler arasında böyle bölündü:

"A, B, C, Ç, D, E, F, G, T" harflerini - Rifkat Ahmetyanov,

"I, İ, J, H, K" harflerini — Fenüze Nuriyeva,

"L, M, N, O, Ö, P, R, S, Ş" harflerini — Rafael Muhammetdin,

"U, Ü, V, Y, Z" harflerini — Fuat Ganiyev yazdılar.

Sözlüğe materyal toplama işine Halil Açıkgöz, Asiye Rahimova katıldı.

Önsözü Rifkat Ahmetyanov ile Fuat Ganiyev yazdılar.

Sözlük üzerine olacak düşünceler ve teklifler aşağıdaki adrese gönderilebilir: Rusya, 121019, Moskova şehri, Gogol' bulvarı, ev 6, "İnsan" yayınevi.

Teşekkğrler / Räxmätlär

Bu sözlüğü yayınlamaya yardım etmiş, baba-dedeleriyle Tataristan'a bağlanmış Ahmet Veli Menger Vakfı Başkanı Safiye İmre hanıma icracılar samimî kalpten şükranlarını bildiriyorlar.

Бу сүзлекне бастырып чыгарырга ярдәм иткән, тамырлары белән Татарстанга бәйләнешле, Әхмәтвәли Мәңгәр фонды рәисе Сафия Имре ханымга авторлар ихлас күңелдән үзләренең рәхмәтләрен юллыйлар.

Сүзлекнең төзелеше

1. Сүзлектә төрек телендә төрле тармакларда киң кулланылган сүзләр, атамалар һәм тотрыклы сүзтезмәләр китерелде.
2. Сүзлек мәкаләсе түбәндәге өлешләрдән гыйбарәт:

а) тәрҗемә ителә торган баш сүздән, ул үзенең башлангыч формасында бирелде:
arda *и.* маяк...

б) сүзнең грамматик тасвирламасыннан, аның кайсы сүз төркеменә каравы күрсәтелде:
dolay *и.* әйләнә-тирә, тирә-юнь, мохит;
düzensiz *с.* 1) тәртипсез, җыйнаксыз; 2) аһәңсез; кәйсез (*музыка*);
değiştirmek *ф.* 1) үзгәртү; 2) алмаштыру, алыштыру

в) баш сүзнең төп мәгънәләренең тәрҗемәсеннән: **kabaklık** *и.* 1) өлгермәгәнлек; пешмәгәнлек (*кавын, карбыз тур.*); 2) пеләшлек; 3) *күч.* билгесезлек
kahretmek *ф.* 1) җимерү, туздыру; 2) җәзалау, интектерү; 3) каргау; рәнҗү

г) кайбер ике төрле аңлашыла торган тәрҗемәләрдән соң җәя эчендә кыскача бирелгән аңлатмадан:
mala *и.* көрәкчек, кельма (*ташчы коралы*)
Nişanci *и. астр.* Укчы (*зодиак'тагы йолдызлык исеме*)

д) турыпочмак (□) билгесеннән соң китерелгән, компонентлары аерым язылган кушма сүзләрдән, атамалардан һәм аларның тәрҗемәсеннән:
ordu *и.* 1) армия, гаскәр; *ordu merkezi* армия штабы; *sömürge ordusı* колониаль гаскәрләр; 2) *күч.* кешеләр тупламы; чирү □ ordu evi офицерлар йорты

е) ромб (◊) билгесеннән соң бирелгән аерым фразеологик берәмлекләрдән һәм мәкальләрдән:
ray *и.* рельс; *ray başlığı* тупик ◊ rayına girmek эзенә төшү, җайлану

3. Баш сүзләр һәм мәкалә эчендәге кушма сүзләр, атамалар, фразеологик берәмлекләр, шулай ук җәясез гарәп саннары ярым калын хәрефләр белән китерелде:
sabretmek *ф.* сабыр итү, түзү ◊ sabreden derviş muradına ermiş сабыр иткән морадына җиткән
safra I *и.* 1) үт; 2) үт куыгы □ safra kesesi үт куыгы ◊ safra bulanmak (kabarmak) күңел болгану
4. Мәкаләдәге барлык шартлы билгеләр (тамгалар), мисаллар һәм җәя эчендәге аңлатмалар курсив белән бирелде:
un *и.* он; *buğday unu* бодай оны; *patates unu* крахмал, бәрәңге оны
uzaklaştırmak *ф.* 1) ераклаштыру; ерагайту; 2) алу, чыгару (*эшеннән*)
5. Тәрҗемәләр гадәти (якты) туры хәрефләр белән бирелде:
üç *сан.* 1) өч; *üç saat* өч сәгать; *saat üç* сәгать өч (вакыт); 2) өч, өчле (*билге*) □ üç dilli өч телле; üç köşeli өч почмаклы ◊ üç buçuk аннан-моннан, ярым-йорты
6. Сүзләрнең, шул исәптән кушма сүзләрнең, фразеологик берәмлекләрнең аерым мәгънәләренең тәрҗемәсе җәяле гарәп саннары белән аерылды:
ezilmek *ф.* 1) изелү, онталу, ваклану; 2) сытылу; 3) *күч.* изелү, изүгә дучар

булу

alevlenmek *ф.* 1) ялкынлану; 2) *күч.* кискенләшү

7. Төрек телендәге бер сүз татар телендә ике сүз төркеме мәгънәсенә туры килгәндә, андый сүз ике сүз төркеме сүзләре белән тәрҗемә ителде:

acı 1. *с.* ачы; *acı biber* ачы борыч; 2. *и. күч.* кайгы, хәсрәт... minicik 1. *с.* нәни, кечкенә. 2. *и.* сабый, нәни бала

8. Язылышы яки яңгырашы ягыннан бердәй, әмма мәгънәләре белән төрле булган сүзләр (омонимнар), нечкә рим саннары белән билгеләнеп, аерым-аерым бирелделәр:

nefis I *и.* нәфес ◊ nefsine düşkün үз нәфесен кайгыртучы, эгоист

nefis II *с.* гүзәл, матур, нәфис

9. Исемнәр баш килеш формасында *и.* тамгасы белән бирелделәр, һәм шул ук формада тәрҗемә ителделәр:

kapan *и.* капкын, ау, тозак kedi *и.* песи, мәче

10. Сүзлектә төрек теленең фигыльләре нигез формасында китерелеп, аңардан соң сызыкча куелды һәм *ф.* тамгасы белән аның фигыль икәне күрсәтелде:

kenetlemek *ф.* ныгыту, беркетү; тоташтыру

11. Төрек фигыльләре татар теленә исем фигыль формасы белән тәрҗемә ителделәр:

ilgilenmek *ф.* кызыксыну

iliklemek *ф.* эләктерү

12. Башка сүз төркемнәренә кергән сүзләр дә сүзлектә тиешле тамгалар белән үз урыннарын алдылар. Сүз төркемнәрен күрсәткән тамгаларның аңлатмасы кыскартылмалар исемлегендә бирелде.

13. Төрек телендә еш кулланылган атамалар шулай ук сүзлектә бирелделәр. Аларның кайсы өлкәгә каравы тиешле билгеләр белән күрсәтелде:

acıçiğdem *и. бот.* эт үләне

ankebut *и. зоол.* үрмәкүч

özdek *и.* 1) *фәлс.* материя; матдә; 2) агач кәүсәсе; үсемлек сабагы

paralel *и.* 1) *геогр.* параллель; 2) параллель сызык; 3) *мат.* параллель

alarga *ы. диңг* (*сигнал сүзе*) әйләнеп үт! якынлашма!

dragon I *тар.* драгун (*атлы гаскәр*)

14. Стилистик төсмерләре булган сүзләрнең аерым тамгалар белән стилистик үзенчәлекләре күрсәтелде:

garip *с.* 1) читтә йөрүче; зимагур; 2) *сөйл.* серле, аңлашылмас

geçmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* кичү; 2) күчү, күченү; ... 10) *кит.* теркәлү; ... 14) *эвф.* үлү, кичү *кит.*

götürüm *и. сөйл.* сабырлык

15. Сүзләрнең күчмә мәгънәсе *күч.* тамгасы белән тәрҗемә ителде:

dümen *и.* 1) (*су һәм һава транспортларында*)руль; 2) *күч.* хәйлә, астан идарә итү

16. Кайбер төрек сүзләрен тәрҗемә иткәндә, татар теленең диалекталь сүзләре дә файдаланылды, андый сүз *диал.* тамгасы белән күрсәтелде:

anneanne *и.* дәү әни, нәнәй *диал.*

evirmek *ф.* 1) әверү, әверелдерү; 2) әйләндерү □ evirmek çevirmek бер урыннан икенче урынга күчерү; әверү-чәверү *диал.*

17. Төрек телендәге күпмәгънәле баш сүзгә татар телендә дә бер генә сүз туры килгәндә, барлык мәгънәләргә шул бер сүз генә эквивалент итеп бирелде:

yağ *и.* май...

18. Теге яки бу мәгънәгә аерым очракларда тәрҗемә җиңел аңлашылсын өчен мисал да китерелде:

varmak *ф.* 1) килү, килеп җитү, барып җитү; *tren Ankara'ya yedide varır*

Анкарага поезд җидедә килә; 2) җитү; *yaşı elliye vardı* яше иллегә җитте

19. Этнографиягә караган сүзләргә, экзотик атамаларга тасвирый аңлатмалар китерелде:

pabuç *и.* 1) аяк киеме; 2) урындык (өстәл) аякларына кидерелгән металл яки пластик аслык ◊ pabuç eskitmek (*бер эш артыннан*) чабата туздырып йөрү

kaçamak *и.* кукуруз оныннан пешерелгән майлы ашамлык

20. Бер мәгънә эчендә тәрҗемәдә китерелгән синонимнар өтер аша бирелделәр. Мәгънәләре белән ераграк яки ерак булган тәрҗемәләр нокталы өтер аша аерылдылар.

Кыскартылмалар исемлеге / kısaltmalar

а. - алмашлык
ав. - авиация
авыл хуҗ. - авыл хуҗалыгы
анат. - анатомия
арго. - арго, жаргон
архит. - архитектура
астр. - астрономия
биол. - биология
бот. - ботаника
бәйл. - бәйлек
геогр. - география
геол. - геология
гр. - грамматика
диал. - диалекталь сүз
дини. - дини сүз
дипл. -дипломатия
диңг. - диңгезчелек
зоол. - зоология
и. - исем
иск. - искергән (сүз)
иярт. - ияртем
к.: - кара
кер. суз. - кереш сүз
кис. - кисәкчә
кит. - китапча, китап стилендә
кулин. - кулинария
күч. - күчмә мәгънәдә
линг. - лингвистика
лог. - логика
мат. - математика
махс. - махсус термин (антропология, аучылык, бакчачылык, бактериология, биохимия, бухгалтерия, ветеринария, геодезия, гидрология, гидромеханика, кинематография, коммерция, кортчылык, метеорология, механика, минералогия, оптика, радиотехника, тимер юл, типография, топография, тукучылык эше, фармакология һ. б. өлкәләргә караган терминнар)
мин. - минералогия
мед. - медицина
мод. сүз - модаль сүз
муз. - музыка
мәгъ. - мәгънәдә
мәс. - мәсәлән
неол. - неологизм
полигр. - полиграфия
психол. - психология
рәв. - рәвеш
с. - сыйфат
сан. - сан
сир. - сирәк кулланышта
спорт. - физкультура һәм спорт
сәяси. - сәяси термин

сөйл. - сөйләү телендә
сәүдә. - сәүдә
тар. - тарихый
терк. - теркәгеч
тех. - техника термины
тур. - турында
төрле мәгъ. - төрле мәгънәдә
ф. - фигыль
физ. - физика
физиол. - физиология
фәлс. - фәлсәфә
хим. - химия
хәб. сүз. - хәбәрлек сүз
хәрби. - хәрби сүз
ы. - ымлык
шахм. - шахмат
этн. - этнология
этногр. - этнография
эвф. - эвфемизм
юр. - юридик термин
әд. - әдәбият термины
һ. б. - һәм башкалар
һ. б. ш. - һәм башка шундыйлар

Библиография

Төрек теле сүзлекләре

1. Türk Dil kurumu. Türkçe sözlük. 1. cilt, A-K, Genişletilmiş 7. baskı, Ankara, 1983, 779 sayfa.
2. Türk Dil kurumu. Türkçe sözlük. 2. cilt, L-Z, Genişletilmiş 7. baskı, Ankara, 1983, 593 sayfa.
3. İmlâ kılavuzu. Ankara, 1993, 347 sayfa.
4. Türkçe-rusça sözlük. Москва, Издательство "Русский язык", 1977, 968 бит.
5. Rusça-türkçe sözlük. Издательство "Советская энциклопедия", Москва, 1972, 1028 бит.
6. Türk Dil kurumu. Okul sözlüği. Ankara, 1994, 864 sayfa.
7. Tatarca-türkçe sözlük, Kazan-Moskova, "İnsan" yayınevi, 1997, 496 sayfa.

Татар теле сүзлекләре

8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, I том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977, 476 бит.
9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, II том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977, 725 бит.
10. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, III том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981, 852 бит.
11. Русча-татарча сүзлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, икенче басма, 1995, 464 бит.
12. Русча-татарча сүзлек. Москва, Издательство "Русский язык", 1991, 735 бит.
13. Татар теленең орфография сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1983, 280 бит.
14. Русча-татарча сүзлек. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1996, 214 бит.
15. Татарча-русча сүзлек. Мәскәү, "Советская энциклопедия" нәшрияты, 1966, 864 бит.

Төрек алфавиты

Aa	**ğ**	**Nn**	**Uu**
Bb	**Hh**	**Oo**	**Üü**
Cc	**Iı**	**Öö**	**Vv**
Çç	**İi**	**Pp**	**Yy**
Dd	**Jj**	**Rr**	**Zz**
Ee	**Kk**	**Ss**	
Ff	**Ll**	**Şş**	
Gg	**Mm**	**Tt**	

Татар алфавиты

Аа	**Зз**	**Пп**	**Чч**
Әә	**Ии**	**Рр**	**Шш**
Бб	**Йй**	**Сс**	**Щщ**
Вв	**Кк**	**Тт**	**ъ**
Гг	**Лл**	**Уу**	**Ыы**
Дд	**Мм**	**Үү**	**ь**
Ее	**Нн**	**Фф**	**Ээ**
Ёё	**ң**	**Хх**	**Юю**
Жж	**Оо**	**һh**	**Яя**
Җж	**Өө**	**Цц**	

A

aba *и.* 1) тупас калын тукыма, чикмән туласы; 2) шул тукымадан тегелгән ябынча, чикмән; 3) дәрвишләр җиләне, йон җилән; □ **aba güreşi** йон җилән киеп көрәшү; **aba terlik** бүлмә аяк киеме (*киездән*); ◊ **aba altından değnek göstermek** теле татлы, тел төбе каты; **aba gibi** тупас (*тукыма тур.*); **abayı sermek** әдәпсез [тупас, дорфа, тартынусыз] урнашу (*берәр урында*); **abayı yakmak** бик ныкгашыйк булу

abacı *и.* чикмәнче; ◊ **abacı kebeci, ara yerde sen neci?** синең биредә [монда] ни катнашы бар?;

abadî *и.* абади, ефәктән эшләнгән кәгазь төре

abajur *и.* абажур

abaküs *и.* Төркиядә кулланыла торган чут, абакус; = abak

abanmak *ф.* 1) сөялү, сөйкәлү, терәлү, таяну; 2) авышу, чүгү; 3) *арго* кеше исәбенә яшәү [тору]

abandırmak *ф.* чүктерү, яткыру ◊ **deveyi sahibi abandırır** дөяне иясе чүктерер (*әйтем*)

abanî *и.* абани (*сары чигеш белән бизәлгән ак ефәк тукыма*)

abanoz *и.* эбен (*агачы*); □ **abanoz yürekli** рәхимсез, шәфкатьсез, каты күңелле, миһербансыз, аяусыз, кансыз (*кеше*); ◊ **abanoz gibi** 1) кап-кара, чем-кара; *abanoz gibi sacı var* аның чәче чем-кара; 2) бик каты, кап-каты

abartmak (*-i*) *ф.* күпертү, арттырып күрсәтү, купайту

abaşo *с.* 1) аскы, астагы; 2) көймәне ярга бәйләү

Abaza *и.* абхаз (кешесе)

abazan *с. туп.* 1) карыны ач; 2) җенси яктан ач

abdal *и.* 1) *мар.* (гизүче) дәрвиш; 2) Афганистан'да торучы бер төрки кавемнең исеме; 3) Анадолу'да яши торган күчмә бер кавем

abdest *и.* тәһарәт, абдәст; □ aptes almak ; aptes bozulmak ; aptes tazelemek ;

abdesthâne *и.* тәһарәтханә

abdülleziz *и.* арахис, җир чикләвеге

abe *ы.* һәй, әй; *abe kardeş* әй кардәш!

abece *и.* әлифба

aberasyon *и.* аберрация

abes *с.* 1) акылга сыймас; 2) рәтсез, юньсез, кирәксез

abıhayat *и.* әбелхәят, мәңгелек суы

abıru *и.* абруй

abi *и.* абый, агай, ага

abide *и.* ядкарь, ядкарьлек; һәйкәл, мавзолей, музей һ. б.

abideleşmak *и.* ядкарьлеккә әверелү

abidevî *с.* 1) һәйкәлсыман; 2) *күч.* исәпсез күп

abis *и.* диңгезнең бик тирән җире

abla *и.* апа

ablak *с.* 1) кыяфәтсез, ямьсез; 2) зур, тупас

ablatya *и.* диңгездә балык тоту өчен зур ятьмә, трал

abli *и.* фал (*кораб арканы*)

abluka *и.* блокада

abone *и.* абунә (әбүнә)

abonman *и.* абонемент

aborda *и.* абордаж

abramak *ф.* кораб йөртү

abraş *с.* 1) алмачуар, чуар; 2) чутыр, карачутыр, шадра

abstre *с.* абстракт

abuhava *и.* һава хәле; икълим
abuk sabuk *с.* ни җитте, сантый (*сүз һ. б.*)
abuli *и.* неврастения
abullabut *с.* 1) байгыш (*кеше*); 2) өтек, зәвыксыз киенгән (*кеше*)
abur cubur *и.* 1) коры-сары (*ашамлык*); 2) әбер-чебер
abus *с.* төксе, томса; чырайсыз
acaip, **acayip** *с.* гаҗәп, гаҗәеп, сәер
acaipleş-, **acayipleşmek** *ф.* сәерләшү
acaiplik, **acayiplik** *и.* гаҗәплелек, гаҗәеплек
acar *с.* гайяр, гайрәтле; ажар, ярсулы
acele 1. *с. рәв.* ашыгыч, тиз, тәҗәл, кабаланып; 2. *и.* ашыгычлык □ **acele etmek** тәҗәлләү, сабырсызлану
aceleci *и.* кабаланучы, ашыктыручы
Acem *и. тар.* фарсы (иранлы)
acemi *с.* ирани; фарси, фарсыларга бәйләнешле
acente *и.* 1) (*эш урыны буларак*) агентлык; 2) агент
acentelik *и.* агентлык, агент булу
acep *с.* гаҗәп
acı 1. *с.* ачы; *acı biber ачы* борыч; 2. *и. күч.* кайгы, хәсрәт ◊ **acı görmüş** авырлык күргән; **acısını çıkarmak** үч алу
acımak *ф.* 1) сызлану; 2) кызгану, жәлләү
acıbadem *и.* ачы бадәм
acıbal *и.* әче бал, эчемлек бал
acıbalık *и.* кәрәкәсыман балык, ачы кәрәкә
acıçiğdem *и. бот.* эт үләне
acıkmak *ф.* ачыгу
acıklanmak *ф.* хәсрәтләнү
acıklı *с.* хәсрәтле
acılanmak *ф.* 1) ачы, ачы тәм керү; 2) борчылу
acılı *с.* 1) ачы кергән; 2) кайгылы, ачынулы
acımasız *с.* кызганусыз, аяусыз
acımasızlık *и.* аяусызлык
acımsı *с.* ачкылт, ачкылтым
acımtırak *с.* ачкылт, ачырак, ачымтырак
acınmak *ф.* ачыну
acındırmak *ф.* ачындыру
acırga *и.* керән, ачы торма
acısız *с.* авыртусыз, сызлаусыз, ачынусыз
acıtmak *ф.* ачыту
acibe *с.* гаҗәп, гаҗәп *иск.*
acil *с.* 1) кичектергесез, ашыгыч; 2) җитез, өлгер
acilen *рәв.* кичектергесез рәвештә, ашыгыч, тиз арада
aciz *и.* гаҗизлек, мескенлек; аптыраганлык
âciz *с.* гаҗиз, аптыраган, аптыраштагы; □ **âciz kalmak** гаҗиз калу
acuk *и. бот.* кыргый алмагач
acul *с.* темпераментлы; зирәк
acur *и. бот.* эре кыяр төре
acuz *и.* холыксыз (усал) карт
acuze *и.* холыксыз (усал) карчык
aç 1. *с.* ач, ачыккан. 2. *и.* ач, ярлы; юксыл, хәерче ◊ **aç ne yemez**, **tok ne demez** ач ни ашамас, тук ни сөйләмәс
açmak *ф.* 1) ачу; 2) ачыклык киңлеген арттыру; 3) мәгълүм итү, ачыклау, бәян итү;

4) ачык (җете) итү
açalya *и. бот.* азалия
açar *и.* 1) ачкыч; 2) аппетит ача торган нәрсә, аперитив
açgözlü *с.* ач күз, туймас тамак, гуҗ
açgözlülük *и.* ач күзлелек
açı *и.* 1) *мат.* почмак; 2) *күч.* караш, караш ноктасы
açıcı *и. төрле мәгъ.* ачучы ◊ **iç açıcı sözler** юатучы сүзләр
açık I *с.* 1) ачык; 2) тоткарсыз, ачык; *yol açık* юл ачык!; 3) киң, ачык; *açık ova* ачык дала; 4) киемсез, ябусыз; *başı açık* яланбаш; 5) ачык, аңлаешлы; 6) ачык, яшерен-батырын түгел □ **açık artırma** аукцион; **açık çek** *сәүд.* акча микъдары күрсәтелмәгән чек
açık *и.* 1) ачыклык, өзек; 2) ерак җир, ераклык, ара; 3) диңгез ягасы, диңгез буйлары; 4) вакант урын; 5) сальдо
açıkça *рәв.* 1) ачык рәвештә, яшермәстән; 2) *самими рәвеш*тә; *açıkça misafir etmek* ачык йөз белән кунак итү
açıkçı *и.* биржа маклеры
açıkgöz *с.* зирәк; елгыр, мут, хәйләкәр
açıkgözlük, **açıkgöziülük** *и.* зирәклек; елгырлык, мутлык
açıklamak *ф.* 1) ачыклау, аңлату; 2) белдерү; 3) төшендерү, шәрехләү
açıklayıcı 1. *с.* ачыклаучы, аңлатучы, белдерүче. 2. *и. гр.* аныклагыч
açıklık *и.* 1) ачыклык, ачык булу; ачылып калганлык; 2) мәйдан, алан; 3) өзеклек, зур аралык; ераклык; бушлык; 4) ачыклык, җетелек; *rengin açıklığı* төснең җетелеге
açıksözlü *с.* ачык сүзле
açıktan *рәв.* 1) юктан, буштан, тик торганнан; 2) ерактан, ерак арадан; 3) ачыктан-ачык (*сөйләү, әйтү*)
açtktohumlular *и. бот.* ачык орлыклылар
açılmak *ф.* 1) ачылу; 2) ачылу, эшли башлау (*мәс., университет, кибет*); 3) мәгълүм булу; 4) ераклашу
açılış *и.* 1) ачылыш, ачылу; 2) эшкә башлау
açım *и. дини.* ачык хакыйкать; үгет
açımlamak *ф.* 1) бәяләү; 2) бәян итү, *аңлату*
açış *и.* 1) ачыш, ачыпыш; кәшфият; 2) кереш; 3) башлангыч
açkı *и.* 1) ялтыраткыч; 2) утлы тишкеч (*тимерне һ. б. ш. нәрсәләрне яндырып тишү коралы*), 3) махсус ачкыч
açkılamak *ф.* чистартып ялтырату
açlık *и.* ачлык, кытлык
açma *и.* 1) ачу, ачыш; 2) ачылган җир, күтәрелгән чирәм
açmalık *и.* керкитәргеч, тапбетергеч
açmaz *и.* 1) тоткынлык, тупик; 2) кыенчылык, кыен хәл, аптыраш; 3) хәйләкәрлек, кинайә ◊ **açmaza düşmek** аптырашта, кыен хәлдә калу
açmazlık *и.* 1) аптыраш, читен хәл; 2) сер ачмау, сер саклау; 3) дәшмәкилек, тешләклек
ad *и.* 1) исем; *benim adım* минем исемем; 2) атаклылык, дан, шөһрәт; 3) *гр.* исем □ **ad çekimi** исемнең зат белән төрләнүе; **ad koymak** атау ◊ **adı batası** аты коргыры; **adını ağzına almamak** исемен дә телгә алмау (*үпкәләүдән*)
ada *и.* 1) атау, утрау; 2) юллар белән әйләндереп алынган һәм йорт, бина һ. б. төзелгән коры җир кишәрлеге □ **ada balığı** кара балык; **ada yavrusu** зур булмаган балыкчы каегы
adamak *ф.* 1) атау, тәгаенләү; 2) сәдака (*корбан һ. б.*) бирү
adak *и.* вәгъдә
adale *и.* 1) мускул; 2) сеңер, җең

adalet *и.* 1) гадәләт, гаделлек; 2) гадлия, юстиция
adaletli *с.* гадәләтле, гадел (*хөкем һ. б. ш.*)
adaletsiz *с.* гадәләтсез, гаделлексез, гаделсез
adalı *с. и.* атау (утрау) кешесе, атаулы (утраулы)
adam *и.* 1) адәм, кеше; 2) юньле кеше, ярдәм итәрдәй кеше; 3) караучы, хезмәтче; 4) хатынның ире ◊ **adam sırasına geçmek** кеше рәтенә керү; **adamına düşmek** нәкъ кешесенә тап булу
adamakıllı *с.* юньле, адәм рәтле, шактый; *adamakıllı yorulmuş* яхшы ук арыган
adamca *рәв.* 1) адәмчә, юньләп, рәтләп; 2) кеше саны җәһәтеннән, ишлелек ягыннан
adamcıl *с.* 1) илгәзәк, аралашучан; 2) кешелекле
adamcılık *и.* 1) кешелеклелек; 2) кешечәлек
adamotu *и.* женьшень (*дару үләне һәм шуның тамыры*)
adamsız *с.* 1) ярдәмчесез; 2) ирсез, тол
adanmak *ф.* аталу
adap *и.* 1) әдәп, әдәплелек, юсын; 2) кагыйдә, юрык
adaptasyon *и.* 1) яңа шартларга күнегү, адаптация; 2) текстны укучыга җиңел аңлаешлы итү
adaş *и.* адаш, исемдәш
aday *и.* 1) вәкил, делегат; 2) кандидат
adaylık *и.* 1) вәкиллек, делегатлык; 2) кандидатлык
addetmek *ф.* (*дип*) хисаплау, (*дип*) чутлау
addolunmak *ф.* хисапка керү, саналу
adem *и.* бушлык, юклык
âdem *и.* 1) Адәм галәйһи-әссәлам; 2) адәм, кеше, инсан
Âdem *дини* Адәм
Âdem alması, -nı бугаз төене
âdemoğlu *и.* адәм баласы, адәм углы
adet *и.* сан, ничәлек
âdet *и.* 1) гадәт; 2) кагыйдә, ысул, закон ◊ **âdet görmek** күрем, һәез
âdeta *рәв.* гадәттә, гадәттәгечә
adıl *и. гр.* алмашлык
adım *и.* адым ◊ **adım adım** акрын-акрын; **adım atmamak** (*бер җиргә*) аяк басмау
adımlamak *ф.* адымлау
adî *с.* 1) гади, катлаусыз; 2) *күч.* тупас, дорфа
âdil *с.* 1) гадел; 2) хаклы
âdilâne *рәв.* гадел рәвештә, гаделлек белән
adîleşmek *ф.* 1) гадиләшү; 2) *күч.* түбәнгә тәгәрәү, тупаслану
adîlik *и.* дорфалык, тупаслык
adlandırmak *ф.* исем бирү
adlı *с.* 1) исемле, атлы; *sen ne adlı* син ни атлы? исемең ничек? 2) атаклы, мәшһүр
adlî *с.* юридик; юстициягә баглы
adliye *и.* гадлия, юстиция
adliyeci *и.* гадлияче, юрист
adres *и.* адрес
adsız *с.* 1) исемсез, атсыз; 2) танылмаган, шөһрәтсез
adsızparmak *и.* атсыз бармак
aerosol *и.* аэрозоль
afacan *с.* зирәк, фәһемле, акыллы; терчә
afacanlık *и.* зирәклек, фәһемлелек; терчәлек
afakî *с.* 1) әһәмиятсез, теге-бу; 2) объектив
afallamak, **afallaşmak** *ф.* хәйран калу, аптырау

aferin *ы.* афәрин, бик шәп
aferist *и.* аферист
afet *и.* 1) афәт, авария, бәла-каза; 2) *күч.* бик гүзәл хатын-кыз (*матурлыгы илә гауга чыгарырлык*)
af(f) *и.* 1) гафу; 2) эштән бушату □ **af dilemek** гафу үтенү
affedilmek *ф.* гафу ителү
affetmek *ф.* гафу итү
affeylemek *ф.* гафу әйләү
afif *с.* 1) гафиф, гыйффәтле (егет); 2) намуслы (*ир-егет*)
afife *с.* 1) гафифә, гыйффәтле (*кыз*); 2) намуслы (*хатын-кыз*)
afiş *и.* 1) афиша; плакат, язма лозунг; 2) рәсемле игълан
afişe *и.* 1) барсын да ачып салу; 2) фаш итү
afiyet *и.* сәламәтлек, исәнлек-саулык ◊ **afiyet olsun** ашыгыз тәмле булсын; аш булсын (*ашый башлаган яисә ашап туйган кешегә әйтелә торган нәзакәт сүзе*)
aforizm *и.* афоризм
aforoz *и.* бәйләнешне (араны) өзү
afrikalı *с. и.* африкалы, африкан
afsun *и.* әфсен, сихер, тылсым
afyon *и.* әфьюн
afyonkeş *и.* әфьюн тартучы, наркоман
afyonlu *и.* 1) әфьюнлы; 2) әфьюн тартып исергән
agâh *с.* алдан хәбәрдар, алдан белеп торучы
ağ *и.* 1) ау, җылым; 2) ятьмә, челтәр; 3) тозак
ağmak *ф.* 1) һавага күтәрелү; 2) салыну, кыегаю, авышу, басып төшү
ağa *и.* 1) ага, агай; 2) абый; 3) хөрмәтле ир кеше
ağababa *и.* дәү әти; бабай, бабакай
ağabey *и.* абый
ağaç *и.* агач; *ağaç dikmek* агач утырту; **ağaç mantarı** агач гөмбәсе
ağaççık *и.* куак үсемлек
ağaçkakan *и. зоол.* тукран
ağaçlamak *ф.* 1) агачлау, агач утырту; 2) тукмау, тукмаклау
ağaçlı *с.* агачлы
ağaçlık *и.* 1) агачлык, урманлык; 2) агач (кебек) булу
ağaçsı *с.* 1) агачсыман, агачсыл; 2) агачтан эшләнгән
ağalanmak *ф.* үз-үзеңне зур тоту, шәпләнү, минсенү
ağalık *и.* 1) агалык, ага булу; 2) юмартлык, киң күңеллелек; 3) салмаклылык, сабырлык, олпатлык
ağarmak *ф.* 1) агару; 2) таң ату, яктыра башлау
ağarık *с.* агарган, төсе уңган
ağda *и.* куе ширбәт (*лимон яисә йөзем суыннан*)
ağdalaşmak *ф.* куеру, куерыклану
ağdalı *с.* 1) куерык массалы; 2) *күч.* катлаулы (*мәс., стиль*)
ağı *и.* агу, зәһәр
ağıl *и.* 1) кәртә, кутан (*киртәләнеп алынган туплавык, утар*); 2) ай яисә кайбер яктырак йолдызлар тирәли пәйдә була торган якты алка
ağılmak, **ağınmak** *ф.* күтәрелү
ağılamak *ф.* агулау
ağılı *с.* агулы, зәһәрле
ağıllanmak *ф.* кәртәләнү, каймалану
ağım *и.* күтәрелеш (*дәрәҗәсе*)
ağımlı *с.* (*биек*) күтәрелешле

ağınmak *ф.* аунау (*хайваннар тур.*)
ağır *с.* 1) авыр; 2) *күч,* кыйммәтле, бәяле
ağırayak *с.* авыраяк (*йөкле хатын*)
ağırbaşlı *с.* 1) салмак хәрәкәтле; 2) олпат; вәкарьле
ağırlamak *ф.* хөрмәтләү, хөрмәт итү
ağırlanmak *ф.* хөрмәт ителү
ağırlaşmak *ф.* 1) авырлашу; 2) холыксызлану; 3) тудыруга якынлашу
ağırlık *и.* 1) авырлык, саллылык, салмаклык; 2) авырлык, йөк, җаваплылык; 3) кыенлык
ağış *и.* югары күтәрелеш
ağıt *и.* 1) елау-сыктау, елаш; 2) мәрсия, элегия
ağız I *и.* авыз; 2) тишек, өн; 3) юлның h. б. башланган төше;4) чат, юлсабыш; 5) сөйләшү, сөйләү рәвеше; 6) балта, пычак йөзе; 7) *лингв.* сөйләш ◊ **ağzından çıkanı kulağı işitmez** авызыннан чыкканны колагы ишетми; **ağzına bakmak** авызына гына карап тору, һәр әйткәненә игътибар итү, һәр кушканын үтәү; **ağzı kulaklarına varmak** бик сөенү; **ağzından girip burnundan çıkmak** бөтен эч серләрен алу; **ağzından bal akmak** матур (татлы) сүзләр сөйләп тору; **ağzı gevşek** сер тотмас, сер сакламаучан
ağız II *и.* угыз сөте
ağızbirliği *и.* бер сүздә булу
ağızlık *и.* 1) имезлек; 2) тынлы музыка әсбапларының (тәмәке трубкасының) авызга кабыла торган өлеше; 3) телефон трубкасының авызга якын ягы; микрофон; 4) авызлык (*йөгәндә һ. б.ш.*)
ağızsız *с.* юаш, карусыз; тел кайтармый торган
ağızünlüsü *и. гр.* ирен сузыгы
ağlamak *ф.* 1) елау, аглау *иск.*; 2) шикаять итү, жалу итү, үзен кызгандыру
ağlamaklı *с.* еламсыраулы, еламсыраган, еларга җитешкән □ **ağlamaklı olmak** елардай булу
ağlamsamak *ф.* еламсырау
ağlamsık *с.* 1) елаган булып күренүче; 2) елавык
ağlaşmak *ф.* елашу, зарлану, сыкрану
ağlatmak *ф.* елату
ağrı *и.* авыру, авырту, чир, хасталык
ağrımak *ф.* авыру, хасталану, чирләү, сырхаулау
ağrık *и.* конкрет хасталык, чир
ağrıklı *с.* сырхау, сызлаулы, авыртулы, авырткан
ağrılı *с.* авыру, хаста, чирле
ağrıtmak *ф.* 1) авырттыру; 2) авыруга сабыштыру
ağsı *с.* аусыман, тозаксыман
ağustos *и.* август
ah *ы.* ah, ах □ **ah çekmek ah** итү, авыр сулау
aha *а.* әнә, әнә теге
ahali *и.* халык (*билгеле бер урында, өлкәдә яшәүчеләр*)
ahbap *и.* 1) сердәш, дус, ахир; 2) таныш-белеш, дус-иш, әхбаб *иск.*
ahbapça *рәв.* дусларча дустанә; тәкәллефсез
ahbaplık *и.* дуслык, дустанәлек, тәкәллефсезлек
ahçı *и.* ашчы, пешекче
ahçıbaşı *и.* баш пешекче, баш ашчы
ahd *и.* 1) килешү; шартнамә; 2) рәсми вәгъдә; 3) ант, әхет *иск.*
Ahdiatik *и. дини* (Иске) Тәүрат
Ahdicedit, -di *и. дини* Гайса пәйгамбәр китабы, Инжил (*русчасы - Новый завет*)
ahenk *и.* 1) ярашу, ярашканлык, гармония; 2) аһәң, аккорд

ahenkleştirmek *ф.* үзара яраштыру, гармониягә китерү
ahenkli *с.* 1) бер-беренә ярашкан, җайлашкан; 2) аһәңле
ahenksiz *с.* 1) бер-беренә җайлашмаган; 2) аһәңсез
aheste *с.* 1) әкрен, акрын; 2) ипләп, тыныч кына, кабаланмыйча; 3) юаш кына, карулашмастан; 4) түбән, кычкырышсыз, әкрен (*аваз, тавыш һ. б. ш.*)
ahi *и.* 1) ир кардәш, ир туган; брадәр; агай-эне; 2) *тар.* һөнәрчеләр берлегенең әгъзасы
ahir 1. *с.* ахыргы, азаккы. 2. *рәв.* ахырда, соң, соңыннан
ahiren *рәв.* соңгы вакытта, соңгы көннәрдә
ahitname *и.* шартнамә, вәгъдәләшү документы
ahkâm *и.* хөкемнәр, законнар
ahlâk *и.* 1) әхлак, мораль; 2) холык, кыланыш □ **ahlâk bilimi** әхлак белеме, этика
ahlâkçı *и.* әхлакчы, моралист
ahlâkdışı *с.* әхлактан тыш, әдәп-хая киртәсенә кермәгән
ahlâkî *с.* әхлакый, әхлакка караган
ahlâklı *с.* әхлакны
ahlâklılık *и.* әхлаклылык
ahlâksız *с.* әхлаксыз
ahlâksızlık *и.* әхлаксызлык
atılamak *ф.* аһылдау
ahlat *и.* 1) кыргый үскән җимеш агачы; 2) *арго.* бик тупас, мәдәниятсез кеше
ahmak *и.* ахмак, акылсыз; юньсез, рәтсез
ahmakça *рәв.* ахмакларча
ahret *и.* ахирәт ◊ **ahret yolculuğu** үлем
ahşap *и.* 1) һәртөрле агач; 2) агач өй, агач корылма
ahu *и.* 1) җәйран, коралай (*мөгезле бер кечерәк киек*); 2) матур күзле хатын-кыз
ahu dudu *и.* кура җиләге
ahur *и.* ат абзары
ahval *и.* әхвәл, хәлләр
ahzetmak *ф.* үзенә кабул итү, үзенә алу
aidat *и.* 1) керем, табыш; аслам; 2) кертем, кушар, взнос
aile *и.* 1) гаилә; 2) өер, җәвер; зат, ыру; 3) семьялык (*биол. һәм лингв.*)
ait *бәйл.* бәйле, баглы, караган; гаид *иск.*
ajan *и.* 1) агент; 2) агентура; шпион, шымчы; 2) вәкил
ajans *и.* 1) агентура; 2) эше махсус бинага һәм бер урында эшләүгә багланмаган орган (оешма); 3) агентлык, хәбәр җыючы һәм хәбәр таратучы орган; 4) яңалыклар
ajur 1. *с.* челтәрле, ажур. 2. *и.* челтәр, ажур бизәк
ak 1. *с.* 1) ак; 2) саф, пакь. 2. *и.* ак; ак тап ◊ **ak koyunun kara kuzusu da olur** аттан ала да туа, кола да туа
akm**a**k *ф.* агу; *sular akıyor* сулар ага; *kova akıyor* чиләк ага (*тишелгән*) ◊ **akan sular durmak** дөрес сүзгә җавап юк
akabe *и.* 1) кыя, биек текәлек; 2) биек текә тау; 3) *күч.* алда торган кыенлык
akabinde *бәйл. рәв.* соңыннан, соңында; шуннан соң, шуннан ары
akademi *и.* 1) академия (*югары гыйльми тәшкиләт, югары хәрби уку йорты*); 2) ялангач кеше сурәте
akademici *и.* 1) академияче; 2) ялангач кеше рәсемен ясаучы
akademik *и.* академик
akait *и.* гакаит (*диннең рәсми кагыйдәләрен өйрәтү*)
akak *и.* сыеклык вә газ агызгыч (*торба һ. б.*)
akala *и.* 1) Төркиядә яңа модаларның бер төре; 2) мамык сорты
akamet *и.* 1) кысырлык; 2) файдасызлык, файдасыз эш

akanyıldız *и.* сәйяр йолдыз
akar 1. *с.* 1) агар, агып торган; 2) сыек, 2. *и. күч.* мал-мөлкәт (*арендага бирелеп, табыш китерә ала торган*)
akarca *и.* 1) йогышлы чир; 2) чуан
akarsu *и.* агар су, агымсу
akaryakıt *и.* сыек ягулык
akasma *и.* үрмә гөл
akasya *и.* акация (*агачы*)
akbaba *и. зоол.* 1) бөркетсыман кош; тазкара; 2) *күч.* бик картайган кеше
akbabagiller *и. зоол.* тазкарасыманнар
akbaş *и. зоол.* диңгез казы **akbaşak** *и. бот.* көзге бодай **akbez** *и.* акбәз, буялмаган мамык тукыма **akciğer** *и. анат.* үпкә **akciğerliler** *и. зоол.* үпкәле хайваннар
akça *с.* аксыл
akçaağaç *и.* каен
akçe *и.* 1) металл акча; 2) көмеш тәңкә
akçıl *с.* төсе уңган, төссезләнгән
akçıllarımak *ф.* төссезләнү
akıbet *и.* азак, ахыр; нәтиҗә; гакыйбәт *иск.*
akıcı *с.* 1) агучан, ага торган, сыек; 2) тыелгысыз агучы; 3) агымдагы
akıl *и.* 1) акыл; 2) хәтер, аң; *adı aklımda kalmadı* исеме хәтеремдә калмады; 3) үгет □ **akıl danışmak** киңәшү ◊ **akılı evvel** акыл белән эш итүче; **akılımda**! исемдә! (*ядәч уенында*)
akılcı *и.* рационалист
akıldışı *с.* акылга сыймаслык
akıldışı *и.* акыл теше
akıllanmak *ф.* 1) акыл белән эшләү; 2) акылга утырту
akıllı *с.* акыллы
akılsız *с.* акылсыз
akım *и.* агым
akın *и.* 1) көчле агым, массалы хәрәкәт; 2) кысрыклау; фронталь һөҗүм
akıncı *и.* кысрыклаучы, басым ясаучы
akıntı *и.* 1) агынты, агым; 2) аккан әрен; кан-сүл; 3) агым; 4) агыш
akış *и.* 1) агыш, агу рәвеше; 2) барыш, хәрәкәт; агым
akıtmak *ф.* агызу
akıtma *и.* 1) кашка (*атта һ. б. хайванда*); 2) татлы камыр ризыгы; 3) киң беләзек
akıtmalı *с.* кашкасы булган
âkibet *и.* ахыр, нәтиҗә, гакыйбәт *иск.*
akide I *и.* 1) ышану, ышаныч; инану, инаныч; 2) принцип
akide II *и.* тиз эреми торган (суыра торган) конфет; леденец
akik *с.* ахак, гакыйк *иск.*
akim *с.* 1) кысыр; 2) нәтиҗәсез, мәгънәсез
akis *и.* 1) рефлекс; 2) чагылыш; 3) яңгыравык, кайтаваз
akit *и.* 1) килешү, контракт; 2) никяхлашу
akkuyruk *и.* гади чәйгә кушыла торган ак төсле тәмләткеч үсемлек; ак чәй
akmantar *и.* ак гөмбә
akordeyon *и.* аккордеон
akort *и.* аккорд
akraba *и.* кардәш-ыру, нәселыру, туган-тумача
akrabalık *и.* кардәш-ырулык, туган-тумачалык
akrep *и.* 1) *зоол.* чаян; 2) сәгать нәйзәсе (угы)
aksamak *ф.* 1) аксау; 2) *күч.* кимчелекләр булу, артта калу; 3) *күч.* начар эшләү (*механизм тур.*)

aksakal *с.* аксакал, хөрмәтле вә белдекле олпат карт
aksaklık *и.* аксаклык
aksatmak *ф.* аксату
aksedir *и.* ак кедр, тис агачы
aksesuar *и.* 1) запас детальләр җыемы; 2) кино һәм театр эчендә вак-төяк кирәк-ярак, аксессуар; 3) хатын-кызның бизәнү әйбере
aksetmek *ф.* 1) яңгырап кайту; 2) чагылу, чагылдыру; чагылып күренү; 3) таралу (*мәс., хәбәр*), барып җитү; 4) кире кайтып кабатлану
aksettirmek *ф.* 1) чагылдыру; 2) кире кайтару, яңгырату; 3) җәелдерү, таралдыру, киңәйтү (*мәс., хәрәкәтне*)
aksırmak *ф.* төчкерү
aksırık *и.* төчкерек
aksi *с.* 1) каршы, карулы; *aksi cevap* карулы җавап; 2) кире, тискәре, холыксыз; *aksi insan* кире (холыксыз) кеше
aksilerimek *ф.* киреләү, киреләнү
aksilik *и.* 1) кирегә китү, регресс; 2) кирелек, тискәрелек
aksine *рәв.* кире юнәлештә, кирегә, киресенә
aksiseda *и.* яңгыравык, кайтаваз
aksu *и.* күзгә ак төшү чире
akşam *и.* 1) кич, кичке вакыт; 2) ахшам, кояш баегач бер сәгать дәвамындагы вакыт; **akşam yemeği** кичке аш ◊ **akşamdan sonra merhaba** өч көн үткәч, исәнме, кодагый
akşamki *с.* кичке
akşamlamak *ф.* 1) кичкә, калу; 2) кичегү, соңару; 3) соң туу (*ай тур.*)
akşamleyin *ф.* кичкырын, кичләтеп; кичкә калып
akşamlı sabahlı *рәв,* иртәле-кичле
akşamyıldızı, akşam yıldızı *и.* Зөһрә йолдызы
akşın *и.* 1) аксыл, якты (*төс*); 2) ак пышлак, ак тәнле, ак йонлы, чәче, төге ак (*кеше һәм хайваннар тур.*)
aktar *и.* вак-төяк сатучы (*кеше яисә кибет*)
aktarmak *ф.* 1) аудару, бушату; 2) күпләп ташу, күчерү; 3) күздән кичерү; 4) *күч,* чит телдән сүз алу; 5) *күч.* алмаштыру; 6) тәрҗемә итү
aktarmalı *с.* күчеп утырулы; *aktarmalı tren bileti* бераздан икенче поездга күчеп утырып юлны дәвам иттерә торган билет
aktarmasız *с.* күчеп утырырга кирәк булмаган; *aktarmasız uçak* турыдан-туры очучы самолет
aktif *с.* актив, тырыш
aktör *и.* актер
ak töre *и.* яхшы сыйфат, һәйбәт гадәт
aktris *и.* актриса
aktüalite *и.* 1) көндәлек вакыйгалар, хәл-әхвәл; 2) актуальлек; 3) көнүзәк мәсьәләләрне яктырткан кечкенә агитацион фильм
aktüel *с.* 1) актуаль, көнүзәк; 2) гамәлгә ярашлы
akustik *и.* акустика
akü *и.* машина аккумуляторы
akömülator *и.* аккумулятор
babayiğit *и.* 1) батыр, баһадир, пәһлеван; 2) ышанычлы (кыю) егет
Babıâli *и. тар.* Госманлы чорында иң мөһим министрлыклар урнашкан бина, Госманлы дәүләтенең символы (*урысча Высокая порта диелгән*)
baca *и.* моржа (мөржә); төтен торбасы
bacak *и.* аяк (*барлык өлешләре: сыйрак, бот һ. б. берлектә*)
bacaklı *с.* озын ботлы, озын аяклы
bacaksız *с.* 1) кыска ботлы, кыска аяклы; 2) *күч.* өлкәннәр сүзенә тыгылучан (*бала*)
bacanak *и.* бажа (бажай)
bacı *и.* 1) кыз кардәш (*апа яки сеңел*); 2) карендәш (*хатын-кызга эндәшү сүзе*)
baç *и. тар.* баж (пошлина)
badana *и.* акшар, акшарлы буяу
badanacı *и.* акшарчы, буяучы; сылаучы, маляр
badanalamak *ф.* акшарлау
badanalı *с.* акшарлы, акшарланган
badanasız *с.* акшарсыз
badas *и.* ындыр чүбе
badat *и. бот.* потат, җир алмасы
badem *и. бот.* бадәм, миндаль; **badem içi** бадәм төше
bademcik *и. анат.* тамак миндале, миндаль биз
bademezmesi *и.* бадәм кәнфите
bademlik *и.* бадәмлек, бадәм агачлары күпләп үскән урын
bademyağı *и.* бадәм мае
baderna *и. диңг.* арканның ашала торган җиренә кидерелә торган җиңсә
badi *и. сөйл.* үрдәк □ **badi badi yürümek** алпан-тилпән атлап йөрү
badıç *и.* кузак, борчак кузагы **badik** *и.* 1) бераз үскән үрдәк яисә каз бәбкәсе; 2) *күч.* кыска аяклы кеше
badire *и.* бәла-каза, афәт
badya *и.* бадья, кое чиләге; зур бидрә
bagaj *и.* багаж
bağ I *и.* 1) киндерә, бау, тасма; 2) бәйләм, төргәк; 3) багланыш, элемтә
bağ *и.* баг, агач бакчасы
bağbozumu *и.* 1) йөзем җыю; 2) җиләк-җимеш җыю вакыты, көз
bağcı *и.* 1) бакчачы; 2) йөземче
bağcık *и.* кечкенә бакча
bağcılık *и.* бакчачылык

bağdaş *и.* 1) нәрсәне дә булса бәйләү өчен чалыштырылган бау; 2) аякларны чалыштырып утыру; □ **bağdaş kurmak** аякларны чалыштырып утыру
bağdaşmak *ф.* багдашлау *иск.,* аякларны чалыштырып утыру (*төрекчә утыру*)
bağdaşık *с.* вәгъдәләшкән, килешкән; килешенгән
bağdoku *и. бот., зоол.* тоташтыргыч тукыма
bağfiil *и. гр.* хәл фигыль
bağım *и.* бәйле булу, баглы булу
bağımlı *с.* бәйле, баглы, буйсынулы
bağımlılık *и.* бәйлелек, баглылык, буйсынганлык
bağımsız *с.* бәйсез, мөстәкыйль, беркемгә дә буйсынмаган
bağımsızlaşmak *ф.* бәйсез булып китү, мөстәкыйльләшү
bağımsızlık *и.* бәйсезлек □ **bağımsızlık savaşı** Төркиянең 1919-1923 еллардагы милли азатлык өчен сугышы
bağıntı *и.* 1) үзара мөнәсәбәт (мөнәсәбәтләр); 2) *фәл.* багланыш; баглылык, бәйлелек; 3) *мат.* нисбәт, пропорция
bağıntılı *с. фәл.* мөнәсәбәтле, багланышлы; бәйләнешле
bağır *и.* 1) гәүдәнең күкрәк өлеше; 2) *анат.* үпкә-бавыр
bağırmak *ф.* кычкыру, бакыру, акыру
bağırsak *и.* 1) эчәк; 2) эчәге, эчәк-бавыр
bağırtmak *ф.* кычкырту, бакырту, акырту
bağış *и.* 1) бүләк, һәдия; 2) гафу, ярлыкау; амнистия
bağışıklık *и.* 1) *мед.* иммунитет; 2) ташлама
bağışlamak *ф.* 1) гафу итү, амнистия ясау; 2) багышлау
bağışlayış *и.* 1) багышлау; 2) гафу; амнистия
bağlamak *ф.* 1) бәйләү; 2) баглау, үзара багланышка кертү
bağlaç *и. гр.* теркәгеч
bağlaçlı *с. гр.* теркәгечле
bağlam *и.* 1) бәйләвеч; 2) бәйләм, төргәк
bağlanmak *ф.* 1) бәйләнү (*мәс., чәчәкләр бәйләме*); 2) багыну, бик нык ярату; 3) билгеләнү (*мәс., пенсия*)
bağlanış *и.* багланыш
bağlantı *и.* бәйләнеш, багланыш
bağlı *с.* бәйле, баглы; бәйләнешле
bağlılık *и.* бәйлелек, баглылык
bağnaz *и.* фанатик; фанат
bağrışmak, **bağırışmak** *ф.* кычкырышу, бакырышу
bahadır *и.* баһадир, батыр
bahaîlik *и.* баһаилек, баһавилек (*дини бер юнәлеш, хәрәкәт*)
bahane *и.* сылтау, бәһанә *иск.*
bahar I *и.* 1) яз фасылы; яңгырлар чоры; 2) күтәрелеш, җанланыш □ **ilk bahar** яз, язгы вакыт; **son bahar** көз, көзге вакыт
bahar II *и.* тәм-том, тәмләткеч
baharat *и. күлин.* тәм-том, тәмләткечләр
baharatçı *и.* тәм-томчы, тәм-
ләткеч сатучы
bahariye *и.* язгы ямьнәрне мактау шигырьләре, язга багышланган шигърият
baharlı *с.* тәмләткечле
bahçe *и.* 1) яшелчә бакчасы; 2) җиләк-җимеш бакчасы
bahçeci *и.* яшелчәче; бакчачы
bahçıvan *и.* бакчачылык (яшелчәчелек) белән шөгыльләнүче
bahis *и.* 1) сүз темасы; 2) бәхәс, сөйләшү; □ **bahse tutuşmak** бәхәсләшү
bahriye *и.* диңгез хәрби көчләре (флоты)

bahriyeli *и.* 1) диңгез хәрби флотында хезмәт итүче; 2) диңгез хәрби укулыгында (*училищесендә*) укучы
bahsetmek *ф.* сүз алып бару, сөйләү
bahşiş *и.* бәхшиш, чәйлек (*акча*)
baht *и.* язмыш, өлеш; бәхет
bahtiyar *с.* бәхетле, бәхтияр *иск.*
bakmak *ф.* 1) *төрле мәгъ.* багу, карау; 2) *сөйл.* билгеле бер факторга (сәбәпкә, сәбәпчегә) баглы булу; 3) *сөйл.* охшау, охшаш булу; **bak** кара, бакчи, бакмый; **bakalım** карыйк (*ни бар*), күрик; карарбыз, күрербез; **bakarak** (*кемгә, нәрсәгә*) карап; **baksana**! **baksanıza**! баксана! (*гаҗәпләнеп игътибар итү ымлыгы*)
bakakalmak *ф.* аптырашта калу
bakan *и. с.* 1) караучы, багучы; 2) министр; **bakanlar kurulu** министрлар советы
bakanlık *и.* 1) министрлык; 2) министр булу
bakar kör *с.* 1) күзе сукыр; 2) *күч.* дикъкатьсез
bakıcı *и.* 1) күзәтүче, күзәтче; 2) авыру багучы; 3) фал ачучы, багучы
bakım *и.* 1) карау, багу, тәрбияләү; 2) караш
bakımevi *и.* ятимнәр йорты; приют; ятимханә
bakımlı *с. карауны, багымны,* тәрбияле
bakımsız *с.* караусыз, багусыз; тәрбиядән мәхрүм
bakımsızlık *и.* караусызлык; тәрбиядән мәхрүмлек
bakım yurdu *и.* картлар йорты
bakınmak *ф.* карану
bakır *и. с.* бакыр □ **bakır çalığı** яшел-зәңгәр төс
bakırcı *и.* бакырчы
bakırlaşmak *ф.* бакыр төсенә керү
bakırrengi *с.* бакыр төсеңдәге, бакыр (*төс атамасы буларак*)
bakırtaşı *и.* малахит
bakış *и.* карау, караш, багыш
bakışmak *ф.* карашу, багышу
bakir *и.* җенси мөнәсәбәткә кермәгән егет
bakire *и.* гыйффәтле кыз
bakirelik *и.* гыйффәтлек, кызлык
bakkal *и.* 1) бакалея кибете; 2) бакалейчы, бакалеяче
bakkaliye *и.* бакалея товарлары; бакалея кибете
bakla I *и.* бөжра, чылбырны хасил иткән алкаларның берсе
bakla *и. бот.* 1) ногыт (ногыт борчагы); 2) борчак □ **bakla dökmek** (**atmak**) ногыт салу, ногыт салып күрәзәләү; **baklayı ağzından çıkarmak** сөйләми торганнан соң сөйли башлау
baklaçiçeği *и. с.* аклы-сарылы; аксыл сары
baklagiller *и. бот.* ногытсыманнар; борчаклылар (кузаклылар)
baklava *и.* пәһләвә (пәхләвә)
baklavacı *и.* пәһләвәче (пәхләвәче)
bakraç *и.* бакыр чиләк
bakteri *и. биол.* бактерия
bakteridi *и.* бактерия спорасы
bakteriyoloji *и.* бактериология
baktırmak *ф.* карату, бактыру
bal *и.* бал □ **bal başı** иң чиста бал ◊ **bal ayı** бал ае (*өйләнешкәннәрнең туйдан соң беренче ае*); **bal dudak** бал авыз (татлы телле)
bala *и. сөйл.* бала **balaban** I *и. зоол.* балабан (*эре кыргый лачын*)
balaban II *с. сөйл.* зур гәүдәле, дәү; симез

balabankuşu *и. зоол.* (*балабаннарга җим була торган*) үрдәксыман кош
balabanlarımak *ф.* гәүдәгә зураю
balabanlık *и.* гәүдәгә зурлык
balalayka *и.* балалайка
balast *и. төрле мәгъ.* балласт
balata *и.* шкив
balcı *и.* балчы, умартачы
balçık *и.* балчык
balçıklı *с.* балчыклы
baldır *и.* балтыр
baldırak *и.* балтырак (*балакның аскы өлеше*)
baldıran *и.* агулы балтырган
baldız *и.* балдыз
bale *и.* балет
balerin *и.* балерина
balet *и.* балетта биюче ир-егет
balgam *и.* какрык, бәлгам *иск.*
balgamlı *с.* какрыклы, бәлгамлы
balık *и.* балык □ **balık nefesi** спермацет, китлардан алынган хуш исле май; **balık tabağı** киң һәм сай тәлинкә; **balık yumurtası** уылдык; **balığa çıkmak** балыкка чыгу; балык ауларга диңгезгә чыгу ◊ **balık baştan kokar** балык башыннан чери; **balık etinde** бик таман көрлектә (*арык та түгел, симез дә түгел, күбесенчә кеше турында*); **balık istifi** шыгрым тулы (*кеше бик күп урын*); **balık kavağa çıkınca** кызыл кар яугач
balıkadam *и.* водолаз
balıkçı *и.* балыкчы
balıkçıl *и. зоол.* челән
balıkçılgiller *и. зоол.* челәнсыманнар
balıkçın *и. зоол.* диңгез карлыгачы
balıkgözü *и.* киндерә үткәзеп йөртер өчен күн яки тукымага тишелгән тишекне читләп торган божра, күз чите
balıkkaıtalı *и. зоол.* диңгез бөркете
balıklamak *ф.* вышкадан суга сикерү
balıklama *и.* (*балык кебек*) суга сикерү төре
balıklava, **balıklağa** *и.* (*диңгездә*) балык яткылы
balıksırtı *и.* 1) чигүле бизәк төре; 2) шоссеның уртадан кабарып торуы
balıkyağı *и.* балык мае
baliğ *с.* балигъ □ **baliğ olmak** балигъ булу
balina *и.* 1) кит (*диңгез хайваны*) ; 2) китның сөзгеч тешеннән ясалган киргеч (*кием өчен*)
balinalı *с.* киергеле (*кием*)
balistik *и.* баллистика
balkabağı *и.* 1) *бот.* татлы кабак төре; 2) *күч.* хуш күңелле, әмма зиһенсез кеше
balkan *и.* текә сыртлы урманлы тау
balkanlı *и. с.* Балкан илләреннән килгән *кеше*; балканлы
balkar *и.* балкар (*халкы һәм кешесе*)
balkarca 1. *и.* балкар теле; 2. *рәв.* балкарча, балкар телендә
balkı *с.* бизәкле; балкулы
balkımak *ф.* 1) балку; 2) яшен яшьнәү; 3) дулкынлану, алкалану (*су*); 4) чәнчеп авырту
balkon *и.* балкон
balköpüğü *и. с.* ачык сары (*төс*)

ballanmak *ф.* баллану
ballandırmak *ф. төрле мәгъ.* балландыру
ballı *с. төрле мәгъ.* баллы, татлы
ballıbaba *и. бот.* баллы баба (*чәчәкле чүп үлән*)
ballık *и.* 1) бал савыты; 2) чәчәк серкәсеннән авыру, серкә аллергиясе
balmumu *и.* балавыз; **balmumu gibi erimek** балавыз кебек эрү (*бик тиз хәлсезләнү*)
balo *и.* бал, биюле кичә
balon *и.* 1) *төрле мәгъ.* баллон; 2) һава шары ◊ **balon uçurmak** куык очыру
bal özü *и.* нектар
balrengi *и.* бал төсе
balsıra *и.* баллы чык, яфрак балы
balta *и.* балта ◊ **balta değmemiş** (**girmemiş**) балта тимәгән (кермәгән) (*кыргый урман тур.*)
baltacı *и.* 1) балта ясаучы яисә сатучы; 2) утын кисүче; 3) янгын сүндерүче (*балта белән эш итүче*); 4) *тар.* балтачы, сарай балтачысы
baltalamak *ф.* берәр эшне махсус бозу, саботаж ясау
baltalama *и.* бозу эшчәнлеге; саботаж
baltalayıcı *и.* саботажчы
baltalık *и. с.* кисентелек (*киселәчәк урман кишәре*)
balya *и.* тюк, кип, зур төргәк; шыр *иск.*
balyalamak *ф.* тюклау, төргәкләү
balyos *и. тар.* Франция яисә Венеция илчесе
balyoz *и.* ташваткыч зур чүкеч
balyozlamak *ф.* зур чүкеч белән таш вату
bambaşka *с.* бөтенләй башка, бам-башка
bambu *и. бот.* бамбук
bambul *и. зоол.* башакчы корт
bamteli *и.* музыка коралларында бас кылы
bamya *и. бот.* бамия
ban *и.* Венгрия һәм Хорватиядә эре феодал
banmak *ф.* ману, манчу
bana *а.* миңа
banak *и. сөйл.* телем
banal *с.* баналь
banço *и. муз.* банджо (*музыка коралы*)
bandaj *и.* бандаж
bandırmak *ф.* 1) мандыру; 2) йөзем җыйганда аның тәлгәшләрен кайнар суга тыгып алу
bandıra *и.* (*корабта*) байрак, әләм, флаг
bando *и.* оркестр
bandocu *и.* оркестрчы, оркестрант
bandrol *и.* 1) ярлык, этикет; 2) бандероль; 3) байрак сабына өстән беркетелгән тасма яисә чук
bangırdamak *ф.* һөңгердәү
bank *и.* банк (*кыскартылган кушма сүзләрдә*)
banka *и.* банк (банкы) □ **banka cüzdanı** банкы кенәгәсе; **bankadan çekmek** банктан (банкыдан) акча алып тору
bankacı *и.* банкчы (банкымы)
banker *и.* банкир
banknot *и.* банкнот, кәгазь акча
banko *и.* 1) (*кәнсәләрдә, почтада һ. б.*) хезмәткәр белән килгән-киткәннәр

арасындагы барьер, эш өстәле; 2) (*кәрт һ. б. отышлы уеннарда*) уртага куелган акча, пул; 3) шундый уеңда кәрт һ. б. таратучы
banlamak *ф.* 1) кычкыру (*әтәч тур,*); 2) кычкыру, акыру (*кеше тур.*)
banliyö *и.* шәһәр тирәсе, бистә □ **banliyö treni** шәһәртирә поезд
bant *и.* 1) бант, тасма; 2) бинт, бәйләвеч; 3) магнитофон тасмасы □ **banta almak** тасмага яздыру
bantlamak *ф.* бантлау, бант белән бәйләү
banyo *и.* ванна, мунча □ **banyo almak** (**yapmak**) юыну, мунча керү
baobap *и. бот.* баобаб
bar I *и.* халык биюе
bar II *и.* бар; аягүрә ашау-эчү урыны
bar III *и. физ.* бар, басым үлчәү берәмлеге
bar IV *и.* катлау, катлам, кунык
baraj *и.* 1) бөя, плотина; 2) *күч.* кирәкле шарт, нигезләмә
barak 1. *с.* йонлач, ялбыр. 2. *и.* барак, йонлач эт токымы
baraka *и.* барак, такта өй
barata *и.* 1) *тар.* солтан сараенда хезмәткәрләрнең махсус баш киеме (*гадәттә кызыл берет*); 2) Көнбатыш Европа илләрендә гыйлем әһелләре кия торган дүрт почмаклы киң баш киеме
barbar *и. с.* варвар
barbarca *с. рәв.* варварларча
barbarlaşmak *ф.* варварлашу
barbata *и.* кальга диварының өске ягы
barça *и.* барка (*йөк яки сугыш көймәсе*)
barçak *и.* кылыч тоткасының багалдагы (саклагычы)
barda *и.* чүкечсыман кискеч
bardak *и.* стакан, тустаган ◊ **bardağı taşıran damla** чыгырыннан чыгарган эш (сүз һ. б.); **bardaktan boşanırcasına yağmak** чиләкләп яву (*яңгыр*)
bardakeriği *и.* татлы өрек төре
barfiks *и.* турник
bargam *и. зоол.* диңгез балыгының бер төре
barı *и.* бакча коймасы
barınmak *ф.* 1) качыну, яшеренү; 2) килеп урнашу
barınak *и.* качу урыны, сыеныр җир
barış *и.* 1) килешү, ярашу; 2) солых
barışçı *и.* килешү тарафдары
barışçıl *с.* килешүчән, яратучан
barışık *с.* ипле, карусыз
barışıklık *и.* иплелек, карусызлык
barışma *и.* килешү, ярашу, ипкә килү
barışsever *с.* ипчел; килешү яклы
barıştırmak *ф.* килештерү, яраштыру
barıştırıcı *и.* килештерүче, яраштыручы
bari *кер. сүз.* һич булмаса
barikat *и.* баррикада
bariton *и.* баритон
bariz *и.* ачык, мәгълүм
barizleşmek *ф.* ачыклану, мәгълүм булу
bark *и.* корылма, каралты
barmen *и.* Бармен
baro *и.* адвокатлар коллегиясе
barok *и.* барокко (стиле)

barometre *и.* барометр
baron *и.* барон
barut *и.* дары, барут *иск.*
barutçu *и. тар.* дарычы, дары ясаучы
baruthane *и.* дары ясау яисә саклау урыны
baryum *и.* барий (*химик элемент*)
bas *и.* бас (тавыш)
basmak *ф. төрл. мәгъ.* басу
basamak *и.* 1) баскыч аратасы, баскыч басмасы; 2) күбурынлы саннарда цифрларның урыны
basbayağı *и.* гап-гади, гап-гадәти
bası *и.* рәсем клишәсе
basıcı *и.* китап басучы
basıcılık *и.* китап басучылык
basık *с.* ямьшек, ямьшетелгән
basıklık *и.* ямьшеклек
basılmak *ф.* басылу, бастырылу
basıla *и.* басылырга яраклылык
basılı *с. төрле мәгъ.* басылган, бастырылган
basım *и.* 1) китап басмасы; 2) китап басу
basımcı *и.* китап басучы
basımevi *и.* типография, басмаханә
basın *и.* пресса
basınç *и. физ.* басым
basınç ölçer *и.* басымүлчәгеч
basil *и.* бацилла
basiret *и.* дөрес күрү, дөрес карау, аеклылык ◊ **basireti bağlanmak** чынбарлыкны аңлый алмас хәлгә килү
basit *с.* 1) гади, гадәти; 2) гади, тупас, бизәксез; 2) *күч.* чикләнгән, тар карашлы
basitleşmek *ф.* гадиләшү
basitlik *и.* 1) гадилек; 2) тар карашлылык
basket *и.* баскетбол исәп саны
basketbol *и.* баскетбол
basketçi *и.* баскетболчы
baskı *и.* 1) басым (ясау); 2) басылыш; *sözlüğün baskısı güzel* сүзлекнең басылышы матур; 3) басма; *kitabın yeni baskısı* китапның яңа басмасы; 4) тираж; 5) пресс, эскәнҗә □ **baskı kalıbı** китап тышына бастырып бизәк төшерү калыбы; **baskı yapmak** басым ясау, мәҗбүриләү
baskın 1. *и.* 1) басым, яу, һөҗүм; 2) тентү. 2. *с.* зуррак, артыграк; өстен, көчле; □ **baskın çıkmak** өстенлеген (көчен) күрсәтү
baskıncı *и.* баскынчы
baskül *и.* авыр йөкләр үлчәве, таразы *тар.*
basma 1. *и.* 1) басу (*эше*); 2) матбугат; 3) басма (*өстенә бизән бастырылган тукыма*); 4) *сөйл.* тирес, черемә. 2. *с.* басылган, нәшер ителгән
basmacı *и.* басма тукучы яисә сатучы
basmacılık *и.* басма җитештерү эше
basmakalıp *с.* күп кабатланган; тапталган, яңалыгы булмаган
basso *и.* бас (тавыш)
bastı *и. кулин.* тапалган ит һәм яшелчәдән пешерелгән ашамлык
bastırmak *ф.* 1) бастыру; 2) уздыру, арттыру
baston *и.* култаяк ◊ **baston yutmuş gibi** уклау йоткан кебек
basur *и.* бүсер; геморрой

basurotu *и. бот.* бүсер үләне
baş *и.* 1) баш; 2) ян, әйләнә-тирә; *ocak başı учак* яны ◊ **baş elde iken** исәнендә; **baş sağlığı dilemek** якыны үлгән кешенең кайгысын уртаклашу; **baş yakmak** кыен хәлдә калдыру; **başı daralmak** акчасызлыктан интегү
başak *и.* башак
başaklanmak *ф.* башаклану
başarmak *ф.* уңышлы башкару
başarı *и.* башкарылыш; уңыш
başarılmak *ф.* башкарылу
başarılı *с.* уңышлы
başarısız *с.* 1) башкарылышсыз, уңышсыз; 2) эшлексез
başasistan *и.* баш ассистент
başbakan *и.* премьер-министр
başbakanlık *и.* премьер-министрлык
başbuğ *и.* армия башлыгы
başçavuş *и.* подполковник
başçı *и.* 1) эш башында торучы, башлык; 2) баш ите (*сыер, сарык башы*) сатучы
başhekim *и.* баш врач
başhemşire *и.* баш сестра, өлкән сестра
başıboş *с.* 1) ирсез яки хатынсыз; 2) торыр җире булмаган
başka *с. рәв.* башка
başkaca *рәв.* башкача
başkahraman *и.* (*әсәрдә һ. б.*) баш каһарман
başkan *и.* рәис, президент
başkanlık *и.* рәислек, президентлык
başkası *а.* башкасы, башкалары
başkâtip *и.* сәркәтип
başkent *и.* башкала
başkomutan *и.* сәргаскәр (*главнокомандующий*)
başkomutanlık *и.* сәргаскәрлек
başkonsolos *и.* баш консул, баш илче
başkurt *и.* башкорт
başkurtça 1. *и.* башкорт теле. 2. *рәв.* башкортча, башкорт телендә
başlamak *ф.* башлау, башлану;
oyun başladı уен башланды
başlangıç *с.* башлангыч
başlanmak *ф.* башлану
başlı *с.* башлы
başlıca *рәв.* иң мөһим, иң беренче чиратта; бигрәк тә
başlık *и.* 1) башлык, баш киеме; 2) башча; китап бүлекләренең *һ. б.* исемләнеше; □ **başlık atmak** (**koymak**) язманы (китап бүлеген, мәкаләне) атау
başlıklı *с.* 1) башлыклы; 2)башчалы, исемләнешле
başmakale *и.* баш мәкалә
başörtü, **baş örtüsü** *и.* баш яулыгы
başsız *с.* башсыз
başvekil *и.* премьер-министр
başvurmak *ф.* мөрәҗәгать итү
batmak *ф.* бату
batak *и.* баткак, сазламык
bataklık *и.* баткаклык, сазлык
batarya *и.* батарея
batı *и.* көнбатыш, Көнбатыш

batık *с.* (*суга һ. б.*) баткан
bâtıl *с.* батыйль, бушка ышанулы
batılı *с.* көнбатышлы, Көнбатыш кешесе
batırmak *ф.* батыру
batkın *с.* бөлгән
batman *и.* батман
battal *с.* эшкә ярамаслык
battaniye *и.* одеял
bavul *и.* баул, зур тукыма сумка
bay *и.* әфәнде, ир кеше, абзый
bayağı *с.* 1) гадәти, гади; 2) баналь, кызыксыз, күптән билгеле; 3) вак, түбән, берни тормый торган
bayağılaşmak *ф.* 1) гадиләшү: кызыксызга әйләнү, күп кабатлану; 3) әшәкеләнү
bayan *и.* ханым, дама
bayat *с.* 1) искергән, каткан; 2) кызыксызга әйләнгән
baygın *с.* 1) һуштан язган; 2) зәгыйфь
baygınlık *и.* һуштан язганлык
bayılmak *ф.* һуштан язу
baykuş *и.* байгыш
bayrak *и.* байрак
bayram *и.* бәйрәм
baytar *и.* байтар, ветеринар
baz *и.* база; төп, нигез
bazen *рәв.* бәгъзән, кайбер вакытта
bazı *с.* бәгъзы, кайбер
bebek *и.* бәби
becermek *ф.* 1) башкарып чыгу; үтәү; 2) хәзерләп бирү; 3) үтәп чыгу, бәҗәрү *диал.*
bedava *рәв.* 1) бушлай, тигән; 2) юк бәягә
bedbin *с. и.* пессимист; □ **bedbin etmek** өметен өзү; **bedbin olmak** өметсезлеккә төшү
bedel *и.* 1) кыйммәт, чын бәя; 2) бәдәл, кеше өчен хаҗга бару
beden *и.* бәдән
bedevî *и.* бәдәви (гарәп күчмәне); күчмән (*күчеп йөрүче кеше*)
bedevîlik *и.* бәдәвилек
begonya *и. бот.* бегония гөле
beğenmek *ф.* 1) ошату; 2) ошатып сайлап алу; 3) кабул итү, раслау
beğeni *и.* зәвык
beğenilmek *ф.* ошау
beğeniş *и.* ошату
bej *и. с.* аксыл көрән
bek I *с.* каты, ныклы
bek II *и.* (*футболда*) якчы, яклаучы
bekâr *с. и.* өйләнмәгән, буйдак
bekâret *и.* 1) кызлык; 2) сафлык
bekas *и. зоол.* бекас, чуллык
bekçi *и.* сакчы, саклаучы; каравылчы
bekinmek *ф.* 1) карышу; 2) тыгылу, бөялү
bekitmek *ф.* бөялдерү; тыккычлау
beklemek *ф.* көтү, көтеп тору
bekleme *и.* көтү, көтеп тору;
bekleme odası (**salonu**) көтеп тору бүлмәсе
beklenmek *ф.* көтелү

beklenmezlik *и.* көтелмәгәнлек
bekleşmek *ф.* көтешү, бергә көтү
bekletmek *ф.* көттерү
bekleyici *и.* көтеп торучы
bekri *и.* эчкече
bekrilik *и.* эчкечелек
bektaşî *и.* суфичылыкның бер мәзһәбе һәм шул мәзһәптәге кеше, бикташи
bektaşîkavuğu *и. бот.* кактусның бер төре
bektaşî üzümü *и. бот.* тау үсемлекләрнең бер тере
bel I *и.* 1) бил; 2) тау билтере; 3) корабның урта өлеше □ **bel bağı** билбау ◊ **bel bağlamak** (*кемнеңдер*) ярдәменә ышану
bel II *и.* ишарәт
bel III *и.* мәни, сперма
belâ *и.* 1) бәла (бәлә); 2) тиешле җәза; 3) юньсез кеше, "хәсрәт"; □ **belâ aramak** гауга чыгарырга тору; **belâ okumak** каргау, бәддога уку; **belâya uğramak** бәлагә юлыгу
belâgat *и.* 1) матур һәм төзек сөйли белү, бәлагать *иск.*; 2) риторика, матур сөйләү гыйлеме
belâgatli *с.* матур сөйли белүче, бәлагатьле *иск.*
belâlı *с.* 1) бәлале (бәләле), гаугалы; 2) авыр, куркыныч (*мәс., эш*)
bel bel *рәв.* алан-йолан (*карану*)
belce *и.* ике каш арасы
belçikalı *и. с.* бельгияле, Бельгия кешесе
belemek *ф.* 1) (*бәби*) биләү, биләүсәгә төрү; 2) буяу, пычрату
belediye *и.* шәһәр (кала, бистә) идарәсе; бәләдия, мэрия
belediyeci *и.* бәләдияче, шәһәр (кала һ. б.) идарәсендә эшләүче
belek *и.* биләү, бәби биләүсәсе
belemir *и. бот.* пәйгамбәр чәчәге
belen *и.* тау билтере
belenmek *ф.* (*бала, бәби*) биләнү; 2) буялу, пычрану
belermek *ф.* (*күз*) *акаю*
belertmek *ф.* (*күзне*) акайту
beleş *с.* тиген килгән (*мөлкәт, акча*)
beleşçi *и.* тигенгә яшәүче, әрәм-тамак
belge *и.* 1) документ, таныклык; 2) документаль фильм
belgeci *и.* документаль фильмнар төшерүче
belgelemek *ф.* таныклау
belgelenmek *ф.* таныклану
belgeli *с.* 1) документлы; 2) таныклы
belgelik *и.* документлар саклана торган җир, архив
belgesel *с.* документаль
belgi *и.* 1) билге; 2) аң, белем
belgitemek *ф.* билгеләү, тамгалау
belgili *с.* билгеле, тамгалы
belgin *с.* ачык билгеле
belginlik *и.* ачык билгелелек
belgisiz *с.* билгесез, тамгасыз; үзенә билге куелмаган;
belgisiz zamir *гр.* билгесезлек алмашлыгы;
belgisiz sıfat *гр.* билгесезлек сыйфаты
belgisizlik *и.* билгесезлек, билге куелмаганлык
belgit *и.* документ; таныклык; документка куелган штамп, мөһер *һ. б.*
belik *и.* толым, чәч үрмәсе

beliklemek *ф.* толымлап үрү
belin *и.* билең (*нерв хасталыгы*; *куркучанлык*)
belinlemek *ф.* билеңлөү (*сәбәпсез кычкырып җибәрү, ярсудан катып калу һ. б.*)
belirmek *ф.* беленү
belirgin *с.* ачык, анык; белендерелгән
belirginleşmek *ф.* ачыклану, аныклану
belirginlik *и.* ачыклык, аныклык
belirlemek *ф.* билгеләү, аныклау
belirtenmek *ф.* билгеләнү, аныкланыш
belirlenim *и.* билгеләнеш, аныкланыш
belirlenimci *и.* детерминист
belirlenimcilik *и.* детерминизм (*сәбәпле бәйләнешләргә ышану һәм "серле" нәрсәләрне инкяр итү*)
belirli *с.* анык билгеле
belirme *и.* беленү
belirsizlik *и.* билгесезлек
belirtmek *ф.* ачыклау, билгеләү
belirten *и. гр.* аергыч
belirti *и.* билге, билгеле итүче
belirtilmek *ф.* ачыкланылу
belirtilen *и. гр.* аерылмыш
belirtili *с. гр.* аергычлы □ **belirtili tamlama** *гр.* I төр изафә
belirtisiz *с.* билгесез □ **belirtisiz tamlama** *гр.* II төр изафә
belirtken *и.* модификатор
belirtme *и.* ачыклау, билгеләү □ **belirtme durumu** *гр.* төшем килеш мәгънәсе, туры объект
belit *и.* аксиома
belkemiği *и.* умыртка
belki, **belkim** *терк.* бәлки, бәлкем
belkili *с.* ихтимал
belladonna *и. бот.* белладонна
bellemek I *ф.* үзләштерү, хәтердә Тоту
bellemek II *ф.* кыска саплы көрәк белән казу
bellek *и.* үзләштерү (хәтергә алу) көче □ **bellek yitimi** *мед.* стресс һ. б. нәтиҗәсендә хәтер югалу
belleme I *и.* үзләштерү, оту, хәтердә тоту
belleme II *и.* билләмә, ат һ. б. биленә ябылган ябу
belleten *и.* бюллетень
belli *с.* билгеле □ **belli etmek** белдерү, сиздерү; **belli başlı** ачык билгеле; мөһим
bellilik *и.* билгелелек
bellisiz *с.* билгесез
belsem *и.* бәлзәм
bembeyaz *с.* ап-ак
ben I *а.* мин, үзем
ben II *и.* 1) миң; 2) йөземнең өлгереш билгесе; 3) чәч-сакалдагы берекче ак төкләр
ben III *и. сир.* җим
benbenci *и.* минминлекле кеше
bencil *с.* минминчел
bende *и.* бәндә; тоткын, кол
benek *и.* тап, сипкел
beneklenmek *ф.* таплану, сипкелләнү
benekli *с.* таплы, сипкелле

bengi *с.* мәңге, мәңгелек
bengilemek *ф.* мәңгеләштерү
bengileşmek *ф.* мәңгеләшү
bengilik *и.* мәңгелек
beniçincilik *и.* эгоцентризм
benildemek *ф. сөйл.* билеңләү, сискәнү
benim a, минем
benimki *а.* минеке
benimsemek *ф.* үз итү, үзсенү, үзләшү
beniz *и.* йөз төсе, йөз чалымнары; **benzi atmak** (**uçmak**) йөзенең төсе качу, агару
benlenmek *ф.* миңләнү, миң белән каплану
benli *с.* миңле
benlik *и.* 1) минлек; 2) минминлек
benlikçi *и.* минминлекче
benzemek *ф.* охшау
benzer *терк.* охшаш; кебек, биңзәр *иск.* □ **benzer şekiller** *мат.* охшаш фигуралар
benzerlik *и.* охшашлык
benzersiz *с.* охшашы булмаган, тиңсез
benzeş *с.* охшаш, охшашкан, охшашлы
benzeşmek *ф.* охшашу
benzeşim *и.* охшашу хәле
benzeşme *и.* 1) охшашу; 2) *лингв.* ассимиляция
benzeşmez *с.* охшамый торган
benzetmek *ф.* охшату
benzeti *и.* копия □ **benzeti ressamı** оригиналга карап рәсемне күчереп ясаучы
benzetici *и. с.* 1) охшатучы; 2) копияче (*рәссам*)
benzeyiş *и.* охшау хәле
benzin *и. хим.* бензин
benzol *и. хим.* бензол
beraat *и.* 1) аклану, гаепсез табылу; 2) *дини.* бәраәт
beraber *рәв.* 1) бергә, берьюлы; ... белән бергә; 2) бәрабәр, тиң; 3) (*ничья*) әлче
beraberinde *бәйл.* яныңда, үзе белән бергә
beraberlik *и.* 1) бергәлек; 2) берьюлы булу
berat *и.* 1) патент; 2) *тар.* ташлама, сөяргәл *тар.,* 3) *дини.* бәраәт
berbat *хәб. сүз. с.* 1) хөрти, начар, койты; 2) бозылган, җимерелгән хәлдә; 3) әшәке, чирканыч □ **berbat etmek** бозып, әшәкеләндереп ташлау; **berbat olmak** тәмам бозылу юлдан чыгу
berber *и.* сачтараш, парикмахер, бәрбәр *иск.*
berber balığı *и. зоол.* диңгез алабугасы
berberî *и.* бәрбәр, бәрбәри (*Төньяк Африкадагы халык һәм шуның бер кешесе*)
berberlik *и.* сачтарашлык, парикмахерлык, бәрбәрлек *иск.*
bere I *и.* бирт, күгәрү (*биртелгән төш караю, эренләү һ. б. ш.*)
bere *и.* берет (*баш киеме*)
bereket *и.* 1) бәрәкәт; 2) *сөйл.* яңгыр;
bereket versin бүләк яисә акча алганда рәхмәт сүзе
bereketlenmek *ф.* арту, ишәю, муллану
bereketli *с.* бәрәкәтле
bereketsiz *с.* бәрәкәтсез
berelemek *ф.* биртү, күгәртү
bergamot *и. бот.* армут тере
bergüzar *и.* истәлек (*истәлеккә бирелгән әйбер*)
berhane *и.* ташландык өй

berhayat *хәб. сүз.* яши, яшәп тора; исән-сау
beri 1. *алм.* бире, бирегә. 2. *бәйл.* бире, бирле □ **öteden beri** күптәннән бирле
beriberi *и.* бери-бери (*йокы чире*)
beriki *с.* бирге, биреге
berilyum *и. хим.* бериллий
berk *с.* каты, нык; ныклы
berkimek *ф.* ныгу
berkitmek *ф.* ныгыту
berklik *и.* ныклык, катылык
bermutat *рәв.* һәркөнгечә, һарвакыттагыча
berrak *с.* ачык, чиста, саф
bertaraf *хәб. сүз. рәв.* бер читкә, бер читтә торсын; □ **bertaraf etmek** кысрыклап чыгару, бер читкә этәрү
bertik *и.* бирт, биртек, яра эзе
bertilmek *ф.* 1) бәрелеп-сугылып зарарлану, имгәнү; 2) биртелү
berzah *и. геогр.* култык
besbedava *рәв. с.* бөтенләй арзан
besbelli *рәв. с.* бик билгеле, ачык мәгълүм
besbeter *рәв. с.* бик начар; бишбитәр *сөйл.*
besi *и.* 1) асрау; 2) симертү
besici *и.* (*терлекне*) симертеп сатучы
besidoku, **besidokusu** *и.* 1) *биол.* альбумин; 2) *бот.* эндосперм
besili *с.* симертелгән
besin *и.* 1) азык-төлек; 2) кирәк-ярак
besinli *с.* азык-төлекле
besinsiz *с.* азык-төлексез
besiörü *и. бот.* орлыкның тукланыш (азыклык) матдәсе
besi suyu *и. бот.* орлыкның тукланыш (эчемлек) суы
beslemek *ф.* 1) ашату, асрау; 2) симертү, үрчетү; 3) *күч.* яшәтү □ **ümit beslemek** (*күңелдә*) өмет яшәтү
besmele *и.* бисмилла; □ **besmele çekmek** бисмилла әйтү
besmelesiz *с.* бисмилласыз
beste *и.* бербөтен музыка әсәре; көй
besteci *и.* композитор, көй язучы
bestekâr *и.* композитор, көй язучы
bestelemek *ф.* көй язу
bestelenmek *ф.* үзенә көй язылу
besteli *с.* көйле, музыкалы
bestesiz *с.* көйсез, музыкасыз
beş *сан.* биш
beşbıyık *и. бот.* әре мушмула
beşbinlik *и.* бишмеңлек (биш мең лиралык) кәгазь акча
beşer I *и.* инсан, (*хөрмәткә лаеклы*) кеше
beşer *сан.* бишәр
beşeriyet *и.* кешелек дөньясы, инсаният
beşgen *и. мат.* бишпочмак, бишлек *диал.*
beşibirlik, **beşibiryerde** *и.* чулпы (*биш алтын тәңкә*)
beşik *и.* бишек ◊ **beşik kertme nişanlı** бишектә үк ярәшелгән
beşikörtüsü *и.* ике тарафка сөзәкле түбә
beşinci *сан.* бишенче
beşlemek *ф.* бишләү, бишәрләү
beşli *с.* бишле, бишәрле

beşlik *и.* бишлек
beşparmak *и. зоол.* диңгез йолдызы
beşyüz *сан.* биш йөз
beşyüzlük *и.* биш йөзлек (*акча*)
bet I *и.* бит, йөз (*аерым тәгъбирләрдә генә кулланыла*)
bet *с.* начар, әшәке
betatron *и.* бетатрон
beter *с.* битәр, начаррак
beti *и.* төрле шәкелдәге рәсем
betik *и.* язу, бөти, бетек *иск.*
betili *с.* төрле шәкелдәге рәсемнәре булган
betim *и.* тасвир, тасвирлама
betimlemek *ф.* тасвирлау
betimsel *с.* тасвирлы, тасвири
beton *и.* бетон
betonarme *и.* тимербетон
betonkarar *и.* бетонболгаткыч
bey *и.* 1) бәй, әфәнде; 2) *иск.* бай, хуҗа; 3) ир, гаилә башы; 4) *тар.* командир
beyan *и.* бәян (бәйан), сөйләп бирү; тасвир □ **beyan etmek** бәян итү
beyanat *и.* тасвирлы белдерү
beyanname *и.* тасвирлама, бәяннамә
beyaz *с.* ак (*төстәге*) ◊ **beyaz ırk** ак раса; **beyaz kitap** хөкүмәт яисә берәр оешма тарафыннан әзерләнгән тасвирлама, бәяннамә; **beyaz zehir** героин (*наркотик матдә*)
beyazcam *и.* телевизор экраны
beyazeşya *и.* көнкүреш техникасы (*суыткыч, кер югыч машина һ. б. w. нәрсәләрнең гомуми атамасы*)
beyazımtırak, **beyazımsı** *с.* аксыл
beyazkömur *и.* "ак күмер", гидроэнергия
beyazlanmak, **beyazlaşmak** *ф.* агару
beyazlatmak ф. агарту
beyazlık *и.* аклык
beyazperde *и. төрле мәгъ.*экран
beyazsinek *и.* мамык чебене (*корткыч бөҗәк*)
beybaba *и.* 1) хөрмәтле өлкән ир кеше; 2) (*баланың*) әтисенә хөрмәтләп эндәшү сүзе
beyefendi *и.* бәй әфәнде (*ир кешегә карата хөрмәт белән эндәшү һәм атау сүзе*)
beygir *и.* 1) алаша; 2) гади эш аты
beygirgücu *и. физ. тех.* ат көче
beyin *и.* ми, баш мие □ **beyin zarı** ми кабыгы ◊ **beyin karıncalanmak** баш түнү; **beyini kemirmek** баш авырттыру (*төрле мәсьәләләр белән тинтерәтү*)
beyincik *и. анат.* мичек, кечкенә ми
beyinli *с. күч.* башлы, акыллы
beyinsi *с. анат.* мисыман
beyinsiz *с. күч.* акылсыз
beyinüçgeni *и. анат.* ми өчпочмагы
beyit *и.* 1) өй, йорт, корылма; 2) *әд.* кушык, строфа
beylerbeyi *и. тар.* губернаторлар башлыгы, губернаторлар советының рәисе
beylik I *и.* 1) билек; би, бәй булу; 2) билек, вассал биләмә; 3) *сөйл.* дәүләт идарәсе, власть
beylik II *и.* кечкенә һәм юка одеял
beynamaz *с.* бинамаз, намазсыз, намаз укымый торган

beynelmilel 1. *и.* бәйнәлмиләл, интернационал. 2. *с.* бәйнәлмиләл, интернациональ
beynelmilelcilik *и.* интернационализм
beyzî *с.* оваль
bez I *и. с.* 1) бәз, мамык тукыма; ситсы; 2) (*гомумән*) тукыма; 3) чүпрәк
bez II *и. анат.* биз
bezmek *ф.* бизү, күл селтәү
bezdirmek *ф.* биздерү
bezdirici *с.* биздергеч
beze I *и.* биз, авыртусыз шеш
beze II *и.* 1) әвәләнгән камыр; 2) *кулин.* безе, күбек
bezemek *ф*. бизәү
bezek *и.* бизәк
bezeklemek *ф.* бизәкләү, бизәү
bezekli *с.* бизәкле
bezelemek *ф.* камыр әвәләү
bezen *с.* бизәгеч
bezenmek *ф.* бизәнү
bezeyici *и.* бизәүче
bezgin *с.* бизгән, төшенке күңелле
bezginleşmek *ф.* бизү, күңелен төшерү, кул селтәү
bezilmek *ф.* бизү, төшенкелеккә бирелү
bezir *и.* 1) җитен орлыгы; 2) җитен мае, олиф
bezirgan *и.* 1) базаркян, базар сәүдәгәре; 2) *күч.* һәр эштә карьера яисә мал табу ягын караган кеше
bezirgânbaşı *и.* 1) *тар.* солтанның базарчыларына баш булган түрә; 2) балалар уены
bezirlemek *ф.* җитен мае белән майлау
beziryağı *и.* җитен мае, олиф
bıcıl *и.* ашык сөяге
bıcırgan *и.* көпшәсыман металл детальләрнең эчен тигезләү һәм чистарту коралы; түгәрәк игәү
bıçak *и.* пычак, пәке ◊ **bıçak altına yatmak** пычак астына яту (*операция ясату*); **bıçak çekmek** пычак белән кадарга хәзерләнү; **bıçak bıçağa gelmek** пычакка пычак килү; **bıçak sırtı** кыл арасы аерма
bıçaklamak *ф.* 1) пычак белән кисү; 2) пычак белән яралау; пычаклау
bıçaklanmak *ф.* 1) пычак белән киселү; 2) пычак белән яралану
bıcılgan *и.* 1) азган шеш яки яра, гангрена; 2) хайваннарның тырнак төбе шешү
bıçkı *и.* 1) зур пычкы, пила; 2) итекче пычагы
bıçkın *с.* куркусыз үткен (*кеше*)
bıçkınlaşmak *ф.* үткенләнү, үткенләшү
bıçkınlık *и.* үткенлек; куркусызлык
bıdık *с.* курач (*кием*)
bıkmak *ф.* ялыгу, тую
bıkılmak *ф.* ялыгу, тую
bıkkın *с.* тәмам ялыккан (*хәлдәге*)
bıktırıcı *с.* ялыктыргыч
bıktırmak *ф.* ялыктыру
bıldır *сөйл. и.* былтыр
bıldırcın *и.* бүдәнә
bıngıldamak *ф.* лепелдәп тору, селкенеп тору
bıngıldak *и.* лепкә
bırakmak *ф.* 1) ташлау; бырагу *иск. һәм диал.*; 2) онытып калдыру; 3) тапшыру

bırakılmak *ф.* ташланылу, ташлану (*әйбер тур.*)
bırakışmak *ф.* 1) ташлашу; 2) (*сугышны һ. б.*) бәргәләшләп туктату
bıyık *и.* мыек
bıyıklanmak *ф.* мыеклану
bıyıklı *с.* мыеклы
bıyıksız *с.* мыексыз
bızbız *и.* сул кулда тотыла торган барабан таягы
bızdık *и.* кечкенә бала, бәпеч, бәләкәч
biber *и. бот.* борыч
biberiye *и. бот.* розмарин гөле
biberlik *и.* 1) борыч савыты; 2) борыч үскән җир
biberon *и.* имезлек шешәсе
bibersiz *с.* борычсыз
bibi *и. сөйл.* биби *диал.,* әтинең сеңлесе
bibliyofil *и.* библиофил
bibliyograf *и.* библиограф
bibliyografik *с.* библиографик
bibliyografya, **bibliyografi** *и.* библиография
bibliyoman *и.* китап сөюче, библиоман
bibliyomani *и.* китап сөючелек, библиомания
bibliyotek *и.* библиотека
bibiiyotekçi *и.* библиотекачы, библиотекарь
biçmek *ф.* 1) үлчәп кисү; 2) уру
bîçare *с. и.* бичара
biçerbağlar *и.* көлтәбәйләгеч (*машина*)
biçerdöver *и.* комбайн (*иген комбайны*)
biçilmek *ф.* урылу, чабылу
biçim *и.* 1) тышкы күренеш, килбәт; 2) шәкел, форма; 3) рәвеш; 4) (*эчке*) төзелеш
biçimbilimi *и.* конструкторлык
biçimbirim *и.* морфема
biçimci *и.* 1) формалаштыручы, форма бирүче; 2) формалист
biçimlenmek *ф.* формалашу
biçimlendirmek *ф.* формалаштыру
biçimli 1. *с.* формалы. 2. *бәйл. мәгъ.* охшаш
biçimsel *с.* 1) формаль; 2) формалистик
biçimsellik *и.* формальлек
biçimselleşmek *ф.* формальләшү
biçimsiz *с.* формасыз
biçimsizlik *и.* формасызлык
biçki *и.* (*кием тегү өчен материал*) кисү
biçme *и.* 1) үлчәп кисү эше; 2) *мат.* призма
bidon *и.* бидон
biftek *и.* кыздырылган ит телеме
bîhaber *с.* рәв. бихәбәр, хәбәрсез
bikini *и.* хатын-кыз коену костюмы (*ике аерым өлештән тора*)
bilmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* белү; 2) дин белү; 3) *"башкара алу, булдыру" мәгъ.* бүтән фигыльләрнең нигезенә кушылып килә; *anlatabilmek* аңлата алу; **bildiğim gibi** белгәнемчә; **bildiğinden şaşmamak** бернигә дә карамастан үз юлыңнан бару; **bildiğini yapmak** белгәнен эшләү; **bilemedin** (**bilemediniz**) күп булса, иң күбендә, күп дигәндә; **bilmeden** белмичә; **bilmem hangi** (**kaç**, **kim**, **nasıl**, **ne**) ниндидер (күпмедер, кемдер, ничектер, нидер)
bilâhare *рәв.* соңыннан, аннары

bilâkis *рәв.* киресенә
bilânço *и.* баланс (*берәр эшне башкару өчен сарыфларны, керем-чыгымнарны күрсәткән хисаплама*)
bilârdo *и.* бильярд (*уены*)
bildik *и.* 1) белгән нәрсә, белдек; 2) белеш, таныш
bildirmek *ф.* белдерү, хәбәр бирү
bildirge *и.* белдерге, справка, рәсми аңлатма язуы
bildiri *и.* 1) белдерү; 2) кыска доклад
bildirilmek *ф.* белдерелү
bildirişmek *ф.* белдерешү
bildirme *и.* белдерү; белешмә
bile *рәв.* эстәвенә; хәтта, гына да, да; *bir çocuk bile bunu anlar* хәтта бала да аңлый алыр моны
bilemek *ф.* беләү, кайрау
bileği *и.* беләү, кечерәк кайрак
bileğitaşı *и.* беләү ташы
bilek *и.* 1) *анат.* беләзек (*кул һәм аякның иң нәзек урынын гына белдерә*); 2) *күч.* көч, куәт □ **bilek güreşi yapmak** кул көрәштерү
bileklik *и.* спортив беләксә
bileşmek *ф.* берләшем хасил итү, кушылу
bileşen *и. физ.* тиңкәрне (тиң-көчне) хасил иткән көчләрнең берсе; кушым көч
bileşik *с. и.* 1) берләшеп хасил булган, берләшкән; 2) *хим.* кушылма; **bileşik faiz** катлаулы процент; **bileşik kesir** катнаш вакланма, санаучысы вакланмасыннан зуррак булган вакланма
bileşim *и. хим.* состав, берләшем
bileşke *и. физ.* тиңкөч, тиңкәр
bileştirmek *ф.* берләштерү, кушу
bileştirici *и.* берләштерүче, кушучы
bilet *и.* билет
biletmek *ф.* кайрату
biletçi *и.* билетчы
bilezik *и.* 1) беләзек; 2) берләштергеч муфта, куныч
bilfiil *рәв. кер. сүз.* гамәлдә, *чынлыкта*
bilge *и. с.* гыйлем иясе, хәким
bilgece *рәв. с.* галимнәрчә, хәкимнәрчә
bilgi *и.* 1) белем, белек, белге *иск.*; 2) гыйлем, фән-белем тармагы; *doğa bilgisi* табигать гыйлеме
bilgicilik *и.* софизм
bilgiç *и.* 1) белгеч, белүче; 2) үзен белемле (гыйлемле) дип күрсәтергә тырышучы кеше; беләмән
bilgiçlik *и.* 1) белгечлек, белүчелек; 2) *күч.* беләмәнлек ◊ **bilgiçlik satmak** (**taslamak**) бик белдеклеләнү
bilgilenmek *ф.* белем үзләштерү, белгечлек алу
bilgili *с.* белекле, белемле
bilgilik *и.* энциклопедия; белешмәлек
bilgin *и. с.* күп белүче; үз өлкәсендә компитентлы кеше
bilginlik *и.* күп белүчелек
bilgisayar *и.* компьютер
bilgisayarcı *и.* компьютерче
bilgisiz *с.* белексез; белемсез
bilgisizlik *и.* белексезлек; белемсезлек
bilgiyazar *и.* хәреф тезүче компьютер

bilhassa *рәв.* бигрәк тә, аеруча
bili *и.* беләк, мәгълүмат
bilim *и.* белем, фән
bilimci *и.* белемче; белем һәвәскәре
bilimdışı *с.* белемгә каршы, фәнни булмаган
bilimsel *с.* гыйлем белән бәйләнешле; гыйльми
bilimselleştirmek *ф.* гыйльмиләштерү, фәнгә яраклаштыру
bilimsellik *и.* гыйльмилек; фәнчәлек
bilimsiz *с.* белемсез
bilimsizlik *и.* белемсезлек
bilinmek *ф.* беленү
bilinç *и.* аң, аң-белем
bilinç altı *и.* аңасты, астаң
bilinçdışı *и. с.* аңнан тыш, аңсыздан; аңсызданлык
bilinçlenmek *ф.* аңлылану
bilinçlendirmek *ф.* аңлыландыру
bilinçli *с.* аңлы
bilinçlilik *и.* аңлылык
bilinçsiz *с.* аңсыз
bilinçsizlik *и.* аңсызлык
bilindik *и. мат.* билгеле сан
bilinemez *и. фәл.* акыл ирешмәслек
bilinemezci *с.* аңлашылмаган нәрсәләрне өйрәнүче
bilinen *и. мат.* билгеле
bilinmedik *с. и. мат.* билгесез
bilinmeyen *с. и. мат.* беленмәгән, билгесез
bilinmez *с.* беленмәс, беленмәслек; серле
bilinmezlik *с.* беленмәслек
bilir *с. и.* "белә, аңлый, булдыра торган" мәгънәсендә килеп кушма сүзләр ясый; *değerbilir* кыйммәтен белүче; *işbilir* эш рәтен белүче
bilirkişi *и.* эксперт
bilirkişilik *и.* экспертлык
bilisiz *с.* белемсез, надан
bilistifâde *рәв.* ярдәмендә, ярдәме белән
biliş *и.* 1) белемлелек, эрудиция; 2) *сөйл.* белеш, таныш, дус
bilişmek *ф.* белешү, бер-берең белән танышу
bilişim *и.* информатика
billâhi *и.* билләһи (биллаһи, биллəһи) (*ант сүзе*)
billûr *и. с.* бәллүр, кристалл
billûrcisim *и. анат.* күз ташы
billûriye 1. *с.* бәллүрдән ясалган. 2. *и.* бәллүр нәрсәләр сатыла торган кибет
billûraşmak *ф.* кристаллашу
billûrsu 1. *с.* кристаллсыман, бәллүрсыман; кристаллоид. 2. *и. хим.* коллоид
bilmece *и.* табышмак
bilmez *с.* белмәс, надан; белмәмеш
bilmezlemek *ф.* надан калдыру, мәгълүматсыз калдыру
bilmezlerimek *ф.* белмәмешкә салышу
bilmezlik *с.* белмәслек
bilmiş *с.* белгән
bilvasıta *рәв.* ярдәмендә, васитасында
bilye *и.* 1) шарчык; 2) шудыргыч (подшипниклар) шарчыгы
bilyeli *с.* шарчыклы

bin *сан.* 1) мең; 2) бик күп ◊ **bin bir** исәпсез күп; **bin can ile** дүрт куллап (бик теләп); **bin derde deva** һәр эшкә ярый торган; **bin dereden su getirmek** хисапсыз дәлил (сылтау) китерү; **bin yaşa**! мең яшә!
binmek ф. 1) *төрле мәгъ.* менү; 2) (*бәяләр, эш хакы һ. б.*) күтәрелү
bina *и.* бина; □ **bina etmek** тезү
binaenaleyh *кер. сүз.* менә шуңа күрә; бинаән-галәйһи *иск.*
binbaşı *и.* меңбашы; майор
binbaşılık *и.* меңбашы булу, майорлык
bindallı *с.* чигүле кием-салым
bindirmek *ф.* мендерү
bindirim *и.* бәяләрне арттыру
bindirimli *с.* бәяләре арттырылган
bindirme *и.* 1) мендерү; 2) әрдәнә; 3) диңгез десанты
binek *и. с.* менге (*ат*), менәк *иск.*
binektaşı *и.* атка атлану өчен махсус таш (*өй янында куела*)
bini *и.* менү
binici *и.* аткаменәр, атка атланып оста йөрүче
binicilik *и.* ат менеп йөрү осталыгы
binilmek *ф.* менелү
bininci *сан.*меңенче
biniş *и.* 1) (*атка*) менү; 2) тар. атлы гаскәриләрнең форма киеме
binişmek *ф.* менешү, аслы-өсле туры килү, япсарылу
binit I *и. сөйл.* менге ат
binit II *и.* ипи көрәге
binlerce *рәв.* меңнәрчә
binlik *и.* 1) *төрле мәгъ.* меңлек; 2) якынча өч литр сыешлы шешә
binme *и.* менү
binyaprak *и. бот.* меңъяфрак (*үләне*)
bir *сан. төрле мәгъ.* бер □ **bir ağızdan** бер авыздан, барысы бергә, берьюлы әйтеп; **bir an** беравык; **bir ara** берара; **bir araya gelmek** туплану, җыелу; **bir araya getirmek** туплау, җыю; **bir avuç** бер уч; **bir (tek) başına** бер башына; **bir boyda** бер буйлы; **bir daha** бер дә, һич тә; **bir de** тагы; **bir dolu** шактый; **bir nebze** бик аз; **bir parça** бер кисәк, бер телем; **bir sıra** бер рәттән; **bir şey değil** рәхмәткә каршы әйтелә торган сүз, "исән бул!"; **bir vakit** бервакыт; бер мәлне; **bir yana** бер якта калып торсын; **bir yandan**, **ikinci yandan** бер яктан, икенче яктан; **bir yol** бер тапкыр; **bire bîr eşleme** *мат.* катлаулы ике төркемнең барча элементлары тәңгәл булу яисә тәңгәлләшү ◊ **bir araba** бер олау; **bir atımlık barutu olmak** (**kalmak**) бераз көче (мөмкинлеге) булу (калу); **bir ayağı çukurda** бер аягы кабер ягасында; **bir ayak önce** (**evvel**) әз генә алдан; **bir ayak üstünde bin yalan** бер аяк өстеңдә мең ялган - кыска гына вакытта әллә ничә (күп) ялган; **bir bardak suda fırtına** бер стакан суда давыл (*кубару*); **bir çatı altında** бер кыек астында; **bir çırpıda** тиз генә; **bir çöplükte iki horoz** бер чүплектә ике әтәч, бер казанда ике тәкә башы; **bir gün evvel** мөмкин кадәр тизрәк; **bir mum al da derdine yan** кеше эшенә тыгылма; **bire bin katmak** бергә меңне кушу
bira *и.* (*куәтле*) сыра, пирәш *иск.*
biracı *и.* пирәшче, сырачы
biracılık *и.* сырачылык
birader *и.* берадәр (брадәр) *иск.:,* туган, туганкай
birahane *и.* сыраханә, пирәшханә *иск.*
biralık *с.* сыралык, пирәшлек
biraz *рәв. с.* бераз

birazcık *с.* аз гына
birazdan *рәв.* бераздан
birbiri *а.* бер-берсе □ **birbirine** бер-беренә, берсе берсенә; **birbirinden** бер-береннән, берсе-берсеннән ◊ **birbirini yemek** берсен берсе ашап бару, дошманлашу, низаглашу; **birbirinin ağzına girmek** үзара бик якын, дус булу
birci *и.* монист, дөньяда һәрнәрсәнең чыганыгы бер диюче
bircilik *и.* монизм
birçok *рәв.* шактый
birde *рәв.* 1) тагы, моннан тыш; 2) кинәт
birden *рәв.* 1) бердән, бергә; 2) көтмәгәндә, кинәт
birdenbire *рәв.* көтмәгәндә
birdirbir *и.* шәкшәкәр уены
birebir *рәв.* нәкъ үзе, нәкъ кирәге
birer *сан.* берәр □ **birer birer** берәмләп
bireşim *и.* 1) бербөтен, берләшмә, берләшем; 2) синтез
bireşimli *с.* синтетик
birey *и.* 1) берәү, бер кеше; 2) массаны хасил иткәннәрнең бер**се**; шәхес
bireyci *и.* шәхес хокукларын яклаучы
bireycilik *и.* шәхес хокукларын яклаучылык
bireyleşme *и.* тупламның (массаның) бер затта чагылышы
bireysel *с.* бер затка бәйләнешле
birgözeli *с. биол.* беркүзәнәкле
biri, **birisi** *и.* бере, берсе
biricik *с.* бердәнбер
birikmek *ф.* берегү
birikim *и.* 1) берекмә; 2) бергәлек; 3) җыелып берләшү, туплану
birikinti *и. төрле мәгъ.* конгломерат
birikiş *и.* берегү
biriktirmek *ф.* беректерү
birim *и.* берәмлек
birinci *сан.* беренче
birincil *с.* беренчел
birincilik *и.* беренчелек
birincizar *и.* җиләк-җимеш кабыгы
birkaç *с. а.* берничә
birlemek *ф.* бер итү
birler *и. мат.* берәмлекләр, берләр, берлекләр
birleşmek *ф.* берләшү
birleşen *с. мат.* кисешә торган, кисешкән (*сызыклар*)
birleşik *с.* кушма
birleşilmek *ф.* берләшелү
birleşim *и.* 1) берләшү эше; 2) *биол.* җенси кушылу
birleştirmek *ф.* берләштерү
birleştirici *и.* 1) берләштерүче; 2) берләштергәч
birli *и. с.* берле
birlik *и. төрле мәгъ.* берлек
birlikte *рәв.* берлектә, бергә; үзең белән
birliktelik *и.* бергә булу, бергәлек
birtakım *с.* бертөркем; кайбер
birterimli *с. мат.* бербуынлы (*сан*)
biryan *и.* кыздырылган ит, кәтлит
bisiklet *и.* велосипед

bisikletçi *и.* велосипедчы
bisküvi *и.* перәннек, бисквит
bit *и.* бет
bitmek I *ф.*1) бетү; 2) хәлсезләнү, бетү *сөйл.*; 3) *күч.* бик ярату, гашыйк булу □ **bitmez-tükenmez** бетмәс-төкәнмәс
bitmek II *ф.* үсү
bîtap *с.* кәефсез, сырхау
bitik *с.* бетеренгән, бетешкән, бик ябыккан, хәлсезләнгән, көчсезләнгән (*кеше*)
bitiklik *и.* бетеренгәнлек
bitim *и.* 1) (*әсәрдә һ. б.*) бетем; 2) бетү
bitimli *с.* 1) бетемле; ахырлы; 2) бетә торган
bitimsiz *с.* 1) бетемсез; ахырсыз; 2) бетми торган
bitirmek *ф. төрле мәгъ.* бетерү
bitirim *арго.* 1. *с.* 1) бик шәп (*кеше, җир*); 2) зирәк һәм үткен; *bitirim çocuk* бик үткен бала. 2. *и.* отышлы уеннар уенханәсе
bitiş *и.* бетеш
bitişmek *ф.* терәлү, теркәлү
bitişik *с.* 1) теркәлешкән, терәлешкән; 2) күрше; 3) яндагы, янгы
bitişiklik *и.* теркәлешкәнлек
bitişken *с. лингв.* аглютинатив (*телләр*)
bitişkenlik *и.* аглютинативлык
bitiştirmek *ф.* терәтү; бик якын урнаштыру
bitiştirilmek *ф.* терәтелү
bitki *и.* үсемлек
bitkibilimi *и.* үсемлек гыйлеме, ботаника
bitkici *и.* үсемлек үстерүче
bitkimsi *с.* үсемлек сыман
bitkin *с.* тәмам көчсезләнгән, хәлсез, мәлҗерәгән
bitkisel *с.* үсемлекләр белән бәйләнешле
bitlemek *ф.* бет чүпләү, бет карау
bitlenmek *ф.* бетләү
bitli *с.* бетле
bitotu *и. бот.* бет үләне
bitpazarı *и.* талчук, иске-москы базары
bitüm *и.* битум
bitümlemek *ф.* битумлау
bitümlü *с.* битумлы
bityeniği *и.* яшерен (яшереп калдырылган) җитешсезлек
biye *и.* кайма
biyel *и.* шатун; тарту кече
biyeli *с.* каймалы
biyoelektrik *и.* биоэлектр
biyofizik *и.* биофизика
biyografi *и.* биография
biyokimya *и.* биохимия
biyolog *и.* биолог
biyoloji *и.* биология
biz I *а.* без
biz II *и.* без (*күн һ. б. тишү коралы*)
biz III *и. зоол.* бер төрле очлы башлы диңгез балыгы
bîzar *с.* тәмам бизмеш, гарык, бизар *диал.* □ **bîzar olmak** бизү, тую
bizimki *а.* безнеке

bizlemek *ф.* хайванны безле таяк белән чәнчеп куу
bizlengiç *и.* (*хайван куу өчен*) очы безле таяк
bizmut *и. хим.* висмут (*элемент*)
bizzat *рәв.* турыдан-туры; күзгә-күз күрешеп
blok *и. төрле мәгъ.* блок
blokaj *и.* 1) блокада; 2) хәрәкәтне тоткарлау, комачау; 3) корылмаларда кайбер бушлыкларны таш белән тутыру
bloke *и.* комачау; □ **bloke etmek** комачаулау, тоткарлау; (*спортта*) блоклау
bloknot *и.* блокнот
bloksuz *с.* хәрби-политик блокка кермәүче (кермәгән)
blöf *и.* 1) кәртле уенда алдау, алдашу (*хәрәмләшү түгел*); 2) блеф, махсус таратылган ялган хәбәр
blöfçü *и.* 1) уенда "законлы" алдау маневры үткәрүче; 2) ялган хәбәр таратучы
blucin *и.* тупас мамык тукыма тере
bluz *и.* блуза
boa *и.* 1) *зоол.* буар елан; 2) пальто якасының бер төре
boagiller *и. зоол.* буар еланнар
bobin *и. тех.* кәтүк, урама
bobinaj *и.* кинотасманы бер кәтүктән икенчесенә ураттыру, шүргечләү *диал.*
boca *и. диңг.* корабның җил тими торган ягы
bocalamak *ф. диңг.* 1) дрейфлау, (*җил туры килмәгәч, агым уңаена китәргә мәҗбүр булу*); 2) *күч.* икеләнү
boci *и.* авыр йөк арбасы
bocurgat *и.* йөк тарттыру чыгыры, тарттыргыч чыгыр
bodrum *и.* подвал
boduç *и.* агач паднус
bodur *с.* буеннан иңе зуррак (*мәс., мичкә, кәтүк һ. б.*), тәпән
bodurlaşmak *ф.* иңе буеннан зураеп китү, тәпәнләшү
bodurpas *и. бот.* тутыксыман гөмбә төре
boğmak *ф.* 1) буу; 2) туктату; 3) (*тавышны, утны һ. б.*) бастыру
boğa *и.* буга, эш үгезе
boğak *и. мед.* ангина, бугак *диал.*
boğanak *и.* өермәле җил
boğanotu *и. бот.* аконит, убыр уты
boğası *и.* юка тукыма, астарлык
boğaz *и.* 1) бугаз; 2) тамак ◊ **boğaz açmak** агач төбен казып йомшарту; **boğaz derdi** ашау-эчү өчен тырышулар; **boğaz dokuz boğumdur** "һәр сүзнең мәгънәсен тирән, уйлап сөйләргә кирәк" мәгънәсендә әйтелә; **boğaz olmak** тамак авырту; **boğaz tokluğuna** тамак хакына; **boğazı düğümlenmek** тамактан үтмәү; тамакка төелү; **boğazına dizilmek** тамагына утыру; **boğazına düşkün** тамаксау (*кеше*); **boğazına sarılmak** бугазына ябышу; **boğazından artırmak** ашау-эчүне кысып, акча һ. б. *җыю*
boğazkesen *и.* диңгез бугазын саклап тора торган кирмән, кальга
boğazlamak *ф.* бугазлау, сую
boğazlaşmak *ф.* бер-берсенең бугазына ябышу
boğazlı *с.* 1) бугазлы; 2) *күч.* гуҗ, күп ашаучан
boğça *и.* букча, сумка; кечкенә капчык
boğçacı *и.* букчачы, букча ясаучы яисә сатучы
boğçalamak *ф.* букчага тутыру
boğdurmak *ф.* будыру
boğdurulmak *ф.* будырылу
boğma *и.* 1) буу; 2) самогон, кумышка

boğmaca *и.* бума ютәл
boğmak *и.* буынтык
boğmaklı *с.* буынтыклы
boğucu *с. и.* 1) буучы; 2) бугыч, буа торган
boğuk *с.* буылган, кысылган (*аваз, тавыш*)
boğuklaşmak *ф.* тавыш кысылу
boğulmak *ф.* буылу
boğum *и.* буынтык
boğumlanmak *ф.* буынтыклану; төенләнү
boğun *и.* буын, буынтык
boğuntu *и.* 1) буылу, сулыш кысылу; 2) *күч.* спекуляция
boğunuk *с.* 1) авыр (*мәс., һава*); 2) кысынкы, кысык, басынкы
boğuşmak *ф.* буышу
bohçaböreği *и. кулин.* бөккән, бүрәк
bohçalamak, **boğçalamak** *ф.* букчага салу
bohen *и.* махсус рәвештә берни уйламыйча яшәү хәле
bokböceği *и.* тирес корты
boks *и.* бокс; *boks şampiyonası* бокс чемпионаты
boksör *и. спорт.* боксер
bol I *с.* мул, күп; киң □ **bol bol** шактый күп, бик күп; **bol bulamaç** артык күп, буа буарлык
bol II *и.* эчемлек (*махсус пыяла савытта ликер, шәраб, шифалы су, җиләк-җимеш суы кушып ясала*)
bolalmak *ф.* күбәю
bolero *и.* 1) җиңсез жакет; 2) авыр ритмлы бер испан биюе һәм аның музыкасы
boliçe *и. сөйл.* яһүди хатыны
bollanmak *ф.* күбәю, ишәю; киңәю
bollatmak, **bollaştırmak** *ф.* мул итү, киңәйтү
bolluk *и.* муллык; киңлек
bolşevik *и.* большевик
bolşevizm *и.* большевизм
bom *и.* комарлы уен тере
bomba I *и.* бомба
bomba II *и. диңг.* аскы горизонталь мачта, бүрәнә (*җилкәнне бөтен киңлегеңдә ачу өчен кулланыла*)
bombalamak *ф.* бомбалау
bombardıman *и.* бомбага тоту □ **bombardıman uçağı** бомбалау самолеты
bombardon *и.* оркестрда иң калын тавышлы тынлы музыка коралы
bombe *с. и.* 1) шешенке; 2) шешенкелек
bombeli *с.* шешенкеле
bonbon *и.* кәнфит
boncuk *и.* 1) муенса төймәсе, сәйләп; 2) кечкенә түгәрәк тамчы ◊ **boncuk gibi** кечкенә (*күз*)
boncuklanmak *ф.* тамчылану (*күз яше, тир, чык һ. б. тур.*)
bone *и.* француз кәпәче
bonfile *и.* филе (*бил ите*)
bonjur *и.* бонжур; хәерле көн
bonkör *с.* изгелекле; юмарт
bonkörlük *и.* изгелек; изгелеклелек, юмартлык
bonmarşe *и.* зур кибет, универмаг
bono *и.* (*вакыты һәм кулына тапшырылырга тиешле кешесе күрсәтелгән*) акча документы, бон

bonservis *и.* мәслихәт кәгазе, (*эшләгән җирдән яхшы эшләгәнлек тур.*) раслама документы, рекомендация
bor I *и. сөйл.* чирәм җир, сөрелмәгән җир
bor *и. хим.* бор
bora *и.* көчле яңгырлы җил
borağan *и.* буран
borak *и.* сөрелмәгән җир
boralı *с.* җилле-давыллы һәм яңгырлы
boran *и.* яңгырлы өермә, көчле яшенле яңгыр
borani *и.* дөге һәм шпинаттан катык кушып пешерелгән ашамлык
borat *и. хим.* бор тозы
borazan *и.* курайның бер төре
borazancı *и.* курайчы
borç *и. төрле мәгъ.* Бурыч □ **borç almak** бурычка алу; **borç bilmek** бурыч дип белү; **borç harç** һәртөрле бурыч-үтечләр; **borcunu bilmek** бурычын вакытында үтәү; **borcunu kapatmak** бурычын түләп бетерү
borç *и. кулин.* борщ, *нарын диал.*
borçlanmak *ф.* бурычлану
borçlu *с. төрле мәгъ.* бурычлы
borçsuz *с.* бурычсыз
borçsuzluk *и.* бурычсызлык
borda *и. диңг.* борт (*корабта, көймәдә һ. б.*)
bordo *с.* бордо төсе
bordür *и.* бордюр
borina *и.* җилкәннәрне тарттырып торган аркан
borsa *и.* биржа
borsacı *и.* биржачы
boru *и.* 1) торба, труба; 2) быргы ◊ **borusu ötmek** сүзе үтү
boruyolu *и.* нефтьүткәргеч
bostan *и.* 1) яшелчә бакчасы; 2) кавын-карбыз басуы ◊ **bostan korkuluğu** карачкы
devirmek ф. 1) аудару, түңкәрү, түнтәрү; 2) *күч.* бәреп төшерү (*мәс., патшаны*); түнтәрү, 3) *күч.* янтайту; *şapkasını bir yana devirdi* бүреген бер якка янтайтты
devleşmek *ф.* зураю
devlet *и.* 1) дәүләт, бәйсез ил, мәмләкәт; 2) хөкүмәт; 3) *күч.* бәхет, уңыш
devletçilik *и.* дәүләтчелек

devletlerarası *с.* илләрара, илара, дәүләтара
devletleştirmek *ф.* дәүләтләштерү, дәүләт милке итү
devre *и.* 1) чор; 2) электр челтәре
devretmek *ф.* 1) әйләнү, әйләнү-тулгану; 2) *төрле мәгъ.* күчерү, аудару; 3) (*товар*) алмашу; 4) башыннан ахырына кадәр (*уку, карау һ. б.*)
devrik *с.* 1) катланган,; 2) ауган; 3) *күч.* бәреп төшерелгән (*патша һ. б.*) □ **devrik cümle** җөмлә кисәкләренең гадәти урыны үзгәртелгән җөмлә (*мәс., алдым барып*)
devrilmek *ф.* 1) катлану, бөгелү; 2) мәтәлү, барып төшү
devrim *и.* 1) катлам, катлау, катлану; бөгелү; 2) революция; путч; фетнә (*дәүләт эчендәге кискен үзгәреш*)
devritmek *ф.* 1) катлау, бөгү; 2) мәтәлдерү, чөйкәлтү
devşirmek *ф.* 1) җыеп алу, җыю; 2) төрү
devşirilmek ф. 1) җыелу; 2) төрелү
deyim *и.* 1) әйтү; 2) әйтем; 3) фразеология
deyiş *и.* 1) әйтү рәвеше; 2) *әд.* (*халык иҗатында*) әйтеш; 3) сөйләү, аңлату
dımdızlak *с.* шәп-шәрә, яп-ялангач
dırdır *иярт.* лыгыр-лыгыр, лыкы-лыкы (*сөйләшү*)
dırıltı *и.* 1) лыгырдау, лыкылдау; 2) чәкәләшү
dırlanmek *ф.* лыгырдау, лыкылдау, такылдау
dış I *и.* тыш, тышкы як; чит, кырый; *şehrin dışı* шәһәр чите
dış *с.* 1) тыш, тышкы; чит; 2) чит илләр белән бәйле; *dış gezi* чит илгә сәяхәт
dışarı, **dışarısı** *и.* 1) тыш, өйдән читтәге җир; *dışarıda yağmur yağıyor* тышта яңгыр ява; 2) чит өлкә, чит ил; *dışarıyla iyi geçinmek* чит илләр белән яхшы мөнәсәбәттә яшәү
dışarlık *и.* провинция җире
dışişleri *с.* чит илләргә караган, чит илләр белән бәйле
dibek *и.* киле; зур (*механизмлы*) киле, изгеч
didik didik *с.* тетелгән, тетелеп беткән
didiklemek *ф.* 1) теткәләү, өзгәләү; 2) бөрчекләү, чемчекләү; 3) җентекләп тикшерү
didinmek *ф.* бар көченә тырышып эшләү
diferansiyel *и. төрле мәгъ.* дифференциал
difteri *и. мед.* дифтерия, дифтерит
diğer *с.* башка, бүтән, икенче
dik *с.* 1) вертикаль; үрә баскан, үрә торган; 2) текә; 3) *күч.* тупас, калын; *sesi dik* тавышы калын (көчле)
dikmek *ф.* 1) бастырып кую, текәү; 2) җиргә кадау, утырту; 3) (*йорт, бина*) салу, торгызу; 4) постка кую; 5) *күч.* туп-туры югары чөю; 6) *күч.* чөйкәлтеп әчү
dikdörtgen *и. мат.* турыпочмаклык
dikelmek *ф.* 1) текә булу; 2) аякта басып тору; 3) *күч.* тупаслык күрсәтү
diken *и.* 1) энә, чәнечке (*үсемлек һәм хайваннарда*); 2) тигәнәк; тигәнәле үлә; □ **diken diken** 1) чәнечкесе, энәсе күп булган; 2) тырпайган, үрә торган (*чәч, мыек, төк һ. б. ш.*)
dikence *и. зоол.* керпе балык
dikendutu *и.* бөрлегән
dikey *и.* вертикаль
dikici I *и.* игенче
dikici II *и.* 1) искене төзәтеп тегүче; 2) тегүче
dikilmek *ф.* 1) утыртылу, бастырып куелу; 2) (*яшь агач һ. б.*) утыртылу; 3) килеп басу, торып басу; 4) текәлү; 5) *күч.* каршы куелу
dikili *с.* үрә бастырылган (*багана, таш һ. б.*); утыртылган, кагылган ◊ **dikili ağacı**

olmamak каккан казыгы да булмау, мал-мөлкәтсез булу
dikim *и.* 1) тегү эше; 2) үсемлек утырту □ **dikim evi** тегү цехы; тегү фабрикасы
dikine *рәв.* 1) үрә бастырып, тек куеп; 2) *күч.* каршы куеп
dikiş *и.* 1) тегү, тегү эше; 2) тегеләсе әйбер; 3) җөй; 4) тегеш, тегү рәвеше
dikişçi *и.* тегүче
dikit *и.* сталагмит
dikiz *и.* күзәтү, күзәтке □ **dikiz aynası** (*шоферның һ. б.*) күзәтү көзгесе
dikizlemek *ф.* (*яшертен, посып*) күзәтү
dikkat *и. төрле мәгъ.* диккать, игътибар; *dikkatle dinlemek* игътибар белән тыңлау; *dikkat!* игътибар!
dikkatli *с.* дикъкатьле, игътибарлы
dikkatsiz *с.* дикъкатьсез, игътибарсыз
diklemesine *рәв.* вертикаль рәвештә
diklenmek, **dikleşmek** *ф.* 1) күтәрелү, текәләнү; *yol dikleşti* үр башланды; 2) *күч.* каршы төшү (килү)
dikmelik *и.* күчереп утыртылган агачлык
dikse *и.* (*кош аулау өчен*) өстенә сагыз сыланган ботак (таяк һ. б. ш.)
diksiyon *и.* дикция
dikta *и.* диктат
diktatör *и.* диктатор
dikte *и.* диктант
dil *и. төрле мәгъ.* тел ◊ **dil uzatmak** каршы сүз әйтү; **dilini bağlamak** сүзсез калырга мәҗбүр итү; **dillini tutmak** телен тыю, сүзен үлчәп сөйләшү
dilmek *ф.* телү; яру
dilbaz *и.* йомшак телле
dilber *с.* күңелне тартучы, сөйкемле; гүзәл; дилбәр *иск.*
dilbilgisi *и.* тел белеме (гыйлеме)
dilbilimi *и.* чагыштырма тел гыйлеме
dilci *и.* телче, тел белгече
dilemek *ф.* 1) үтенү; 2) теләү
dilek *и.* 1) үтенеч; 2) теләк
dilekçe *и.* гариза; үтенеч кәгазе
dilenmek *ф.* теләнү
dilenci *и. с. төрле мәгъ.* теләнче
dilendirmek *ф.* теләндерү
dilim *и.* телем
dilimlemek *ф.* телемләү; телү
dillenmek *ф.* 1) телгә килү; 2) (*бала*) сөйләшә башлау; 3) *күч.* телгә керү, аты-чабы чыгу
dillendirmek *ф.* (*берәрсе хакында*) сүз чыгуга сәбәпче булу
dillendirme *и.* 1) атын-чабын чыгару; 2) *әд.* җанландыру
dilli *с.* телдар; шома телле (*оста һәм матур сөйләшүче*)
dillidüdök *и.* 1) курай; 2) *күч.* күп сөйләшкән кеше
dilmaç *и.* тылмач, тәрҗемәче
dilsiz *с.* телсез
dimdik *с. рәв.* 1) теп-текә; 2) туп-туры; төз
din I *и.* 1) дин; *müslüman dini* мөселман дини; 2) инаныч
din II *и. физ.* дин (*көч үлчәү берәмлеге*)
dinmek *ф.* тыну; тынычлану; туктау; *göz yaşlarım dindi* күз яшьләрем (*агудан*) *туктады*
dinç *с.* 1) сау-сәламәт; хасталыксыз; 2) таза, көчле
dinçlik *и.* сәламәтлек, исәнлек; күңел (җан) тынычлыгы

dindar *и.* диндар, тәкъва
dindaş *с.* диндәш
dindışı *с.* дин белән бәйле булмаган
dinen *рәв.* дин буенча, дин кушканча, динчә
dingil *и.* күчәр; төңгел *диал.*
dingildemek *ф.* 1) тетрәү, уйнаклау; 2) *күч.* курку
dingin *с.* 1) хәрәкәтсез; 2) арыган, талчыккан
dinî *с.* дини, дингә баглы
diniş *и.* тыну, тынычлану
dink *и.* төйгеч, тукмак
dinlemek *ф. төрле мәгъ.* тыңлау
dinlenmek *ф.* 1) тыну, тынып тору; 2) ял итү
dinlendirmek *ф.* 1) тын алдыру, ял иттерү; 2) *сөйл.* сүндерү; 3) (*җирне*) парга калдыру
dinlendirici *и.* тынычлык бирә торган
dinlenme *и. яп* итү, *яп* алу; **dinlenme kampı** ял лагеры, ял базасы
dinletmek *ф. төрле мәгъ.* тыңлату; ишеттерү
dinleyici *и.* ирекле тыңлаучы
dinsiz *с.* динсез, дәһри
dinozor *и.* динозавр
dip *и.* 1) *төрле мәгъ.* төп; *deniz dibi* диңгез төбе; *tencerenin dibi* кәстрүлнең төбе; 2) түр; *salonun dibindeki masalar* залның түрендәге өстәлләр
dipçik *и.* приклад, кундак
dipkoçanı *и.* төпсә (*ертып алынган документтан калган төп*)
diploma *и.* диплом
diploması *и.* дипломатия
diplomatik *с.* дипломатик
dipnot *и.* текст астына төшерелгән искәрмә
dipsiz *с. төрле мәгъ.* төпсез
dirayet *и.* булдыклылык
dirayetli *с.* булдыклы
diremek *ф.* 1) *сөйл.* сөяү, терәү; 2) *күч.* киреләнү
direk *и.* 1) терәк, терәү; колга; 2) *күч.* терәк, таяныч; *baba ailenin direğidir* ата кеше — гаиләнең терәге
direksiyon *и.* 1) руль тәгәрмәче; 2) рульле идарә
direkt *рәв.* турыдан-туры
direktif *и.* директива, күрсәтмә
direktör *и.* директор
diren *и.* ике-өч япьле зур сәнәк, салам сәнәге
direnmek *ф.* каршылык күрсәтү, аяк терәп карышу
direnç *и.* 1) каршылык көче; 2) *физ.* электр каршылыгы
dirençli *и.* 1) тотрыклы; 2) куәтле
direniş *и.* каршылык күрсәтү
direşmek *ф.* үҗәтләнү, тырышу
direy *и.* зоол. хайваннар дөньясы, фауна
diri *с.* 1) тере, терек, җанлы; 2) яхшылап пешмәгән, чи; 3) тере, теремек, терчә; 4) сулмаган; *diri yaprak* сулмаган яфрак
dirilmek *ф.* 1) терелү; җанлану; 2) теремекләнү, көчәю
diriltici *с.* терелткеч, терелтүче
dirim *и.* тереклек, биологик яшәү
dirlik *и.* 1) *сөйл.* тереклек, яшәү, тормыш кичерү; 2) *тар.* тормыш кирәге, кирәк-ярак; 3) татулык ◊ **dirlik yüzü görmemek** рәхәт күрмәү

dirliksiz *с.* татулыксыз; тынычсыз
dirsek *и.* 1) *төрле мәгъ.* терсәк; 2) бөгелеш, бөгелгән төш ◊ **dirsek çürütmek** бик күп еллар уку (белем алу)
dirseklemek *ф.* терсәк белән төртү
dirseklik *и.* 1) кәкре ныгыткы, кәкре деталь; 2) култыкса; 3) җиңсә; терсәк турысындагы ямау
disiplin *и. төрле мәгъ.* дисциплина
disk *и. төрле мәгъ.* диск
diskalifiye *и.* дисквалификация
disko *и. к.:* **diskotek**
diskotek *и.* дискотека
dispanser *и.* диспансер
diş *и. төрле мәгъ.* теш; *diş ağrısı* теш авыртуы; *diş dolusu* пломба; *bir diş sarımsak* бер теш сарымсак □ **diş eti** урт
dişçi *и.* теш табибы, теш врачы
dişi *с.* теше, инәк, ана (*җан иясе, хайван*); *dişi kedi* ана *мәче*
dişlemek *ф.* тешләү
dişlek *с.* 1) тешләре чыгып торган, тешләч; 2) *күч.* үз сүзен сүз итә торган
dişli *с. төрле мәгъ.* тешле
dişsiz *с.* 1) тешсез; 2) *күч.* юаш
ditmek *ф.* тетү; вак кисәкләргә өзгәләү
divan I *и.* 1) *тар.* диван, дәүләт советы (*шурасы*); 2) *әд.* диван (*бер шагыйрьнең шигырьләр җыентыгы*)
divan II *и.* диван, софа
divane *и. с.* дивана, тиле; ахмак
diyafram *и. анат.* диафрагма
diyalekt *и.* диалект
diyalog *и.* диалог
diyanet *и.* 1) диянәт, дин эшләре; 2) дингә баглылык, динчелек
diyar *и.* төбәк, өлкә, регион
diye *рәв.* дип (*диеп*), дия
diyecek *и.* әйтер сүз; *başka diyeceğiniz var mı?* башка әйтер сүзегез бармы?
diz *и.* тез □ **diz boyu** тездән (*мәс., кар*); **diz kapağı** тез капкачы ◊ **deze gelmek** тезләнү, баш ию
dizmek *ф.* тезү
dize *и.* шигырь юлы
dızenteri *и. мед.* дизентерия
dizel *и. тех.* дизель
dizgi *и.* хәреф җыю
dizgin *и.* тезген ◊ **dizginleri salıvermek** дилбегәне бушату
dizginlemek *ф.* 1) тезгенләү; 2) *күч.* тыеп тору
dizginsiz *с. төрле мәгъ.* тезгенсез
dizi *и.* 1) тезмә, тезем; рәт, саф; *iki dizi inci* ике рәт энҗе; 2) *мат.* прогрессия; **dizi film се**риал
dizilmek ф. тезелү
dizili *с.* тезүле; тезмәле; теземле
diziliş *и.* тезелеш
dizlik *и.* 1) тезлек, тез каплагыч; 2) *сөйл.* тезгә кадәр төшеп торган эчке күлмәк; 3) *сөйл.* эш алъяпкычы
doçent *и.* доцент
dogma *и.* догма
doğmak *ф.* туу, дөньяга килү; барлыкка килү

doğa *и.* табигать □ **doğa yasası** табигать законы
doğal *с.* табигатькә багланышлы; табигый; *doğal gaz* табигый газ □ **doğal ayıklanma** табигый сайланыш
doğan *и.* лачын
doğancı *и.* лачынчы (*аучы*)
doğdurmak *ф.* тудыру
doğramak *ф.* турау
doğram *и. сөйл.* кисәк, туралган кисәк
doğrama *и.* агачтан (*тактадан*) ясалган әйберләр (*җиһазлар*)
doğranmak *ф.* 1) киселү, туралу; 2) *күч.* сызлау
doğru I *с.* 1) туры; 2) дөрес; хатасыз; 3) турылыклы; тугры, хыянәтсез; *doğru karar* дөрес карар; *doğru söylemek* дөрес сөйләү
doğru II *и.* 1) дөреслек; 2) *мат.* туры, туры сызык
doğru III *бәйл,* таба; *iskeleye doğru* искәләгә (*пристаньга*) таба
doğruca 1. *рәв.* турыдан; туп-туры. 2. *с.* шактый туры
doğrucu *и.* һәрвакыт дөресен сөйләүче
doğrulmak *ф.* 1) тураю, төзәлү; 2) туры юнәлү; туп-туры юнәлү; юнәлү; 3) күтәрелү, калку; 4) *күч.* яңадан күтәрелү, көчәю
doğrulamak *ф.* 1) дөресләү, дөресен әйтү (әйтеп бирү); 2) дәреслек табу өчен тикшерү
doğruluk *и.* 1) төзлек, турылык; 2) дөреслек; хатасызлык; 3) тугрылык; хәйләсезлек
doğrusu *кер. сүз.* турысы, дөресе; чынлыкта
doğu *и. с.* 1) көнчыгыш, кояш чыгышы; 2) көнчыгыш, шәрык
doğulu *с.* көнчыгыш кешесе, шәрык кешесе
doğum *и.* 1) туу, туу хәле; 2) туган ел (вакыт); 3) туым (*бала туу саны, проценты һ. б.*), туыш □ **doğum evi** бала табу йорты; **doğum gönü** туган көн
doğumlu *с.* (*фәлән вакытта*) туган; *1970 doğumlular* 1970 елгылар, 1970 елда туганнар
doğurmak *ф.* 1) тудыру, бала табу; 2) тудыру, барлыкка китерү; иҗат итү
doğurgan *с.* 1) күп бала табучы, күп (еш) тудыручы; 2) *күч.* иҗатчан, күп әсәр иҗат иткән
doğuş *и.* туыш, тумыш
doğuştan *рәв.* тумыштан
dok *и.* док (*портның йөк санлау һәм бушату, кораб ремонтлау өлеше*)
doksan *и.* туксан
doksanlık *и. с.* 1) *төрле мәгъ.* туксанлык; 2) туксан яшьлек; *doksanlık bir ihtiyar* туксан яшьлек бер карт
doktor *и.* доктор, табиб, врач
doktora *и.* 1) докторлык дәрәҗәсен яклау; 2) докторлык (*гыйльми дәрәҗә*)
doktrin доктрина, тәгълимат
doku *и. биол.* тукыма, организмда күзәнәкләр береге
dokumak *ф.* 1) туку; 2) *күч.* агачны селкетеп җимешләрен төшерү
dokuma 1. *и.* 1) туку; *halı dokuma sanatı* келәм туку сәнгате; 2) бәз, тукыма. 2. *с.* тукылган
dokumacı *и.* тукучы, тукучылыкта эшләүче
dokunaklı *и.* тәэсирле, йогынтылы; *dokunaklı bir söz təəsirle* бер сүз
dokunca *и.* зарарлы нәрсә
dokundurmak *и.* тидерү, тидертү
dokunmak ф, 1) *төрле мәгъ.* тию (*кул һ. б.*) тидерү, кагылу; 2) начар тәэсир ясау; кагылу, тию; *hırsız giyimlere dokunmamış* карак киемнәргә кагылмаган; *belki sana bir yardımı dokunur* бәлки сиңа бер ярдәме тияр

dokunulmaz *с.* 1) тиелгесез, кагылгысыз; 2) *күч.* тел тидергесез
dokunum *и.* сизү, тою
dokunuş I *и.* кагылыш
dokunuş *и.* тукылыш
dokurcun *и.* 1) тугызташ уены (*тугыз таш белән уйнала*); 2) тугыз көлтә өстенә унынчысын баштүбән куеп өелгән бәпкә
dokuz *сан.* тугыз
dokuzlu *и. с.* тугызлы
doküman *и.* документ
dolmak *ф.* 1) тулу; 2) тәмамлану
dolamak *ф.* урау, урату, чолгау, чорнау; сару
dolak *и.* 1) чолгау; 2) *сөйл.* юка шарф, яулык
dolam *и.* урам, уратым; чорнам
dolama *и.* 1) ачык җилән; 2) *мед.* тырнак асты үлекләү (авыруы)
dolambaç *и.* лабиринт
dolanmak *ф.* 1) әйләнеп чыгу, әйләнеп йөрү, тулгану; чолгану, сарылу; 2) йөренү
dolandırıcı *с. и.* бутаучы; хәйләче
dolap *и.* 1) шкаф, шифоньер; 2) базар эчендәге кибет, киоск; 3) барабанлы кое чарыгы (куласасы); 4) чарык, чыгыр, куласа; 5) *күч.* хәйлә, әмәл
dolaplı *с.* шкафлы
dolar *и.* доллар
dolaşmak *ф.* 1) әйләнеп (*әйләнеп-тулганып*) йөрү; 2) гизү, сәяхәт итү; 3) (*сүз, хәбәр һ. б.*)йөрү; 4) үрелү, ишелү, чырмашу; 5) әйләнечтән йөрү; 6) әрле-бирле йөренү
dolaşık *с.* 1) борылмалы, бөгелмәле; 2) бер-беренә сарылган, үрелгән, ишелгән; 3) буталган (*сүз һ. б. ш.*)
dolaşım *и.* 1) кан әйләнеше; 2) әйләнеш, бер юлдан әйләнеп йөрү
dolay *и.* әйләнә-тирә, тирә-юнь, әтраф, мохит
dolayı I *и.* 1) тирә-юнь; 2) даирә, тирәлек; 3) мөнәсәбәт
dolayı *бәйл.* сәбәпле, аркасында; *parasızlıktan dolayı* акчасызлык (*акча булмау*) аркасында
dolayısıyla 1. *рәв.* кыеклатып. 2. *бәйл.* сәбәпле, аркасында
dolaylı *с. рәв.* кыеклатып, читләтеп; тирәләп (*сорашу һ. б.*); *кыек*; **dolaylı tümleç** *гр. кыек* тәмамлык
dolaysız *рәв. с.* турыдан-туры; туры
doldurmak *ф. төрле мәгъ.* тутыру
doldurma *и.* 1) тутыру; 2) *әд.* артык һәм урынсыз тасвирлаулар (чагыштырулар) ярдәмендә хикәяләү
dolgu *и.* тутырма, нинди дә булса буш (тишек һ. б. ш.) урынга тутырыла торган нәрсә; *diş dolgusu* теш пломбасы
dolgun *с.* 1) тулы, тулган, тутырылган; 2) тулымса (*кеше*), тулы (*гәүдәле*)
dolgunluk *и.* тулылык
dolma I *и.* 1) тулу; 2) тулма (*татлы борыч, кәбестә яфрагы һ. б.ны ит, ярма белән тутырып пешерелгән ашамлык*)
dolma II *с.* чокырга таш (*балчык, ком һ. б.*) тутырып ясалган (*басу, бакча*)
dolmuş I *с.* 1) тулган, тулы; 2) тулышкан
dolmuş II *и.* 1) кеше тулгач (кеше җыелгач) кына юлына китә торган көймә; 2) шәһәр *эчендә* һәм шәһәртирә йөри торган кечкенә автобус (*минибус*)
dolu I *с.* 1) *төрле мәгъ.* тулы; 2) корылган, корулы (*мылтык һ. б.*); 3) мәшгуль; буш вакыты юк; *bu gön do/uyum* бүген буш вакытым юк
dolu II *и.* боз (*яву*)
dolunay *и.* тулган ай

domalmak *ф.* тумпаю, бүселү, бүлтәү
domalan *и.* томалан (*ашарга яраклы гөмбә*), трюфель
domates *и.* томат; помидор
dombay *и. зоол. сөйл.* бегемот
domino *и. төрле мәгъ.* домино
domuz *и.* дуңгыз, чучка ◊ **domuz ayağı** штопор; **domuz elması** җир астында үсә торган гөмбә төре
don I *и.* 1) һәртөрле кием, кием-салым; 2) ыштан; 3) атның төсе
don II *и. с.*1) суык, салкыннар; 2) туң; кырау □ **don kesmek** кырау сугу; **don yağı** 1) туңмай; 2) *күч.* сөйкемсез кеше
donmak *ф.*1) туңу; 2) өшү; 3) *күч.* шаккату
donamak *ф.* бизәү (*матур киендерү*)
donanmak *ф.* 1) киенү, бизәнү; 2) бәйрәм билгеләрен чыгарып кую
donanım *и.* 1) *диңг.* такелаж (*җилкәнле кораб, зур көймә өстендәге бөтен җиһаз, йөреш кирәк-ярагы*); 2) җиһаз; *soğutma donanımı* суыту җиһазы
donanma *и.* 1) бәйрәм һәм тантаналарда күрсәтелгән бизәкләр (байраклар һ. б.); 2) диңгез флоты; *ticaret donanması* сәүдә флоты
donatmak *ф.* 1) киендерү; 2) бизәү, матурлау; 3) бәйрәм билгеләрен күрсәтү, рәешләү; 4) *күч.* ачулану
donatım *и.* җиһазлау; бизәү
dondurmak *ф.* 1) туңдыру; 2) *күч.* торгын хәлендә калдыру, үзгәрешсез тоту; *fiyattan dondurmak* бәяләрне үзгәрешсез тоту
dondurma I *и.* туңдыру
dondurma II *и.* туңдырма, морожный
donra I *и.* тундра
donra II *и.* 1) кавык; 2) кер (*тәндә*)
donsuz *с.* киемсез, ялангач
donuk *с.* 1) туң, туңган; 2) тонык (*төс*); 3) *күч.* туң, хиссез;
dopdolu *с.* туп-тулы
doru *с.* туры (*ат*); кызгылт җирән
doruk *и.* 1) тау түбәсе, агач башы; 2) *күч.* (*вакыйганың, уңышның һ. б.*) иң югары ноктасы
doruklamak *ф.* түбәләмә итү
dost *и.* дус, дуст ◊ **dost tutmak** сөяркә тоту
dostane *рәв.* дусларча, дустанә *кит.*
dostluk *и.* дуслык
dosya *и.* 1) досье; 2) папка, кәгазь папкасы
doymak *ф.* тую □ **doya doya** туйганчы
doygun *с.* туйган, канәгать
doymaz *с.* туймас, ачкүз
doyulmak *ф.* туену
doyum *и.* тую, туену; □ **doyum olmamak** туйгысыз булу
doyumluk *и.* 1) туярлык; 2) *тар.* чапкын, талау һөҗүме
doyurmak *ф.* 1) туйдыру, туендырып тору; 2) *күч.* алдау; 3) *күч.* акча төртү
doyuran *и. физ.* туендыручы матдә
doyurucu *с.* 1) туендыргыч (матдә); 2) *күч.* канәгать калырлык
doz *и.* доза
dökmek ф. 1) агызу; *su dökmek* су агызу; 2) түгү, түгеп җибәрү; *çayı dökmek* чәйне түгеп җибәрү; 3) бушату; *buğdayı dökmek* бодайны бушату; 4) сибү; *tavuklara yem dökmek* тавыкларга җим сибү; 5) *күч.* түгү, кою; *göz yaşı dökmek* күз яше түгү; *yapraklarını dökmüş ağaç* яфракларын койган агач; *para dökmek* акча түгү; 6) *күч.* күп итеп җыю, туплау; *sınıra asker dökmek* чик буена гаскәр

туплау; 7) *күч.* бушату; *dert dökmek эчне* бушату □ **döke saça** чәчә-түгә

dökme I *и.* түгү

dökme *с.* 1) эретеп калыпка салу юлы белән ясалган; 2) түгелгән, агызылган; 3) капларга салынмаган, чәчелеп яисә өелеп яткан; сибелеп яткан

dökük *с.* 1) сибелеп торган; төшеп торган; *saçları omuzlarına dökük* чәчләре иңбашларына төшкән; 2) искергән

dökülmek ф. 1) түгелү, бушатылу; 2) *төрле мәгъ.* коелу, сибелү; 3) *күч.* бик нык искерү

döküm *и.* 1) (*чуенны һ. б.*) эретеп калыпларга агызу; (*чуен һ.* б.) кою; 2) (*тукыманың, киемнең*) салынып тору; 3) җентекле итеп аңлату; 4) яфрак коелу вакыты; **döküm evi** кою цехы

dökümcü *и.* (*чуен һ. б.*) коючы

döküntü *и.* 1) түгенте, чүп-чар; 2) калдык-постык (*тар-мар ителгән гаскәр һ. б. калдыклары*); 3) биткә чыккан таплар, бетчәләр; 4) *күч.* эшкә яраксыз нәрсә

döl *и.* 1) тул; яралгы; 2) ыру, нәсел, җәвер □ **döl yatağı** *анат.* аналык

dölek *с.* 1) тыныч холыклы, ипле, түләк *иск.*; 2) төз, тигез (*җир*)

döllemek *ф.* яралгы ясалу

dönmek *ф.* 1) үз күчәре яисә бер үзәк тирәли әйләнү; 2) әйләнеп кайту, түнү; 3) әверелү, үзгәрү; 4) дүнү, ниятеннән (карашыннан) ваз кичү; 5) борылу, йөз тоту; 6) (*укучы тур.*) сыйныфта (класста) калу □ **döne döne** тәгәри-тәгәри

döndürmek *ф.* 1) әйләндерү; 2) түндерү; 3) *күч.* идарә итү, тәртиптә тоту

dönek *с.* аумакай

dönelmek *ф.* (*югары күтәрелгәннән соң*) тешә башлау

dönem *и.* чор, дәвер

dönemeç *и.* 1) борылу төше, борылыш; 2) үзгәреш ноктасы

dönenmek *и.* әйләнү, әйләнгәләү, әйләнеп йөрү

dönence *и.* тропик параллельләрнең берсе

döner 1. *и.* дөнәр (*әйләнгеч шештә пешерелгән ит, шешлек*). 2. *с.* әйләнә торган

döngel *и. бот.* мушмула, башмала

dönük *с.* 1) кире борылган; 2) *күч.* юнәлдерелгән

dönüm I *и.* 1000 м^2 лык мәйдан үлчәве

dönüm II *и.* 1) әйләнү, әйләнгәләү; 2) (*табигатьтә, җәмгыятьтә кабатланып торган*) күренешләрнең берсенең тәмамланып, икенчесенең башлануы; *yıl dönümü* ел тулу; 3) кабатлана торган хәрәкәтнең һәр юлы; *iki dönüm yük getirdi* ике юл йөк китерде

dönüşmek *ф.* үзгәрү, әверелү

dönüşlü *с.* 1) кайтмалы; 2) *гр.* кайтым юнәлеше булган (*фигыль*)

dönüştürmek *ф.* 1) үзгәртү, әверелдерү; 2) *мат.* үзгәртелү

dönüşüm *и.* формасы үзгәрү (үзгәртелү); бер үк эчтәлекнең төрле формаларда чагылышы

dördül *и.* 1) дүртпочмак, квадрат; 2) *әд.* робагый, дүртьюллык

dördüz *сан. с.* дүртәү, дүртле

dört *сан.* дүрт ◊ **dört gözle beklemek** дүрт күз белән көтү

dörtgen *и.* дүртпочмак

dörtleme I *и.* дүртләү, дүртәрләү

dörtleme *и.* 1) басуны дүрт тапкыр сөрү; 2) (*шагыйрьләр ярышында*) дүртьюллыклың беренче ике юлын бер шагыйрь, калган икесен икенче шагыйрь язып иҗат итү ысулы

dörtnala *рәв.* чаптырып, бар көчкә

döş *и.* түш, күкрәк

döşemek *ф.* 1) түшәү, җәю; каплау; *kilim döşemek* келәм җәю; *çini döşemek* кафель түшәү, кафель белән каплау; 2) өйне җиһазлау

döşek *и.*) түшәк, ястык; 2) ятак, урын-җир
döşekli *с.* 1) түшәкле, түшәге булган; 2) *и.* җәенке (ялпак) көймә
döşeli *с.* 1) түшәүле; 2) *күч.* җиһазы тулы булган (*өй*)
döşeme *и.* 1) идән; 2) түшәмә, (*диван, урындык, һ. б.ның*) йомшак ител түшәп ясалган өлеше
döşemeli *с.* 1) түшәмәле; 2) җиһазлы (*өй, бүлмә*)
dövmek *ф.* 1) төю; 2) кыйнау, тукмау; 3) (*тимер*) чүкү; 4) кагу, суккалау; 5) тупка тоту, бомбалау
döveç *и. сөйл.* киле
döven *и.* ындырда иген суктыру *өчен* ат, үгез һ. б. белән җәем өстеннән тарттырыла торган таш
döviz *и.* 1) илләр арасында йөргән түләү васитасы (*акча, чек һ. б.*); 2) валюта, чит ил акчасы; 3) девиз, лозунг
dövme *и.* 1) төю; 2) кыйнау; 3) (*тимер*) чүкү; 4) татуировка □ **dövme yapmak** татуировка ясау
dövüş *и.* 1) төю; 2) кыйнашу
dövüşçü *и.* кыйнашчы
dövüşken *с.* сугышырга яратучы; сугыш чукмары
dragon I *и. тар.* драгун (*атлы гаскәр төре*)
dragon II *с.* аждаһа
drahmi *и.* драхма (*Грециядә кулланыла торган акча берәмлеге*)
dram *и. төрле мәгъ.* драма
dramatize etmek *ф.* драматизацияләү, фаҗига итеп күрсәтү
dua *и.* дога
duacı *и.* догачы
duba *и.* 1) баржа; 2) понтон
dublâj *и.* дубляж (*кинофильмне башка телгә күчерү*)
duble *и.* 1) нәрсәнең дә булса икеләтә артыгы; 2) икенче кат, киемнең алынмалы астары; 3) эчлек
dudak *и.* ирен ◊ **dudağını ısırmak** хәйран калу
dudaksıl *с. гр.* иренләшкән (*аваз*)
dudu *и.* 1) ханым; *Ayşe dudu* Гайшә ханым; 2) олы яшьтәге әрмән хатыны
dul *и. с.* тол (*хатын яисә ир*) □ **dul kalmak** тол калу
dulda *и.* 1) ышык җир; 2) яклау, химая
duldalamak *ф.* ышыклау
dulluk *и.* толлык
dumağı *и.* томау
duman *и.* 1) төтен; 2) тузан болыты
durmak *ф.* 1) *төрле мәгъ.* тору; 2) туктау, тукталу; *bileğimdeki saat durmuş* беләгемдәге сәгать туктаган; 3) яшәвен дәвам итү
durağan *с.* 1) хәрәкәтсез, тик торучан; 2) *күч.* артта калган
durak *и.* 1) тукталыш; 2) пауза
duraklamak *ф.* 1) тукталу, туктап тору; 2) *күч.* тынып тору, тынып калу
duraklı *с.* 1) тукталышлы; 2) *физ.* тотрыклы
duraksamak *ф.* икеләнеп калу
durdurmak *ф.* туктату; *otobüsü durdurdu* автобусны туктатты
durgun *с.* 1) тыныч, тымызык; 2) *күч.* сүнек, рухсыз
durgunlaşmak *ф.* 1) тымызыклану; 2) кәефсезләнү
durmadan *рәв.* бертуктамыйча
duru *с.* 1) чиста; *duru su* чиста су; *duru beyaz tenli* чиста ак тәнле; 2) *күч.* саф (*тел, ысул һ. б. тур.*)
duruk *с.* үзгәрмәгән; торгынлыктагы

durulamak *ф.* чиста суда чайкау
durum *и.* әхвәл, хәл; вәзгыять (*мәсьәләнең һ. б.*) ничек торуы; ничеклек
duruş *и.* 1) торыш; 2) күренеш
duruşma *и.* судта ике якның бергә килеп тикшерелүе
duş *и.* душ (*су коену җайланмасы*)
dut *и.* тут җиләге □ **dut ağacı** тут агачы; тут
duvak *и.* 1) кәләш бөркәнчеге; 2) йокылык (*кайбер яңа туган бәбиләрнең башындагы яры*), туак *диал.*
duvar *и.* дивар, таш койма, стена
duymak *ф.* 1) тою, сизү; 2) ишетү; 3) хис итү
duyar *с.* хисле
duygu *и.* 1) тойгы; 2) ишетү
duygulu *с.* 1) тойгылы, хисле; 2) сак; тавышны тиз ишеттерүчән; сизгер
duygusuz *с.* 1) тойгысыз; 2) сөмсез; туң
duymaz *с.* тоймас; ишетмәс
duyu *и.* тою (*организмнарның тышкы дөньядан сигналлар кабул итүе*)
duyum *и.* тоем, тою күренеше; апперцепция
düdük *и.* 1) кечкенә сыбызгы; 2) гудок
düğmek *ф.* төйнәү
düğme *и. төрле мәгъ.* төймә
düğmelemek *ф.* төймәләү
düğüm *и. төрле мәгъ.* төен
düğümlemek *ф.* төенләү
düğümlü *с.* 1) төенле; 2) ботаклы
düğün *и.* туй
düğüncü *и.* туйчы
düğünçorbası *и.* туй ашы (*шулпага ит, он, катык һәм кыздырылган май салына*)
dükkân *и.* 1) кибет, кечкенә кибет; 2) һөнәрче алачыгы
dükkâncı *и.* кибетче, кибет тотучы
düldül *и.* 1) дөлдөл; 2) *күч.* иске автомобиль
dülger *и.* (*оста*) балтачы
dümbelek *и.* (*кечкенә*) барабан
dümbelekçi *и.* барабанчы
dümdüz *с.* 1) төп-төз; 2) *күч.* бик гади, күрексез; 3) *күч.* беркатлы, артта калган, чикләнгән
dümen *и.* 1) (*су һәм һава транспортларында*) руль; 2) *күч.* хәйлә; астан идарә итү
dün 1. *и.* кичәге көн. 2. *рәв.* кичә
dünden *рәв.* 1) кичәдән; *dünden kalma yemek* кичә калган аш; 2) *сөйл.* күптәннән; *o dünden razı* ул күптән риза
dünkü *с.* 1) кичәге; 2) күптән түгелге; 3) *күч.* артта калган
dünür *и.* кода, кодагый
dünürcü *с.* башкода, кодалаучы
dünürleşmek *ф.* кодалашу
dünya *и.* 1) дөнья; 2) дөньяви эшләр (хәлләр); 3) җир шары
dünyada *рәв.* гомердә дә, һичбервакыт
dünyalık *и.* байлык; матди хәл
düpedüz *рәв. с.* 1) төп-төз; туп-туры; 2) ачыктан-ачык; 3) ачык, гади, садә; эчкерсез (*кеше*)
dürmek *ф.* төрү, катлау
dürbün *и.* бинокль
dürme *и.* 1) төрү; 2) кәбестәнең күпкатлы яфраклары; яфраклы кәбестә; 3) *кулин.* төрмә *(кыстыбыйның бер төре)*

dürmece *и. зоол.* кәбестә күбәләге
dörtmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* төртү, төртеп күрсәтү, төрттерү; 2) этәргеч бирү, кызыктыру
dürtüklemek *ф.* 1) төрткәләү; 2) (*күңелне, берәүне һ. б.*) кызыктырып тору, котырту
dürtülmek *ф.* (*барып*) төртелү
dürtüşmek *ф.* төртешү
dürü *и.* 1) төргәк; 2) бирнә, өшәнчек; туй бүләге
dürülü *с.* төрүле, төрелгән
dürüm *и.* катлама, катланма
dürüst *с. рәв.* дөрес, хатасыз
düş *и.* 1) төш; 2) хыял □ **düş görmek** төш күрү
düşmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* төшү; төшеп калу; килеп төшү, егылу, егылып төшү; 2) яву; 3) туры килү, килешеп тору
düşey *с. и.* вертикаль
düşkün *с.* 1) (*бер эшкә, нәрсәгә*) күңелен салган; яратучы; *sinema düşkünü* кино яратучы; 2) *күч.* мәлҗерәгән, алҗыган, хәлсез
düşman *и.* дошман
düşmanlık *и.* дошманлык
düşük *с.* 1) төшкән; төшерелгән; 2) түбән, аз; *düşük fiyat* түбән бәя
düşünmek *ф.* 1) уйлану; уйлау; 2) планлаштыру; җыену; 3) тикшерү; 4) хәтерләү
düşünce *и.* 1) төшенчә; уй; 2) аң; 3) гамь, ваем
düşünceli *с.* 1) аңлы; 2) гамьле, ваемлы
düşüncesiz *с.* 1) аңсыз; 2) гамьсез, ваемсыз
düşündürmek *ф.* 1) уйга калдыру, гамьләндерү; 2) кайгыга салу, кайгыландыру
düşünür *и.* фикер иясе
düşürmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* төшерү, төшереп җибәрү; 2) түбәнәйтү, киметү
düz I *с.* 1) тигез; шома; 2) сай
düz II *и.* 1) тигезлек; дала, тез *диал.*; 2) бер төрле исерткеч эчемлек
düzmek *ф.* 1) төзү; 2) ясау; 3) хәзерләү; *gelin çeyizi düzmek* килен бирнәсе хәзерләү
düzelmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* төзәлү; 2) тигезләнү
düzeltici *с. и.* 1) төзәтүче; 2) төзәткеч, төзәлткеч
düzen *и.* 1) тәртип; җыйнаклылык; 2) тәртипкә салынганлык; 3) режим; 4) система
düzenlemek ф. 1) тәртипкә салу; 2) (*музыкада*) көйләү, көйгә салу; 3) оештыру
düzenleyici *и.* 1) көйләүче, җайга салучы; 2) оештыручы
düzensiz *с.* 1) тәртипсез, җыйнаксыз; 2) аһәңсез; көйсез (*музыка*)
düzey *и.* кимәл; дәрәҗә; *kültür düzeyi* культура дәрәҗәсе
düzgün I *с.* 1) тигез; тигезләнгән; шомартылган; 2) көйләнгән, җайланган; 3) тәртипкә (көйгә, җайга) куелган
düzgün *и.* кершән
düzine *и.* дюжина, 12 данә
düzlemek *ф.* тигезләү
düzlem *и.* 1) тигез җир; 2) *мат.* яссылык
düzlük *и.* 1) тигезлек; 2) төзлек; 3) турылык
düzme *с.* уйдырма (сүз), ялган (*мәс., документ*)

E

e *ы.* алайса, алай
ebe *и.* 1) кендек әбисе (*сөйл.*); 2) дәү әни (*сөйл.*); 3. (*балалар уенында*) узаман
ebebulguru *и. сөйл.* кырпак кар
ebedî *с.* мәңгелек; әбәди (*иск.*)
ebedileşmek *ф.* мәңгеләшү

ebedilik, -ği (*-i*) *и.* мәңге булу, мәңгелек; чиксезлек; үлемсезлек
ebonit *и.* эбонит
ece *и.* 1) патшабикә, краличә; 2) (*сөйл.*) матур / чибәр хатын / кыз; матурлык краличәсе; 3) ана, әни, әнкәй
ecel *и.* әҗәл; үлем сәгате
eciş bücüş *с. рәв.* әҗе-бөҗе, әҗе-гөҗе *диал.*; тәртипсез, рәтсез; ничек җитте шулай
ecnebi 1. *с.* чит илдән килгән; **2**. *и.* чит ил кешесе, әҗнәби (*иск.*)
ecza *и.* дару, дәвалагыч матдә; **ecza dolabı** дару шкафы / долабы
eczacı *и.* даручы, дару сатучы; аптекачы
eczalı *с.* 1) дарулы; 2) махсус пакьләнгән, стериль
eczane *и.* даруханә, аптека, әҗзаханә
eda I *и.* 1) эшләү ысулы; 2) кыланыш; 3) кыланчыклану
eda II *и.* 1) үтәү; түләү; 2) башкару, булдыру; **eda etmek** башкарып чыгу, әда итү *иск.*
edalı *с.* 1) матур кыланышлы; 2) рәвешле; кыланчык, һавалы, назлы; 3) ыспай, кыланчык;
edat *и.* 1) кирәк-ярак, кирәкле вак-төяк; 2) *гр.* ярдәмлек сүз; кисәкчә
edebî *с.* әдәби
edebiyat *и.* әдәбият
edep, -bi *и.* әдәп □ **edep etmek** оялу, тартыну
edeplenmek *ф.* әдәпләнү
edepli *с.* әдәпле
edepsiz *с.* әдәпсез
edilgen *с. гр.* төшем, төшемле (*фигыль юнәлеше һ. б.*)
edip *и.* әдип
editör *и.* нәшир, нәшер итүче, нәшерче, нәшриятчы
efe *и.* 1. 1) *с.* батыр, кыю; йөрәкле; 2) (*Batı Anadolu'da*) булдыклы, өлгер, уңган чос егет; 2) *диал.* ага, агай;
efekt *и.* эффект
efendi *и.* 1) *иск.* укымышлы кеше; 2) *бәй* сүзеннән соң әйтелә торган (*икенче дәрәҗәле*) хөрмәтләп эндәшү сүзе; 3) *күч.* йомшак (нәзакәтле) кеше; ◊ **efendilik** *и.* 1) әфәнделек, әфәнде булу; 2) юмартлык
efendim *кис.* 1) "ни дидегез, ни әйттегез?" мәгънәсендә әйтелә; 2) әфәндем, әдәп һәм хөрмәт билгесе итеп әйткән сүзгә (жөмләгә) өстәмә
efil efil *рәв.* җилфер-җилфер; җиңелчә (генә), җай гына, җайлап (кына), сак кына
eflâtun *и.* ачык шәмәхә төс
eflâtunî *с.* 1) ачык шәмәхә; 2) платоник;
efsane *и.* 1) әкият, хикәят, риваять; борынгы халык әкиятләре; 2) *күч.* юк-бар сүз; уйдырма;
efsanevî *с.* легендар, әфсанәви, әкияти; мифик;
efsun *и.* әфсен, сихер; тылсымчылык, сихерчелек; тылсым
efsuncu *и.* әфсенче, сихерче
efsunlamak *ф.* әфсенләү
ege *и.* багавыл, опекун
egemen *с. и.* ия, хуҗа, баш
egemenlik *и.* 1) ия (хуҗа, баш) булу; 2) суверенитет
eğdirmek (*-i*) *ф.* авыштыру, янтайту; кырын салу
eğe *и.* игәү
eğeçi *и.* игәүче; игәүләүче
eğelemek (*-i*) *ф.* игәүләү
eğer *терк.* әгәр
eğiç *и. сөйл.* игеч, кәшәкә (*чикләвек һ. б. ш. җыяр өчен кәкрәйтелгән башлы таяк*)

eğik *с.* 1) иелгән; 2) авыш, кыеш
eğilmek *ф.* иелү, бөгелү; кыйшайтылу
eğim *и.* авышлык
eğin *и.* 1) иң, иңсә; җилкә ягы; 2) гәүдә
eğirmek *ф.* эрләү
eğitici *и.* мәгърифәтче; мәгарифче
eğitim *и.* 1) өйрәтү, укыту; мәгариф; 2) педагогика
eğitimci *и.* педагог
eğitmek *ф.* өйрәтү, укыту; тәрбияләү
eğlek *и.* 1) кунып чыгар өчен тукталган җир; 2) туплау, туплавык (*көтү туплана торган җир*)
eğlemek *ф.* 1) юату; күңелен ачу; 2) туктатып калу
eğlence *и.* 1) ирмәк, күңел ачу өчен эшләнгән нәрсә; 2) уен; 3) күңел ачу урыны
eğlenceli *с.* күңел ачу урыннары булган; күңел ачулы
eğlenmek ф. 1) вакыт үткәрү; 2) күңел ачу
eğmek (*-i*) *ф.* ию, бөгү, бөгелдерү; киерү
egoist *и.* эгоист
egoizm *и.* эгоизм
eğrelti *и. бот.* дәрмана үләне
eğreti *с.* 1) вакытлы; паллиатив; 2) ясалма (*мәс., теш, чәч һ. б.*); 3) ныгытылмаган
eğri *с. и.* 1) кәкре; кәкре-бөкре; 2) авыш; 3) ялгыш; 4) *мат.* кәкре-сызык ◊ **eğri bakmak** кыек карау
eğri-böğrü *с.* кәкре-бөкре
eğrilmek *ф.* кәкрәю
eğriltmek *ф.* кәкрәйтү, бөгү
egzotik *с.* экзотик
ehemmiyet *и.* әһәмият
ehli *с.* кулга ияләштерелгән, йортлашкан
ehliyet *и.* кулдан килү, көч, мөмкинлек
eh *ы.* әһ, их
ehram *и.* Мисыр пирамидасы
ejder, **ejderha** *и.* аждаһа
ек *и.* 1) өстәмә, кушымта; 2) кештәк, ямау; 3) *гр.* кушымча
екмек *ф.* 1) игү; 2) чәчү, утырту; 3) *күч.* чәчеп җибәрү, тарату
ekici *с. и.* игүче; игенче
ekilmek *ф.* игелү, (иген) чәчелү
ekili *с.* игүле, игелгән (*кыр, басу*)
ekim I *и.* игү, чәчү
ekim II *и.* октябрь
ekin *и. сөйл.* иген
ekinci *и.* игенче
ekincilik *и.* игенчелек
ekinlik *и.* басу, кыр
ekip *и.* 1) контингент, әһлия *кит.*; 2) команда, экипаж, төркем
eklemek *ф.* 1) өстәү, ялгау; 2) (*тегеп һ. б.*) беркетү
eklem *и. анат.* 1) тоташма; 2) буын
eklemeli *с.* ялгаулы
eklenti *и.* ялганма, өстәмә
ekleşmek *ф.* кушымчага әйләнү
ekli *с.* ямаулы, ялгаулы, өстәмәле
ekmek *и.* икмәк, ипи
ekoloji *и.* экология

ekonomi *и.* экономика
ekran *и.* экран
ekselans *и.* чит илдән килгән дәрәҗәле кеше, эксцеленц *кит.*
eksen *и.* (*сызымда, координатларда һ. б.*) күчәр
ekser *и. сөйл.* зур кадак, тимер чөй
ekseriyet *и.* күпчелек
eksi 1. *и. мат.* минус билгесе. 2. минуслы (*мәс., температура*); нольдән түбән
eksik *с. и.* 1) җитешсез, көтек; 2) әйбәт түгел; шәп түгел; 3) ким; кимчелекле; 4) җитешсезлек, кимчелек; **eksik çıkmak** ким чыгу
eksikli *с.* (*нәрсәгә дә булса*) мохтаҗ
eksiklik *и.* җитешсезлек, көтеклек; кимлек
eksiksiz *с.* кимчелексез; тулы
eksilmek *ф.* кимү
eksilen *с. мат.* кимүче сан
eksper *и.* эксперт
ekspres *и.* 1) экспресс; 2) *күч.* ашыгыч башкарылган эш
ekstra *с.* 1) экстра, иң яхшы; 2) аеруча югары, өстәүле (*бәя, түләүләр һ. б. ш.*)
ekşi *с.* 1) әче, әчкелтем (*мәс., лимон, әйрән*); 2) әче, әчегән ◊ **ekşi yüz** (**surat**) чытык йөз, сытык чырай
ekşimek *ф.* 1) әчү; әчешү; 2) ачу, ачып бозылу; 3) *сөйл.* (*йөзе*)*сы*-тылу, чытаю
el I *и.* 1) кул; кулның терсәктән бармак очларына кадәрге өлеше; 2) хайваннарның алгы аягы; 3) сап, кулса; 4) (*микъдар билгеләмәсе буларак*) уч; *bir el* бер уч; 5) нәүбәт, чират; 6) кул белән эшләнә торган әйберләрнең бер керешүдә эшләнгән кадәресе ◊ **el açmak** теләнү; **el altında** кул астында (якын гына); **el çırpmak** кул чабу, алкышлау; **el işi** кул эше; **el kaldırmak** кул күтәрү, сукмакчы булу; **el vermek** кул бирү, ярдәм кулы сузу; **el uzatmak** кул озайту; **elden gelmemek** кулдан килмәү; **ele geçmek** кулга керү, кулга төшү
el II *и.* 1) ил, өлкә; 2) халык
elâ *с.* коңгырт кара (*күз тур.*)
elaman *ы*. "гарык булдым" мәгънәсендә
elastik *с.* эластик
elbet, **elbette** *рәв.* әлбәт, әлбәттә
elbezi *и.* тастымал
elbise *и.* кием-салым
elbiselik *с.* күлмәклек; тукыма
elçi *и.* 1) илче; арадашчы; 2) пәйгамбәр
eldiven *и.* пирчәткә, иләсә *диал.*
elemek *ф.* 1) иләү; 2) *күч.* сайлап алу, сайлау; 3) *күч.* кемне дә булса җиңеп уеннан чыгару
elebaşı *и.* атаман; (*уеңда һ. б.*) узаман
eleğimsağma *и. сөйл.* салават күпере
elek *и.* иләк ◊ **elekten geçirmek** иләктән үткәрү
elektrik *и.* электр
elektrikli *с.* электрлы
elektriksiz *с.* электрсыз
elektromanyetik *с.* электромагнетик
elektromıknatıs *и.* электромагнит
elem *и.* 1) авырту, сызлау; 2) кайгы, хәсрәт
eleman *и.* 1) элемент, өлте; катлаулы бер нәрсәнең аерым өлешләреннән берсе; 2) әһел, билгеле бер җәмгыять һ. б. әгъзасы, билгеле бер катлам кешесе
elemli *с.* кайгылы, хәсрәтле; сызлаулы
eleştirmek *ф.* тикшерү; тәнкыйтьләү, тәнкыйть итү

eleştiri *и.* 1) (*нәрсәнең дә булса*) сыйфатын тикшерү; 2) тәнкыйть
eleştirici 1. *и.* тәнкыйтьче. 2. *с.* тәнкыйтьчән, тәнкыйтьчел
eleştirmeci *и.* тәнкыйтьче
elhak *рәв.* чыннан да
elhasıl *кер. сүз.* кыскасы, әлхасыйль
elifba *и.* әлифба (*гарәп хәрефләре алфавиты*)
elit *и.* элита
ellemek *ф.* кул белән тоткалау; кармалау
elleşmek ф. 1) кул көрәштерү; 2) *күч.* төртмәле сүз сөйләү; 3) кул биреп күрешү
elli I *с.* куллы, кулы булган
elli II *сан.* илле
ellilik *и.* иллелек
elma *и.* алма
elmabaş *и.* диңгез үрдәгенең бер төре
elmalı *с.* алмалы
elmas *и.* 1) алмаз; 2) кыйммәтле таш, асылташ
elmasiye *и.* желе
elti *и.* килендәш, килендәшләрнең бер-берсен атау сүзе
elvan 1. *и.* төсләр. 2. *с.* төрле төстәге
elveda *и.* 1) әлвидагъ, хушлашу сүзе; 2) бәхилләшү сүзе
elvermek *ф.* 1) җитәрлек булу, җитү; 2) ярашу; 3) җайлы яисә файдалы булу; 4) нәтиҗәгә китерү
elverişli *с.* 1) уңышлы; 2) җайлы, уңайлы; кулай, файдалы
elverişsiz *с.* 1) уңышсыз, нәтиҗәсез; 2) җайсыз, уңайсыз
em *и.* им, дару
emmek *ф.* 1) имү; 2) чөмерү; 3) суыру
emanet *и.* әманәт □ **emanet etmek** әманәт итү, сакларга тапшыру
emanetçi *и.* әманәтче; (*билгеле бер түләү бәрабәренә*) тапшырылган нәрсәне саклап торучы
emare *и.* (*судта һ. б.*) дәлил, таныклык, галәмәт
emay *и.* эмаль
emaye *с.* эмальле, эмальләнгән
emcek, **emcik** *и. сөйл.* имчәк; ими
emeç *и.* имгеч (*кайбер үсемлек һәм хайваннарның имү органы*)
emek *и.* 1) хезмәт; 2) эш хакы; 3) имгәк, азап, михнәт □ **emek harcamak** хезмәт кую
emekçi *и.* хезмәт иясе, хезмәт белән яшәүче (*кеше*)
emeklemek *ф.* 1) мүкәләү, мүкәләп йөрү; 2) *күч.* азаплану, маташу
emekli *с.* 1) зур хезмәт куелган; 2) пенсиядәге, пенсияле кеше □ **emekli olmak** пенсиягә чыгу
emeksiz *с.* 1) эшләмичә булдырылган; 2) *күч.* үги бала
emektar *с. и.* 1) күп хезмәт күрсәткән (кеше); 2) күп кулланылган, таушалган
emel *и.* 1) максат; 2) хирыс
emin *с.* 1) тыныч, имин; 2) шикләнүсез, шөбһәсез; 3) ышанычлы
emir I *и.* 1) әмер; 2) боерык
emir II *и.* әмир
emirlik *и.* әмирлек
emirname *и.* әмирнамә, боерык
emisyon *и.* эмиссия
emlâk *и.* 1) *тар.* иске Төркиядә дәүләт җирләре; 2) күчерелмәс милек (мөлкәт)
emlâkçi *и.* күчерелмәс милек белән сату итүче
emlemek *ф. сөйл.* имләү, дәвалау

emmi *и. сөйл.* абый, абзый
emniyet *и.* 1) иминлек, куркынычсызлык; 2) ышаныч; 3) куркынычсызлык полициясе, милициясе (*һәм алар белән бәглы эшләр*); 4) хәвеф-хәтәрне булдырмау чаралары; 5) (*машинада, механизмда һ. б.*) саклык, саклану өчен куелган деталь
emniyetli *с.* 1) имин, хәвеф-хәтәрсез; 2) ышанычлы
emniyetsiz *с.* 1) иминлексез, хәвефле, хәтәр; 2) ышанычсыз
emperyalizm *и.* империализм
empoze *с.* мәҗбүри кабул иттерелгән
empresyonizm *и.* импрессионизм
emprime *и.* төсле басма; төсле тукыма
emretmek *ф.* әмер итү, боеру
emsal *и.* 1) мисал, тиң; *emsali yok* мисалы юк, тиңе юк; 2) үрнәк
emsalsiz *с.* тиңсез
emzik *и.* 1) имезлек; 2) бәби өчен сөт шешәсе; 3) чәйнек борыны
emzikli *с.* 1) имезлекле; 2) күкрәк баласы булган (*ана*)
emzirmek *ф.* имезү
en I *и.* иң, киңлек □ **enine boyuna** иңенә-буена
en II *кис.* иң; *en büyük* иң бөек, иң зур, иң олы
encümen *и.* комиссия, комитет
endam *и.* 1)тән, бәдән; 2) буй, килбәт, әндам *иск.*
endamlı *с.* 1) буйлы; 2) сылу, зифа
endamsız *с.* 1) буйсыз; 2) килбәтсез
ender *с.* сирәк (*нәрсә*); бик сирәк
endişe *и.* 1) (*билгеле бер нәрсә турында*) уй, фикер; 2) гамь, хәсрәт, кайгырту; 3) шикләнү, вәсвәсә
endişelenmek *ф.* уйга калу, шиккә төшү
endişeli *с.* 1) гамьле; кайгылы; 2) вәсвәсәләнүчән, шикләнүчән; 3) шикләндергәч; төрле уйларга төшерә торган
endüksiyon *и.* индукция
endüstri *и.* индустрия
endüstriyel *с.* индустриаль
enek *и.* печтерелгән хайван
enerji *и.* энергия
eneze *с.* зәгыйфь; арык
enfarktüs *и.* инфаркт
enfeksiyon *и.* инфекция
enfes *с.* бик нәфис
enfiye *и.* борын тәмәкесе
enflâsyon *и.* инфляция
enflüanza *и. мед.* грипп; бик көчле томау
enformasyon *и.* информация **e**
nfraruj *с.* инфракызыл
engebe *и.* чокыр-чакыр
engebelik *и. с.* чокыр-чакырлык
engel *и.* 1) тоткар, комачау; 2) (*спортта*) киртә
engellemek *ф.* 1) тоткарлау, комачаулау; 2) (*керештә*) матау, аяк чалу
engelli *с.* тоткарлы, киртәле
engerek *и.* әңгерәк (*өчпочмаксыман башлы, кара төстәге агулы елан*)
engin I *с.* иңле, киң
engin II *и.* ачык киңлек, сәхрә
engin III *и.* иңкел, иңкүлек

enginar *и. бот.* артишок
enginlemek *ф.* ачык киңлеккә чыгу
enginlik *и.* ачык киңлек
engizisyon *и.* инквизиция
enik *и.* әнчек, кечек
eniklemek *ф.* (*җәнлекләр тур.*) чагалау, балалау
eni konu *с. рәв.* кирәгенчә; шактый
enişte *и.* җизни
enjeksiyon *и.* иньекция, укол (*кадау*)
enjektör *и.* инжектор
enkaz *и.* җимерелгән бина калдыклары; хәрәбәләр
enlem *и. геогр.* киңлек
enli *с.* иңле, киң
enlilik *и.* иңлелек
ense *и.* иңсә; җилкә ◊ **ensesi kalın** көчле, сүзе үтә торган; **ensesine binmek** җилкәгә менү
enselemek *ф.* җилкәсеннән алу, җилкәсеннән эләктереп алу
ensiz *с.* иңсез, тар
enstitü *и.* институт; *türkiyat enstitüsü* Төркология институты
enstrüman *и.* музыкаль инструмент
enstrümantal *с.* инструменталь
ensülin *и.* инсулин
entari *и.* озын күлмәк; халат; *gecelik entari* йокы күлмәге
entegre *и.* интеграль
entelekt *и.* интеллект
entelektüel 1. *с.* интеллектуаль. 2. *и.* интеллектуал
enteresan *с.* кызыклы
enternasyonal *с.* интернациональ; халыкара
enternasyonalizm *и.* интернационализм
enterne *с.* күзәтү астына алынган
entipüften *с.* нигезсез; кыйммәте булмаган
entrika *и.* интрига; (*үзара аралашуда*) хәйлә-мәкер
entrikacı *и.* интригачы
envanter *и.* 1) инвентарь, дирбия; 2) керем-чыгым дәфтәре; 3) кагылгысыз запас
enzim *и. мед.* энзима
epe *и. спорт.* кылычбазлыкта кулланыла торган бер төр корал; шул корал белән кылычбазлык итү
epey, **epeyce** *рәв.* шактый
epedemi *и.* эпидемия
epedemioloji *и.* эпидемиология
epik *с.* эпик; *epik eser* эпик әсәр
er I *и.* 1) ир, чын ир кеше; 2) солдат; 3) *сөйл.* ир (*хатынның ире*) ◊ **er meydanı** көрәш мәйданы; **ere gitmek** (**varmak**) кияүгә чыгу
er II *рәв. сөйл.* иртә; иртән; **er geç** иртә кич
ermek *ф.* 1) ирешү; 2) җитү, җитеп тию; 3) өлгерү (*үсемлекләр тур.*)
erat *и.* ир-ат; офицер дәрәҗәсенә кадәрге гаскәриләр
erbap *и.* белгеч; бер эшнең остасы
erdem *и.* ирлек, егетлек
erdirmek *ф.* ирештерү; җитештерү
erek *и.* максат
eren *и.* ирән, изге кеше
erg *и. физ.* эрг (*эш микъдарын үлчәү берәмлеге*)

erganun *и. муз.* орган
ergen *и.* (*өйләнү яшенә җитеп тә*) өйләнмәгән егет, буйдак
ergenlik *и.* 1) өйләнмичә йөрү хәле, буйдаклык; 2) (*егетләр йөзенә чыга торган*) сыткы, бетчә
ergimek *ф.* (*каты нәрсәләр*) эссе*лектән эрү
ergimiş *с.* эрегән
ergin *с.* 1) балигъ, җитлеккән; 2) өлгергән; *ergin ekin* өлгергән иген
erginleşmek *ф.* җитлегү, балигъ булу
erguvan *и. бот.* пурпур чәчәге
erik *и.* өрек
erim I *и.* ара, аралык; **el erimi** кул сузымы ара; *göz erimi* күз күреме ара
erim II *и.* яхшылык галәмәте; яхшы хәбәр
erinmek *ф.* иренү
erincek *с.* иренчәк, ялкау
erinç *и.* рәхәтлек, хозур
erirlik *и.* эрүчәнлек
erişmek *ф.* 1) ирешү; 2) җитү; *vakit erişti* вакыт җитте; 3) өлгерү; *yemişler çabuk erişti* җиләк-җимеш тиз өлгерде
erişkin *с.* буйга җиткән; өлгергән
eritmek *ф.* 1) эретү; 2) *күч.* әрәм-шәрәм итү; 3) *күч.* борчуга салу
eriten *и.* эреткеч матдә (сыеклык)
eritici *с.* эреткеч, эретүчән
eritme *и.* эретү □ **eritme peynir** эретелгән сыр
eriyik *и.* эретмә
eriyiş *и.* эрү рәвеше
erk *и.* ирек, ихтыяр; кодрәт
erkan *и.* 1) югары дәрәҗәле кешеләр; мәшһүрләр; 2) генералитет; 3) идарә
erkeç *и.* кәҗә тәкәсе
erkeçsakalı *и. бот.* кәҗә сакалы
erkek 1. *и.* 1) иркәк, ата (хайван); 2) ир, хатын ире; 3) *күч.* ышанычлы кеше. 2. *с.* нык, каты; *erkek demir каты* тимер
erkekçe *рәв.* ирләрчә
erkekli *и.* ирле
erkeksi *с.* ирләр кебек
erken *рәв.* 1) иртүк; 2) вакытыннан элек
erkence *рәв.* иртәрәк, шактый иртә
erkenden *рәв.* бик иртә; алдан ук, элгәртен
erkli *с.* ирекле, ихтыярлы; кодрәтле
ermin *и. зоол.* сары ас
ermiş *и.* әүлия
eroin *и.* героин (*наркотик матдә*)
eroinman *и.* наркоман
erotik *с.* эротик
erozyon *и.* эрозия
ersiz *с.* ирсез
ersizlik *и.* ирсезлек, толлык
erte *и.* нәрсәнең дә булса иртәгәсе; *bayram ertesi* бәйрәмнән соңгы беренче көн
ertelemek *ф.* иртәгәчә калу
erzak *и.* ризык
esaret *и.* 1) әсирлек, әсарәт *иск.*; 2) коллык
esas *и. төрле мәгъ.* нигез; әсас *кит.*
esasen *рәв.* 1) төптән, асылда, нигездә, әсаста *иск.*; 2) чынында; 3) болай да,

гомумән
esaslanmak *ф.* нигезләнү
esaslı *с.* нигезле, төпле; әсаслы *иск.*
esef *и.* көенү, көенеч
eseflenmek *ф.* көенү
esen *с.* 1) исән, сау-сәламәт; 2) саф, чиста; 3) зирәк
esenlemek *ф.* 1) сәламләшү; 2) саубуллашу
esenleşmek *ф.* исәнләшү; саубуллашу
esenlik *и.* 1) исәнлек; 2) сау-сәламәт булу
eser *и.* әсәр; *eski eserler* борынгы әсәрләр; 2) эз, ишарәт; *buralarda sudan eser yok* биредә суның әсәре дә юк
esinti *и.* йомшак җил
esintili *с.* җиләс
esintisiz *с.* бөтенләй җилсез
esir I *и.* әсир, тоткын
esir II *и.* эфир, радиодулкыннар җыелмасы
esirgemek *ф.* 1) саклау, яклау, исергәү *иск.*; 2) кызгану
esirgeyici *с. и.* 1) саклаучы, яклаучы; кызганучы; 2) сакчыл, сак тотучан
esirlik *и.* әсирлек, тоткынлык
eskatologya *и.* эсхатология (*дөньяның бетүе турында уйланулар*; *шул турыдагы тәгълимат*)
eski *с.* 1) иске; искергән; 2) борынгы; 3) элекке, элеккеге; 4) тәҗрибәле □ **eski püskü** иске-москы ◊ **eski hamam eski tas** иске мунча, иске таш (*үзгәрмәгән, кабатланып килгән нәрсәләр тур*); **eski kurt** карт бүре
eskimek *ф.* 1) искерү; 2) карарлашу, ныгып урнашу
eskiçağ *и. тар.* тарихкача дәвер (*беренче язма ядкарьлекләр барлыкка килгәнче булган дәверләр*)
eskiden *рәв.* борыннан, борынгыдан, искедән
eskıdünya *и.* Иске Дөнья (Европа, Азия, Африка)
eskileşmek *ф.* искерү
eskilik *и.* искелек
eskimo *и.* төньяк халыклары; эскимослар
eskiyiş *и.* искерү, искереш
eskiz *и.* эскиз
eskrim *и.* кылычбазлык, кылыч уены
eskrimci *и.* кылычбаз
eslemek *ф.* игътибарга алу
esmer *с.* 1) карасу (*тәнле*); 2) кара кучкыл (*төс*)
esnaf *и.* 1) вак һөнәрче(ләр), вак сәүдәгәр(ләр); 2) *күч.* алдакчы
esnemek *ф.* 1) иснәнү; 2) тәэсиргә бирелү; йогынтыга бирелү (*тартылу, сузылу һ. б.*); 3) киерелү
esnek *с.* 1) йомшак, эластик; 2) *күч.* йомшак; йогынтыга тиз бирелүчән
espas *и.* 1) (*типографиядә*) хәреф җыю таякчыгы; 2) җыймада юл арасы, интервал; *eki espas ile yazmak* ике интервал белән язу
esperanto *и.* эсперанто (теле)
espri *и.* тапкыр сүз; хикмәтле сүз
esrar I *и.* серләр
esrar II *и.* наркотик киндераш, баң
esre *и.* гарәп язмасында хәрәкә билгесе
esrik *и.* исерек, сәрхуш
estağfirullah *ы.* әстәгъфирулла (*төрекләрдә рәхмәт яисә мактау ишеткәндә әйтелә торган нәзакәтлелек сүзе*)

estek köstek *и.* юк-бар сәбәпләр; сәбәпкә сылтау □ **estek köstek etmek** юк-бар сәбәпләр табу
estet *и.* эстет
estetik 1. *и.* эстетика. 2. *с.* эстетик
eş *и.* 1) иш, сыңар; 2) иптәш, дус-иш; 3) хәләл җефет, ир яисә хатын □ **eş anlamlı** *гр.* синонимик, ишмәгънәле
eşmek *ф.* 1) казу, ишеп төшерү; 2) *күч.* тикшеренү
eşarp *и.* шарф, муен яулыгы
eşdeğer *и.* тиңкыйммәтлелек
eşdeğerli *с.* тиңкыйммәтле
eşek *и.* ишәк ◊ **eşek arısı** кыргый балкорты төре; **eşek kulağı** ат кузгалагы
eşelemek *ф.* 1) (*туфракны һ. б.*) болгату; 2) *күч.* җентекләп тикшерү
eşelmobil *и.* җитештерелгән мал кыйммәтенең артуына яисә кимүенә бәйле рәвештә эш хакы түләү системасы
eşey *и. биол.* җенеслелек
eşgüdüm *и.* эштәге координация
eşhas *и.* шәхесләр; төрле кеше
eşik *и.* 1) бусага; 2) *геогр.* субүләр сырт
eşilmek *ф.* ишелү, казынты хасил булу
eşinmek *ф.* (*хайваннар тур.*) тибенү, тибендә йөрү
eşit *с.* тиңдәш, тиң
eşitlemek *ф.* тиң итү, тиңләштерү; тигезләү
eşitlik *и.* 1) тиңлек, тиңдәшлек; 2) иҗтимагый тигезлек
eşitsizlik *и.* тиңсезлек, тигезсезлек
eşkenar *с. мат.* тиңьянлы, тигезьяклы □ **eşkenar dörtgen** тигезьяклы дүртпочмак; квадрат
eşkiya *и.* бандитлар, рэкетирлар һ. б. ш.
eşkıyalık *и.* бандитлык
eşlemek *ф.* 1) бер-беренә иш ике нәрсә барлыкка китерү; 2) кинофильмны тавышландыру (*кадрны һәм тавышны бер-берсенә туры китерү*)
eşlik *и.* 1) ишлек, иш булу; 2) гармония □ **eşlik etmek** 1) кушмалык итү, җырчыга кушылып музыка коралында уйнау; 2) юлдаш булу
eşsesli *с. гр.* омонимик (*сүзләр*)
eşsiz *с.* 1) иптәшсез, җефетсез; 2) тиңсез (гаять шәп)
eşya *и.* әйбер, әйберләр
eşzamanlı *с.* синхроник, бер үк вакытта барлыкка килгән
et *и.* 1) ит; 2) җимеш йомшагы; 3) тән, бәдән □ **et suyu** ит шулпасы
etmek *ф.* 1) итү, кылу; 2) билгеле бер бәягә тору; 3) хасил итү
etajer *и.* этажерка
etap *и.* этап
etek *и.* итәк □ **etek bezi** бәби чүпрәге ◊ **etek öpmek** ялагайлану; тәлинкә тоту; **eteğine yapışmak** кемнән дә булса ярдәм сорау
eteklik *и.* 1) итәклек (*тукыма*); 2) итәк (*кием*)
eter *и. хим.* эфир
eterlemek *ф. мед.* эфир белән наркоз (*яисә анестезия*) ясау
etiket *и.* 1) этикетка; ярлык; 2) этикет
etiketçi *и.* 1) ярлык, этикетка ябыштыручы; 2) этикет яклы кеше; әхлакчы
etiketlemek *ф.* этикетка ябыштыру
etilen *и.* этилен
etimoloji *и.* этимология, этимология фәне
etken *с. и.* 1) тәэсир итә торган; 2) *гр.* гади хәбәр; 3) *хим.* катализатор
etkenlik *и.* тәэсирлек, тәэсирле булу

etki *и.* тәэсир, йогынты
etkilemek *ф.* тәэсир итү
etkilenmek *ф.* (*кемнең, нәрсәнең дә булса*) тәэсирендә калу
etkili *с.* тәэсирле
etkin *с.* хәрәкәтчән, актив
etkinlik *и.* эшчәнлек
etkisiz *с.* тәэсирсез
etlenmek *ф.* итләнү; симерү
etli *с.* 1) итле; 2) итләч, симез
etlik *и.* 1) иткә асралган терлек; 2) итлек, ит саклый торган урын
etnik *с.* этник
etnografya *и.* этнография
etnoloji *и.* этнология
etraf *и.* 1) тирә-юнь, тараф; 2) яклар, тарафлар
etraflı *с.* 1) дус-ишле; 2) әтрафлы; киң
etraflıca *рәв.* киңәйтеп, әтрафлы рәвештә
etsiz *с.* 1) итсез; 2) ябык, арык
ettirgen *с. гр.* төшем юнәлешендәге (*фигыль*)
etüt *и.* 1) этюд; 2) сабак (дәрес) хәзерләү өчен билгеләнгән вакыт
etüv *и.* калорифер (*химик лабораториядә матдәне билгеле бер температурада саклый торган җайланма*)
ev *и.* 1) *төрле мәгъ.* өй; 2) *күч.* гаилә □ **ev adamı** өйдә торучан һәм юаш кеше; **ev eşyası** өй әйберләре, өй җиһазлары; **ev işi** өй эше, кул эше, кулдан эшләнгән нәрсә; **ev bark** өй эче, өйдәгеләр; **ev halkı** бер өйдә торучыларның барчасы; **ev kadını** хуҗабикә
evce *рәв.* бөтен өй эче белән
evci *и. с.* бәйрәм һәм каникул көннәрендә өенә кайткан (кайтырга рөхсәте булган) укучы һ. б.
evcil *с.* йортлашкан (*хайван*)
evcilik *и.* өй ясап уйнау; кунак-кунак уены
evcilleşmek *ф.* йортлашу, кулга ияләшү
evdeş *и.* өйдәш
evegen *с.* 1) кабаланчык, ашыгучан (*кеше*); 2) тиз көчәючән (*авыру*)
evelemek *ф.* сүзен авызында әвәләү, бытылдау
evermek ф. өйләндерү
evet *ы.* әйе, ие, ээ; шулай
evgin *с.* ашыгыч, тәҗелле
evham *и.* шик, икеләнү
evhamlı *с.* шикләнүчән
evirmek *ф.* 1) әверү, әверелдерү; 2) өйләндерү □ **evirmek çevirmek** бер урыннан икенче урынга күчерү; әверү-чәверү *диал.*; әвеш-түеш китерү
evirgen *с.* булдыклы
evlât *и.* 1) балалар, бала-чага; 2) токым, яңа буын; 3) иләт, ил-көн, халаек *иск.*; өлкәнең барлык яшәүчеләре
evlâtlık *и.* 1) балалык, угыл-кызлык; 2) балалыкка алынган ул яки кыз
evlâtsız *с.* баласыз, токымсыз
evlek *и.* 1) басу яисә бакчаның аерымланган бер өлеше, кишәрлек; 2) бөтен җир кишәрлеген (гектарны, дисәтинәне) дүрткә бүлү өчен сызылган буразна, ызан; 3) (*җир үлчәме буларак*) түтәрәм; 4) арык; бер арык сугарган кишәрлек
evlenmek *ф.* өйләнешү; өйләнү; кияүгә чыгу
evlendirmek *ф.* өйләндерү; кияүгә бирү
evli *и.* 1) өйлә; 2) өйләнгән; кияүгә чыккан

evlilik *и.* өйләнгәнлек; кияүдә булу
evliya *и.* әүлия
evrak *и. эш* кәгазьләре; документлар
evre *и.* этап, дәвер, чор
evren *и.* 1) бөтен дөнья, җиһан; 2) *күч.* мохит
evrim *и.* эволюция, үсеш
evrimci *и.* эволюционист, эволюция теориясе тарафдары
evrimcilik *и.* эволюционизм
evvel *и. с.* әүвәлге, тәүге; беренчел; вакыйганың h. б. башы
evvelâ *рәв.* 1) башта, беренчедән; 2) беренчеләй
evvelce *рәв.* 1) әүвәлрәк, баштарак; 2) билгеле вакыйгадан h. б. элегрәк
evvelden *рәв.* әүвәлдән, электән
evvelki *с.* әүвәлге
ey *ы.* 1) әй, и; 2) (*аерым аһәң белән*) әйе, ие
eyalet *и.* өлкә, штат
eylem *и.* шөгыль; гамәл
eylül *и.* сентябрь
eyvah *ы.* вай!, ай!
eyvallah *ы.* 1) бик яхшы; ярый; дөрес; 2) рәхмәт; 3) Аллага тапшырдык!
ezmek *ф. төрле мәгъ.* изү, сыту; таптау, таптату
eza *и.* иза, изалау
ezan *и.* азан; азан уку
ezber *и.* 1) яттан уку, ятлау; 2) яттан укырга бирелгән текст
ezberci *и.* дәресен яттан җавап бирүче укучы; аңламастан ятлаучы
ezberlemek *ф.* ятлау
ezel *и.* чиксез борынгы заманнар, чиксез борынгылык; мәңгелек; әзәл
ezeli *с.* мәңгелек; борынгы
ezgi *и.* 1) моң, аһәң; 2) көй, көйнең кабатлана торган өлеше; 3) көй, җай; ысул
ezgili *с.* моңлы, аһәңле
ezgin *с.* 1) изелгән; 2) йончыган; 3) алҗыган; мәлҗерәгән
ezginlik *и.* изелгәнлек; йончыганлык; алҗыганлык
ezici *и. төрле. мәгъ.* изүче
ezik *с.* 1) йомшарган, изелгән; 2) зәгыйфь, мескен
ezilmek *ф.* 1) изелү, онталу, ваклану; 2) сытылу; 3) *күч.* изелү; изүгә дучар булу
eziyet *и.* интегү, җәфа, азап □ **eziyet çekmek** җәфа чигү; **eziyet vermek** җәфалау
ezme *и.* измә; пюре

F

faal *с. кит.* күп эшли торган, эшчән
faaliyet *и.* эшчәнлек, фәгалият *иск.*
fabl *и. әд.* мәсәл
fabrika *и.* фабрика, завод
fabrikacı *и.* фабрикачы, фабрикант; заводчы
fabrikasyon *и.* 1) фабрикация; 2) фабрикада эшләнгән нәрсә
fabrikatör *и. к.:* **fabrikacı**
facia *и.* фаҗига, һәлакәтле хәл
façuna *и.* ышкылудан ашалып бетмәсен өчен арканны тасма белән урап кую
façunalık *и.* арканга урату өчен махсус ясалган тасма
fagot *и.* фагот (*тынлы музыка коралы*)
fahiş *с.* әхлаксыз, әшәке, фахиш *кит.*
fahişe *и.* фахишә
fahrenhayt *и.* фаренгейт (*температураны үлчәү берәмлеге*)

fahrî *с.* мактаулы, мактанычлы, фәхри *иск.*
fail *с.* эшчән, эшмәкәр; актив, фагыйль *иск.*
faiz *и.* (*капиталдан*) процент; табыш □ **faiz yürütmek** процентын исәпләп чыгару
faizci *и.* процентка акча бирүче; рантье
faizleridirmek *ф.* акчаны процентка бирү
faizli *с.* процентлы
faizsiz *с.* процентсыз
fakat *терк.* фәкать
fakir *и.* 1) фәкыйрь; 2) фәкыйрь, фәкыйрең, фәкыйрегез (*мин диясе урында тыйнаклык йөзеннән әйтелә торган сүз*)
fakirce *рәв.* фәкыйрьләрчә, ярлыларча
fakirleşmek *ф.* фәкыйрьләшү
fakirlik *и.* фәкыйрьлек, ярлылык
faksimile *и.* факсимиле (*әдәби ядкарьлекнең төп нөсхәсеннән фотографик күчермә*)
faktör *и.* фактор
fakülte *и.* факультет
fal *и.* багу, фал ачу; китаптан очраклы бер өзекне укып күрәзәләү; **fal taşı** фал ташы, рәмел ташы
falaka *и.* (*эллекке мәктәптә*) тыңлаусыз балага җәза бирү җайланмасы (*аякка бәйләнә торган такта*)
falan *и. с.* фәлән ◊ **falan filân** (**fıstık**, **feşmekân**, **festekiz**) фәлән-төгән, фәлән-төгән фәсмәтән
falanca *рәв.* фәләнчә
falanına *а. сан* фәләненме
falcı *и.* фалчы
falçete *и.* итекче пычагы
falso *и.* фальшь, ялгыш алым h. б. ш.
falsolu *с.* фальшьле
falyanos *и. зоол.* дельфиннең иң зур гәүдәле төре
familya *и.* гаилә
fanatizm *и.* фанатизм
fanfan *с.* ачык итеп сөйләшми торган; авызында ботка пешерүче
fânî *с.* фани
fanta *и. зоол.* күк чәүкә
fantasma *и.* фантазия
fantastik *с.* фантастик
fantaziya *и.* фантазия
fantezi *и.* 1) фантастик әсәр (*роман, хикәя, картина һ. б.*); 2) мода яки традиция белән исәпләшмичә киенү яисә кылану
fanus *и.* 1) фонарь, юл лампасы, факел; 2) диңгез маягы; 3) пыяла калпак
fanuslu *с.* 1) фонарьле, факеллы; 2) маяклы; 3) калпаклы
far I *и.* фара, автомашина h. б. яктырткычы
far II *и.* күз кабакларына сөртү өчен бизәнү буявы
faraş *и.* чүп соскысы
faraza *кер. сүз.* фаразан, билфараз, әйтик
farazî *с.* фарази, хыялый, күз алдына китерелгән
faraziyat *и.* фараз ителгән нәрсәләр
faraziye *и.* фараз, гипотеза **farbala** *и.* бөрмә, бөрмәле итәк **fare** *и. зоол.* күсе ◊ **fare deliği** кереп качарлык урын
farımak *ф.* 1) ваз кичү, җиксенү; 2) хәлдән таю; 3) искерү, таушалу
fariğ *с.* эшеннән котылган, мәшәкатьләрдән азат; эшен тапшырган, эштән азат

fark *и.* 1) аерма; 2) аеру, аерымлау; **fark etmek** 1) аеру; күреп алу, абайлау; 2) аңлау, сизү; 3) үзгәрү; **farkına varmak** абайлап алу, аңлау
farklı *с.* 1) аермалы; 2) үзгәргән, үзгәрешле
farklılaştırmak *ф.* аермалы итү
farklılık *и.* аермалылык
farksız *с.* аермасыз, өстенлексез
farmakoloji *и.* фармокология
farmason *и.* 1) масон оешмасы; 2) динсез, фармазон
fars *и.* фарс, көлкеле-мыскыллы сәхнә әсәре
fart furt, **farta furta** *рәв.* пырдымсыз
farz *и.* 1) фарыз, һичшиксез үтәлергә тиешле дини йөкләмә; 2) һичшиксез үтәлергә тиешле кагыйдә
farzımuhal *и.* фараз ителгән хәл
fasa fiso *и.* фәлән-фәсмәтән
fasarya *и.* аңлаешсыз һәм буш
fasıl *и.* 1) бүлек, бүлем, өлеш; 2) (*пьеса уйналышында аерым*) күренеш
fasıla *и.* аерып торган нәрсә, бүлгеч
fasikül *и.* зур бер китапның, (әсәрнең) бер өлеше булган том
faska *и.* киң бинт
fason *и.* фасон, рәвеш (*киемдә*)
fasone *и.* 1) бизәкле йон тукыма; 2) шундый тукыманың бизәк үрнәге
fasulye *и. бот.* фасоль; *kuru fasulye* өлгергән коры фасоль; *taze fasulye* кузаклы яшел фасоль
faş: **faş etmek** фаш итү
faşır faşır *иярт.* шаулап, гөрләп (*агу туры.*)
faşist *и.* фашист
faşizm *и.* фашизм
fatalizm *и.* фатализм
fatih *и.* яулап алучы, фатих *иск.*
fatiha *и.* Коръәннең беренче сүрәсе
fatura *и.* сатылачак малның (товарның) төрен, микъдарын һәм бәясен күрсәтеп, сатучы тарафыннан язылган язу, фактура
faturalamak *ф.* фактура язу
faturalı *с.* фактуралы
fauna *и.* фауна, хайваннар дөньясы
favori *и.* 1) фаворит; 2) бакенбард, чигә сакалы
fay *и. геол.* җир кабыгының әүсәкләре (плитәләре) бер-берсенә бәрелү нәтиҗәсендә барлыкка килгән кырынтылар
fayans *и. с.* фаянс, керәч
fayda *и.* файда
faydalanmak *ф.* файдалану
faydalı *с.* файдалы
faydasız *с. рәв.* файдасыз
fayrap *и.* 1) пароходта пар казанының утын көчәйтергә кушу командасы; 2) пар казанының нормаль эшләве; 3) *күч.* (*эшне, һ. б.*) кызулату
faz *и.* фаза ◊ **faz kalemi** токның барлыгын-юклыгын тикшерү коралы
fazilet *и.* кыйммәт, кирәклелек, фазиләт *иск.*
faziletli *с.* кыйммәтле, кирәкле, Фазиләтле *иск.*
fazla *и. с.* 1) күп; артыклык; 2) артып калган нәрсә, артык; калдык; 3) күбрәк, артыграк
fazlalaşmak *ф.* артып китү
fazlalık *и.* артыклык; артык күплек

fecî *c.* фаҗигале
fecir *и.* кояш чыгу алдыннан булган вакыт, таң, иртә
feda *и.* фида; *canım feda* җаным фида
fedaî *и.* фидаи, берәр эш *яисә* идея өчен үз мәнфәгатен корбан иткән кеше
fedakâr *с. и.* фидакяр
fedakârca *рәв.* фидакарларча
fedakârlık *и.* фидакярлек
federal *с.* федераль
federalist *и. с.* 1) федерализм тарафдары; 2) федерализмга бәйле
federalizm *и.* федерализм **federasyon** *и.* федерация **federatif** *с.* федератив
federe *с.* федерациягә кергән
fek *и.* аеру, кубару
felâket *и.* фәләкәт, зур бәла-каза; һәлакәт
felâketli *с.* фәләкәтле, һәлакәтле
felç *с.* паралич, фалиҗ
felçli *с.* параличлы
feldmareşal *и.* фельдмаршал
felek *и.* 1) күк гөмбәзе; 2) дөнья, галәм; 3) язмыш; 4) *хәрби.* оркестрда кыңгыраулы музыка коралы ◊ **feleğin çemberinden geçmiş** күпне күргән (кеше)
felemenk *и.* Фламанд (*хәзерге Голландия, һәм Франциянең төньяк-көнчыгыш өлешләрен берләштергән өлкәнең борынгы исеме*)
felfellemek *ф.* сүлпәнләнү
fellik fellik *рәв.* җәһәт-җәһәт
felsefe *и.* фәлсәфә, философия
felsefeci *и.* фәлсәфәче, философ
felsefî *с.* фәлсәфи
feminist *и.* феминист
feminizm *и.* феминизм (*хатын-кыз азатлыгы һәм ир-ат белән тигез хокуклылык өчен көрәш хәрәкәте*)
fen *и.* 1) фән (*табигать фәне*); 2) техника; 3) белем; 4) *күч.* хәйлә
fena I *и.* юк булу, югалу, җуелу
fena II *с.* начар, әшәке, яман; хөрти
fenalaşmak *ф.* начарлану, начарлашу, әшәкеләнү
fenalık *и.* начарлык; әшәкелек; хөртилек
fenci *и.* техника галиме; табигать фәннәре укытучысы
fener *и.* 1) фонарь, урам яктырткычы; 2) диңгез маягы □ **fener balığı** дельфинның кечерәк төре; **fener böceği** көя
fenerci *и.* диңгез маякчысы, маякчы
fenerli *и.* фонарьле
fenersiz *и.* фонарьсыз ◊ **fenersiz yakalanmak** көтмәгәндә уңайсыз бер хәлгә төшү
fenike *и.* Финикия
fenikeli *и.* финикияле
fennî *с.* фәнни
fenol *и.* фенол
fenomen *и.* феномен, гаҗәп хәл (очрак)
feodal *и.* феодал
feodalite *и.* феодаллык
feodalizm *и.* феодализм
fer I *и. кит.* тармак (*хуҗалык, фән-гыйлем һ. б. тармагы*)
fer II *и.* 1) нурлылык, күркәмлек; 2) күз нуры; җанлылык
feragat *и.* хокукыннан үз теләге белән баш тарту
ferağ *и.* 1) ваз кичү, баш тарту хәле; 2) күчемсез мөлкәткә хокукны башкага

тапшыру
ferah I *и. кит.* сөенеч
ferah II *с.* киң, мул (*кием-салым һ. б. тур.*); иркен (*дала һ. б.*)
ferahlamak *ф.* 1) киңәю; *odaferah-ladı* бүлмә киңәйде; 2) күңел рәхәтләнү
ferahlatmak *ф.* сөендерү, күңелгә рәхәтлек бирү
ferahlatıcı *и.* күңелгә рәхәтлек бирүче
ferahlık I *и.* киңлек, ачыклык
ferahlık *и.* күңел рәхәтлеге
ferde *и.* тукыма төргәге, кечерәк рулон
feribot *и.* паром
ferik I *и.* 1) зур чеби; 2) алма сорты
ferik II *и.* генерал
feriklik *и.* генераллык; армия генералы булу
ferma *и.* ау этенең корбанын күзәтеп тик торышы
ferman *и.* фәрман
fermanlı *с.* 1) *тар.* хөкем ителгән (җинаятьче); 2) *күч.* үзбашка кыланучы
fermantasyon *и.* ферментация; төнәтелү
ferment *и.* фермент; әчетке
fermuar *и.* молния (*каптырмалы тасма*)
fersiz *с.* нурсыз (*күз, караш*)
fersizleşmek *ф.* нурсызлану
feryat *и.* сөрән салу, фөрьяд *кит.*
fes *и.* фәс (*баш киеме*)
fesat *и.* 1) рухи яисә мораль-әхлакый бозыклык; 2) каршылык, кирелек, үчләшү
fesatçı *и.* бозыклык чыгаручы
fesih *и.* бетерү, бозу, юкка чыгару (*карар, канун һ. б. ш.ны*)
fesleğen *и. бот.* рәйханның бер төре
fesrengi *и.* куе кызыл төс
festival *и.* фестиваль
fetiş *и.* фетиш, чиктән тыш әһәмият бирелгән нәрсә
fetişizm *и.* фетишизм
fettan *и.* 1) фетнә чыгаручы; 2) *күч.* көнчелек чыгаручы (*кыз*)
fetva *и.* фәтва, дини күрсәтмә, бәхәсле нәрсәгә дини авторитет тарафыннан бирелгән аңлатма
fevkalâde *с.* гадәттән тыш, фәүкыльгадә *иск.*
fevkalâdelik *и.* гадәттән тыш булу, фәүкыльгадәлек
fevrî *с.* дуамал
feyiz *и.* 1) муллык, иркенчелек; 2) юмартлык; бүләк; 3) уңыш, өлгәшү; 4) рухи тынычлык, рухи өлгәшү
feyizli *с.* муллыклы
fıçı *и.* мичкә
fıçıcı *и.* мичкәче
fıçılamak *ф.* мичкәгә тутыру
fıkır-fıkır *иярт.* быкыр-быкыр (*кайнау*)
fıkırdamak *ф.* 1) быкырдау, быкырдап кайнау; 2) дулкынланып тору; 3) *күч.* кыланчыклану, чытлыклану
fıkırdak *с. күч.* уйнак, кыланчык, чытлык
fıkırdaşmak *ф.* чытлыклану
fıkırtı *и.* быкырдау авазы, быкырдавык
fıkra *и.* 1) әсәрнең аерым бер бүлеге, эпизод; 2) кануннамәдә бүлекчә, параграф h. б. ш.; 3) анекдот; 4) көндәлек газит мәкаләсе; газиттагы көндәлек хәбәр
fıkracı *и.* 1) мәзәкче анекдотчы; 2) газетта көндәлек хәбәрләр язучы, хәбәрче

fıldır fıldır *иярт.* елтыр-елтыр; мелт-мелт
fındık *и.* чикләвек
fındıkbiti *и. зоол.* чикләвек корты
fındıkçı *и.* 1) чикләвек сатучы; 2) *күч.* чытлык хатын-кыз
fındıkfaresi, **fındıksıçanı** *и. зоол.* чикләвек кимерүче тычкан
fındıkî *с.* чикләвек кабыгы төсендәге
fındıkkıran *и.* чикләвек ваткыч
fındıkkurdu *и. зоол.* чикләвек корты
fırça *и.* 1) мисвәк, щетка; *elbise fırçası* кием щеткасы; *diş fırçası* теш щеткасы; 2) *күч.* рәсем сәнгатенең бер төре
fırçalamak *ф.* мисвәкләү, щетка белән чистарту
fırdolayı *рәв.* түгәрәкләп, әйләнә-тирәләп
fırdöndü *и.* 1) вертлюг (*тоташкан арканнар, валлар һ. б. берсе әйләнгәндә икенчесе әйләнмәсен өчен куелган тоташтыргыч җайланма*); 2) шуңа охшаш бер уенчык (*отышлы уенда да кулланыла*); 3) *күч.* флюгер (*фикерен, карашын үзгәртеп торучы*)
fırfır I *и.* күлмәк-күнчек читләренә беркетелә торган тасма челтәр
fırfır *иярт.* фыр-фыр
fırfırlı *с.* тасма челтәрле
fırıldak *и.* 1) пырлавык, уенчык җил тегермәне, флюгер; 2) җилләткеч, кечкенә вентилятор; 3) моржа өстенә куела торган түбәчек
fırıldakçiçeği *и. бот* дүрт лепелдәкле чәчәк
fırıl fırıl *иярт.* зыр-зыр (*әйләнү*)
fırın *и.* 1) икмәк миче; 2) икмәк пешерү эшханәсе; 3) тимер мичле казан
fırıncı *и.* 1) икмәк пешерүче; 2) миччe
fırınlamak *ф.* мичтә икмәк һ. б. пешерү
fırınlı *с.* мичле
fırka *и.* 1) груһ, фирка, партия; 2) хәрби корпус, дивизия, җиде полктан торган гаскәри берләшмә
fırkacı *и.* фиркачы, партияле
fırlamak *ф.* 1) атылып чыгу, чыгу; 2) очып чыгу, очып китү; 3) (*бәяләр*) кинәт күтәрелү
fırlak *с.* 1) чыгынкы, чыккан, чыгып торган; 2) тасрай, тасрайган (*күз*)
fırsat *и.* форсат
fırsatçı *и.* форсатчы, уңайлы очрак көтеп ятучы
fırt *и.* бер тапкыр суыру (*мәс., сигаретны*); бер йоту
fırtına *и.* 1) давыл; 2) *күч.* кыен хәл, чарасызлык □ **fırtına kuşu** давыл кошы
fısfıs *иярт.* пыш-пыш (*сөйләшү*)
fısfıslamak *ф.* пыш-пышлау, пышылдау
fısıldamak *ф.* пышылдау
fısıl fısıl *иярт.* пыш-пыш, пышыл-пышыл
fısıltı *и.* пышылдык, пышылдаган тавыш
fısır *иярт.* чытыр-чытыр (*яну*); чылтыр-чылтыр (*агу*)
fıskiye *и.* кечкенә фонтан
fıslaşmak *ф.* пышылдау; шыпыртлау
fıstık *и. бот.* 1) пестә; 2) *күч.* гүзәл кыз
fıstıkçı *и.* пестәче, пестә җитештерүче яки сатучы
fıstıkî *и. с.* саргылт яшел
fış fış *иярт.* кыштыр-кыштыр; челтер-челтер
fışır fışır *иярт.* кыштыр-кыштыр
fışırdamak *ф.* кыштырдау

fışırtı *и.* кыштырт (итү)
fışkı *и.* яңа тирес
fışkılamak *ф.* тиресләү
fışkılık *и.* тиреслек
fışkın *и.* курпы
fışkırmak *ф.* 1) сиптерү, бөркү; 2) чыгу
fışkırdak *и.* сиптергеч
fışnamak *ф.* әчеп кабару; күпчү
fıtık *и. мед.* бүсер
fiber *и.* фибр
fiberglas *и. с.* фиберглас, пыяла мамык
fidan *и.* үренте, үсенте
fidanlık *и.* үрентелек; үрентеләр җитештерә торган хуҗалык
fide *и.* күчәт, күчереп утыртыласы шытым
fideci *и.* күчәтче
fidecilik *и.* күчәтчелек
figür *и. төрле мәгъ.* фигура
figüran *и.* 1) фигурант, статист (*кинофильмда массаны күрсәтүдә генә катнашучы артист -гадәттә хәзерлексез кеше*); 2) берәр оешмага яисә мәрасимгә чакырылып та, бик пассив рольдә калган кеше
figüranlık *и.* фигурантлык, статистлык
figürlü *с.* фигуралы
fihrist *и.* 1) күрсәткеч, индекс; 2) каталог; 3) исемлек
fiil *и.* 1) (*чынбарлыктагы*) эш, хәрәкәт; 2) *гр.* фигыль
fiilen *рәв.* чыннан да, Турыдан-туры; сүздә генә түгел, чынбарлыкта да, эштә дә
fiilî *с.* сүздә генә түгел, эштә дә башкарылган
fikir *и. төрле мәгъ.* фикер; уй, караш
fikirli *с.* фикерле
fikirsiz *с.* фикерсез
fikren *рәв.* фикере белән, фикереннән, фикрән *иск.*
fikrî *с.* фикергә бәйләнешле, фикри
fikstür *и. спорт.* уйналачак матчлар җәдвәле
fil *и. зоол.* 1) фил; 2) *күч.* (*шахматта*) фил
filân *и.* фәлән
filanıncı *с.* фәләненче
filarmoni *и.* филармония
filarmonik *и.* филармония оркестры; филармониягә бәйләнешле музыкаль төркем
fildişi *и.* 1) фил теше; 2) *анат.* тешнең сөяк тукымасы
file *и.* 1) челтәр капчыкчык, сетка (ситке); 2) (*челтәрләп һәм төенләп үрелгән*) балык ятмәсе
filet *и. диңг.* тигез төпле сай җир
filinta *и.* 1) кыска мылтык, флинт; 2) *күч.* зифа буйлы кеше
filiz I *и.* 1) бөре; 2) уҗым
filiz II *и.* мәгъдән, руда
filizî *с.* ачык яшел, яшь яфрак төсендәге
filizkıran *и.* (*гадәттә май уртасында була торган*) салкын җил
filizlemek *ф.* артык дип саналган бөреләрне кисү
filizlenmek *ф.* бөреләнү
filizli *с.* бөреле
film *и.* 1) кинофотопленка; 2) кинофильм, фильм
filo *и.* флот
filoloji *и.* филология

filotilla *и.* флотилия, (*хәрби*) кораблар төркеме
filoz *и.* җылым калкавычы
filozof *и.* философ
filtre *и.* фильтр
filtreli *с.* фильтрлы
filtresiz *с.* фильтрсыз
final *и.* финал
finanse *и.* финанс □ **finanse etmek** финанслау
fincan *и.* чынаяк, йомры, чокыр
fincanböreği *и.* кечкенә кабартма
fince 1. *и.* фин теле. 2. *рәв.* фин телендә, финча
fingirdemek *ф.* шаталаклану
fingirdek *с.* шаталак (*хатын-кыз*), чытлык
finiş *и.* финиш
fino *и.* кечкенә йонлач эт болонка
firar *и.* 1) качу, качып китү; 2) качу (*тоткын тур.*)
firavun *и.* 1) фиргавен; 2) *күч.* тиран, явыз кеше
firavunfaresi *и. зоол.* фиргавен күсесе, мәчесыман бер хайван
firavunluk *с.* фиргавенлек
fire *и.* товарны йөрткәндә (сатканда h. б.) пәйда булган кимү
firfiri *с.* кызыл шәраб төсендәге, җете кызыл
firma *и.* фирма
firuze *и.* фирәзә, фирүзә (*асылташның бер тере*)
fiske *и.* 1) чиртү, чиртеш; 2) чеметем
fiskelemek *ф.* чиртү
fistan *и.* ябу; җилән
fisto *и.* 1) бизәкле тасма; 2) Челтәрсыман бизәкле тукыма
fiş *и.* 1) штепсель, токка тоташтыргыч җайланма; 2) квитанция
fişek *и.* патрон; шартлаткыч матдә
fişlemek *ф.* квитанция тутыру
fit I *и.* 1) коткы; 2) (*уенда һ. б.*) квит
fit II *и.* бер төр озынлык үлчәве
fıtçi *и.* коткычы, котыртучы
fitil *и.* 1) филтә; 2) билтә (*иске ату коралларында дары кабызгыч*); 3) юрмәп тегү; 4) тукымада тар юлак ◊ **fitil almak** каударланып кабынып китү, пырлау; **fitil vermek** кыздыру, котырту, аздыру
fitillemek *ф. мар.* филтәгә яки билтәгә ут төртү
fitilli *с.* 1) филтәле; билтәле (*мылтык*); 2) тар юлаклы (*тукыма*)
fitilsiz *с.* 1) филтәсез (*лампа*); 2) билтәсез (*мылтык, туп*)
fitlemek *ф.* коткы салу, котырту
fitleyici *и.* коткычы, коткы салучы
fitne *и.* 1) үзара низаглар; 2) фетнә; баш күтәрү; 3) низагчы яисә низагларга сәбәпче булган кеше, фетнә
fitneci *и.* 1) фетнәче; 2) интригачы
fitnelemek *ф.* фетнә чыгару
fiyasko *и.* фиаско, зур уңышсызлык, көлкегә калу
fiyat *и.* бәя, хак; □ **fiyat biçmek** бәя кую; **fiyat kırmak** бәяләрне төшерү
fiyatlarımak *ф.* бәясе (бәя, бәяләр) арту
fiyonk *и.* күбәләк сурәтендәге бизәнү әйбере
fizik *и.* 1) физика; 2) гәүдә, килбәт, бәдән □ **fizik ötesi** метафизика
fizikçi *и.* 1) физик, физика буенча белгеч; физика укытучысы; 2) физиодәвалау белгече

fiziksel *с.* физик көч белән бәйле
fizyoloji *и.* физиология
fizyonomi *и.* физиономия
fizyoterapi *и.* физиотерапия
flama *и.* 1) ялау (*сөңге очына тагылган кечкенә байрак, әләм*); 2) (*корабларда сигнал өчен кулланыла торган*) *байракчык*
flâman *и.* фламанд
flamingo, **f**lâm**a**n kuşu *и.* фламинго
flândra *и. диңг.* сигнал байрагы □ **flândra balığı** *зоол.* пычкыбалыкның бер тере
flanel *и.* фланель (*тукыма төре*)
flâş *и.* 1) (*фотога төшергәндә кыска арада*) яктыртып алу; 2) тиз генә, яктыртып ала торган лампа; 3) *күч.* иң мөһим
flegmon *и. мед.* флегмона, тире астындагы яки үпкәдәге эрен
flora *и.* флора
florin *и.* флорин, Голландиядә кулланыла торган акча берәмлеге
flört *и.* флирт
flurya *и. зоол.* яшелле-сарылы бер кош
flüt *и.* флейта, курай
flütçü *и.* флейтачы, курайчы
fob *и.* фоб (*алучының йортына китереп бирү шарты белән сату һәм шуның бәясе*)
fobi *и.* курку авыруы, куркучанлык, биләм
fodla *и.* ярлыларга таратыла торган махсус төр икмәк
fodul *с.* тәкәббер, һавалы, эреләнүчән
foga *и.* артиллериядә "ут!" командасы
fok *и. зоол.* тюлень
fol *и.* маяга калдырылган йомырка
folk *и.* халык, масса, гавам
folklor *и.* фольклор, халык иҗаты
folklorcu *и.* фольклорчы
folluk *и.* (*тавыклар өчен*) йомырка салу оясы
fon *и.* 1) фонд; 2) декорация, фон; 3) (*рәсемчелектә*) *грунт*
fonda *и. диңг.* кораб ләңгәр салган җир
fondan *и.* йомшак эчлекле кәнфит
fonem *и.* (*тел гыйлемендә*) фонема
fonetik 1. *и.* фонетика. 2. *с.* фонетик
fonetikçi *и.* фонетикачы, фонетист
fonksiyon *и.* функция; роль
fonograf *и.* фонограф
fonoloji *и.* фонология
font *и.* чуен; чуен яки корыч кисәге
fora I *диңг.* "җилкәннәрне ач!" командасы
fora II *и.* машина (*механизм* һ. б. ш.) сүтү
forint *и.* форинт, Венгриядә акча берәмлеге
form I *и.* форма
form II *и.* бланк
forma *и.* 1) (*полиграфиядә*) форма, металл рам; 2) (*китапның һ. б.*) басма табагы; 3) форма, хәрби яисә спорт киеме (*формасы*)
formalite *и.* формалылык; формасына (рәвешенә) китерү, рәвешчелек
formaliteci *и.* педант
formalizm *и.* формализм
formasyon *и.* формация, шәкелләнү
formül *и.* формула

formülleşmek *ф.* формуллашу
foroz *и.* ятьмәне бер салуда чыккан балык микъдары
fors *и.* 1) өч яисә дүрт почмаклы байрак; 2) *күч.* форс, шәп тәэсир итү
forum *и. төрле мәгъ.* форум
fosfor *и.* фосфор
fosforışı *и.* фосфоренция, фосфор яктыруы яки шуңа охшаш яктыру
fosforik *и.* фосфор кислотасы
fosforlu *с.* фосфорлы
fosil *и.* фосиль (*геологик катламнарда торып калган хайван, үсемлек калдыклары һ. б.*)
foslamak *ф.* бушка чыгу, әрәмгә китү
fosurdamak *ф.* гыжылдау
fosurdatmak *ф.* тәмәке төтене чыгару
fosur fosur *иярт.* пыш-пыш (*тәмәке суыру*)
fota *и.* шәраб мичкәсе
foto *и.* фото, фотография
fotoğraf *и.* фотография
fotoğrafçı *и.* фотограф
fotojenik *с.* 1) фотографиягә бәйле; 2) фотоген, фотогеник
fotokopi *и.* фотокопия
fötr *и.* фетр, киез
frak *и.* фрак
fraksiyon *и.* (*сәяси*) фракция
francala *и.* озын тар икмәк
frank *и.* франк (*Франция акча берәмлеге*)
fransız *и. с.* француз
fransızca 1. *и.* француз теле. 2. *рәв.* француз телендә, французча
frapan *с.* күзгә ташланып торган
frekans *и.* тетрәү һ. б. ешлыгы
fren *и.* 1) ышкылу; 2) тормоз
frenlemek *ф.* тормозлау
fresk *и.* фреска
freze *и.* 1) кыру, кыру эше; 2) фрезер урдыны (станогы)
frezeci *и.* фрезер
frezelemek *ф.* фрезерлау
friksiyon *и.* фрикция, ышкылу
frişka *и. диңг.* әкрен җил
früktoz *и.* фруктоза
fuar *и.* ярминкә
fuaye *и.* фойе
fuhuş *и.* фәхешлек
fukara *с. и.* ярлы, мескен
funda *и.* себерке үләне
fut *и.* фут (*инглиз озынлык үлчәме*)
futa I *и.* пута, озын һәм чагыштырмача тар билбау
futa II *и.* озын һәм тар ярыш каегы
futbol *и.* футбол
futbolcu *и.* футболчы
füme *и. с.* 1) төтен төсе; 2) ысланган (*балык, ит*)
fümerol *и.* гейзер
fütürist *и.* футурист
futürizm *и.* футуризм

fütüroloji *и.* футурология, киләчәк турындагы фән
füze *и.* ракета
füzen *и.* күмер каләм, карандаш

G

gabardin *и.* габардин (*туныма төре*)
gabari *и. тех.* габарит
gacırdamak *ф.* мыгырдау, күңелгә тия торган тавыш чыгару
gacır gucur *иярт.* шыкыр-шакыр, чыгыр-чыгыр
gag *и.* интермедия
gaga *и.* томшык, кош борыны
gagalamak *ф.* чуку
gagalı *с.* томшыклы
gagavuz *и.* гагауз (*башлыча Көньяк Молдавиядә яшәүче төрки халык*)
gagavuzca 1. *и.* гагауз теле. 2. *рәв.* гагауз телендә, гагаузча
gaip *с.* күз алдында булмаган, күренеп тормаган; гаип
gaiplik *и.* гаиплек, билгесезлек, юкка чыкканлык
gaklamak *ф.* каркылдау (*карга тур.*)
gala *и.* презентация, тәкъдим итү (*билгеле бер әсәрне тәгъдим итү өчен җыелган кичә, мәҗлес һ. б.*)
galaksi *и.* 1) галактика, йолдызлар тупламы; 2) Киек каз юлы
galebe *и.* җиңү; өстенлек □ **galebe çalmak** өстенлек алу, җиңеп чыгу
galeri *и.* 1) *төрле мәгъ.* галерея; рәт; 2) штрек (*шахталарда*)
galeyan *и.* кызулану, кайнарлану
gali *и.* галера (*бер төрле диңгез көймәсе*)
galiba *кер. сүз.* мөгаен, ихтимал, булса кирәк
galip *и. с.* җиңүче ◊ **galip gelmek** җиңеп чыгу
galon *и.* галлон
galvaniz *и.* гальванизация, гальванизлау
galvanometre *и.* гальванометр
gam I *и.* гамма, (*башлыча*) авазлар гаммасы
gam II *и.* гамь
gamlı *с.* гамьле
gamlılık *и.* гамьлелек
gammaz *и. с.* гайбәтче, сүз йөртүче
gammazlamak *ф.* хурлап сөйләү
gamsız *с.* гамьсез
gamsızlık *и.* гамьсезлек
gamze *и.* бит чокыры
gangster *и.* гангстер
gangsterlik *и.* гангстерлык
ganimet *и.* 1) ганимәт, үлҗә, трофей; 2) *күч.* уңайлы мөмкинлек, форсат
gar *и.* вокзал
garabet *и.* гариплек
garaj *и.* гараж
garanti *и.* гарантия
garantilemek *ф.* гарантияләү; кәфил булу
garantili *с.* гарантияле
garantisiz *с.* гарантиясез
garantör *и.* гарантия бирүче, кәфил, гарант
garazlı *с.* кинәле, үчле
garazsız *с.* кинәсез, үчсез

gardiyan *и.* гвардияле, гвардин *сөйл.*
gardiyanlık *и.* гвардия солдаты булу
gargara *и.* 1) голт-голт йоту; 2) гаргарә, авыр хырылдау
garip *с.* 1) читтә йөрүче; зимагур *сөйл.*; 2) серле, аңлашылмас
garnitür *и. төрле мәгъ.* гарнитур
garnitürlü *с.* гарнитурлы
garpçı *и.* көнбатыш мәдәниятен үзләштерү тарафдары, гарепче *иск.*
garson *и.* официант, ашханәдә h. б. хезмәт күрсәтүче
gasil *и.* мәет юу
gâvur *и. с.*) кяфер; 2) *күч.* мәрхәмәтсез
gâvurlaşmak *ф.* кяферләшү
gayret *и.* гайрәт; дәрт, рухый көч
gayretlenmek *ф.* гайрәтләнү
gayretli *с.* гайрәтле
gayretsiz *с.* гайрәтсез
gayrı *кис.* инде, моннан соң
gayri *и.* башка; бүтән
gayzer *и. геогр.* гейзер
gaz I *и.* газ, hавасыман хәлдәге матдә
gaz II *и.* газ, өрфия (*тукыма*)
gazal *и.* 1) газәл, тау боланы; 2) *күч.* гүзәл яр
gazap *и.* ачу, үпкә
gazaptandırmak *ф.* ачуландыру
gazaplanmak *ф.* ачулану
gazaplı *с.* үпкәле, ачулы, ярсу
gazel *и.* 1) газәл, мәхәббәт шигыре; 2) серенада
gazete *и.* газет
gazeteci *и.* газетчы
gazetecilik *и.* газетчылык
gazi *и.* 1) газый, дошманны җиңгән кеше; 2) каһарманнарга бирелгән данлыклы исем
gazlamak I *ф.* газ белән агулау
gazlamak *ф.* керосинлау
gazlanmak *ф.* 1) керосинлану; 2) газлану
gazlı *с.* газлы
gazoil, **gazoyl** *и.* газолин, керосинның бер тере
gazojen *и.* газогенератор
gazyağı *и.* керосин, керосинның бер төре
gebe *и.* көмән, авыр
gebelik *и.* көмәнлелек, авырлылык
gebermek *ф.* аяк сузу, үлү
gebertmek *ф.* үтерү
gebeş *с.* 1) юан, симез; 2) аңгыра
gece *и.* 1) төн; кичә *иск.*; 2) кичә, кичке мәҗлес, төнлә үткәрелә торган күңел ачу мәҗлесе ◊ **gece kuşu** 1) өке; 2) *күч.* төнлә йокламый торган кеше
gececi *и.* төнгелеккә калучы, төнлә эшләүче
geceki *с.* кичәге
gecekondu *и.* 1) төнкунды (*шәһәр идарәсеннән рөхсәтсез корылган бина* (*өй*)); 2) такта өйчек
gecelemek *ф.* 1) төнгә калу, төнләү; 2) төн уздыру; 3) төнгелеккә тукталу
geceli *с.* төнле; *geceli gündüzlü* кичәле-кәндезле
gecelik *и.* төнлек, төнгелек

gecikmek *ф.* кичегү, соңлау
gecikmeli *с.* кичеккән, соңарган
gecikmesiz *с.* кичеккесез, кичектергесез
geciktirmek *ф.* кичектерү
geciktirilmek *ф.* кичектерелү
geç *рәв.* кичегеп, соң, соңарып
geçmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* кичү; 2) күчү, күченү; 3) *төрле мәгъ.* үтү; 4) үтеп керү; 5) үтеп китү; 6) баш тарту, ваз кичү; 7) кичерү, гафу итү; 8) узу, узып китү; 9) күчереп алу; 10) *кит.* теркәлү; 11) элгәшү, (*уку материалын тиешенчә*) үзләштереп бару; 12) (*мич һ. б.*) сүнү; 13) артык пешүдән изрәү (*җимешләр тур.*); 14) *эвф.* үлү, кичү *кит.*; 15) *сир.* мирас булу, мирас булып калу; 16) язу (*мәс., акылдан, һуштан һ. б.*) ◊ **geç**! игътибар итмә!; **geçmiş olsun** *авыруга яисә* бәла-казага дучар булган кешегә әйтелә торган сүз
geçe *рәв.* үткәч, үтеп, узгач, узып (*вакыт тур*)
geçen *с.* үткән, узган, кичкән
geçende *рәв.* баягынак
geçer *с.* 1) йөрешле, кулланылышта булган; 2) үтә торган, үтемле (*товар*)
geçerli *с.* 1) ярарлык, ярыйсы; 2) кулланылышта йөргән; гамәлдә булган
geçerlik *и.* үтемлелек
geçersiz *с.* яраксыз, гамәлдән чыгарылган
geçersizlik *и.* яраксызлык
geçici *с.* үтүче, үтеп китәсе (*күренеш*), кичәчәк
geçilmek ф. кичелү, үтелү (*мәс., юл, гомер*)
geçim *и.* 1) татулык; 2) яшәү, көн-күреш
geçimli *с.* тату; тыныч холыклы
geçinmek *ф.* киченү, ничек тә яшәү
geçirmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* күчерү; 2) кичерү; 3) китәрү, читләтү; 4) аша чыгару, үткәрү; 5) тирәләү; 6) (*нәрсә белән булса да*) тышлау, каплау, каплату; 7) каләм очына алу, язып кую, теркәү; 8) (*мосафирны һ. б.*) озату; 9) (*тартып*) кию, (*тарттырып*) кидерү
geçişmek *ф.* үзара керешү, катышу
geçiştirmek *ф.* 1) әһәмият бирмәү; 2) котылу
geçit *и.* 1) кичү (*урыны*); 2) җир асты кичүе (*мәс., шәһәр урамнарында*)
geçkin *с.* 1) узып киткән; артып киткән; 2) бик олы яшьтәге; 3) артык өлгергән (*үсемлек, яшелчә һ. б. тур.*)
geçmez *с.* 1) үтмәс (*товар*); 2) ялган (*акча*); 3) терелгесез (*авыру, чир*); 4) йогышсыз (*авыру, чир*)
gedik 1. *и.* 1) китек, кителгән җир; җимерек; 2) җитешсезлек. 2. *с.* китек, кителгән
gedikli *с.* китекле, кителгән; җимерекле, җимерелгән
gedilmek *ф.* кителү
geğrek *и.* сөбә кабыргасы, кәкрә *диал.*
gelmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* килү; 2) килешү, ятышу; ятышлы булу; 3) тоелу, кебек күренү; кебек булу; 4) чыдау; 5) ярашу, ярау; 6) якынлашу; 7) (*ярдәмче фигыль буларак*) килү; *elden gelmek* кулдан килү
gelberi *и.* кисәү таягы
gelecek *с. и.* 1) киләчәк; 2) язмыш, күрәчәк
geleğen *и. геогр.* кушылдык
gelen giden *с.* килгән-киткән
gelenek *и.* йола; традиция,
ата-баба йоласы
gelenekli *с.* йолалы
gelgeç *с.* килделе-киттеле; карарсыз, сәбатсыз

gelgit *и.* талкыну, бушка йөрү
gelin *и. төрле мәгъ.* килен ◊ **gelin havası** диңгезнең аз гына дулкынланып торуы
gelince *кер. сүз.* (*фәлән мәсьәләгә*) килгәндә
gelincik *и.* 1) *зоол.* ас; 2) *бот.* лалә, чүл тюльпаны, кызалак
gelinçiçeği *и. бот.* төнбоекның бер төре
gelinkuşu *и.* чыпчыксыман бер кош
gelinlik *и.* 1) киленлек, килен булу; 2) җиткән кыз
gelinparmağı *и.* озынча йөзем
gelir *и.* килер, керем; даими табыш
gelişmek *ф.* 1) үсеп җитү; 2) тазару, көрәю; 3) алгару, үсеш алу
gelişigüzel *рәв.* 1) аннан-моннан; 2) ничек туры килсә шулай
geliştirmek *ф.* үстерү; алгарту
gelme *и. с.* 1) *төрле мәгъ.* килү; 2) килгән
gelmiç *и.* эре балык сөяге
gem *и.* ат авызлыгы; авызлык
gemi *и.* көймә, кораб
gemici *и.* 1) көймәче; 2) диңгезче; матрос; 3) хәрби диңгезче
gemicilik *и.* диңгезчелек
gemilik *и.* верфь
gemlemek *ф.* 1) авызлыклау; 2) *төрле мәгъ.* йөгәнләү
genç *с. и.* яшь, яшь кеше; буйга җиткән ◊ **genç irisi** буйчан малай (яисә кыз)
gençleşmek *ф.* яшәрү
gençlik *и.* 1) яшьлек; 2) буйга җиткәнлек
gene терк. 1) янә, тагын; 2) шулай да
genel *с.* гомуми; генераль
genelge *и.* циркуляр
genelkurmay *и.* генераль штаб
genellemek *ф.* гомумиләштерү
genelleşmek *ф.* гомумиләшү
general *и.* генерал
genetik *и.* генетика
geniş *с.* киң, иңле
genişlemek *ф.* киңәю
genişletmek *ф.* киңәйтү
genişlik *и.* киңлек
genleşmek *ф.* кабару, күләме арту
genlik *и.* 1) киңлек; 2) муллык
geometri *и.* геометрия
geometrik *с.* геометрик
germek *ф.* 1) киерү; 2) киереп кигезү
gerçek *с. и.* 1) дөреслек, чынлык; 2) факт; 3) чын
gerçekçi *с. и.* реалист, чынлыкчы
gerçeklemek *ф.* дөресләү
gerçekli *с.* чын, хак, дөрес
gerçeklik *и.* дөреслек, чынлык
gerçekten *рәв.* чынлап; чыннан да
gerçi терк. гәрчә
gerdan *и.* 1) муен; 2) (*ат түшкәсенең*) муен тирәсе
gerdanlık *и.* муенса
gerdel *и.* чиләк, тубал
gerdirmek *ф.* киерелдерү
gereç *и.* кирәк-ярак; чимал

gereğince *рәв.* кирәгенчә
gerek *хәб. сүз.* кирәк
gerekmek *ф.* кирәгү, кирәк булу
gerekçe *и.* 1) кирәкле шартлар; 2) сәбәп, сылтау; 3) әзерлек
gerekçeli *с.* шартлары булган; әзерлекле
gerekçesiz *с.* шартлары булмаган, әзерлексез
gerekli *с.* кирәкле
gereklik *и.* кирәклек
gereksemek, **gereksinmek** *ф.* кирәксенү
gereksiz *с.* кирәксез
gereksizlik *и.* кирәксезлек
geren *и.* балчыксыл туфрак; уңдырышсыз туфрак
gergef *и.* махсус киерге, киергеч
gergi *и.* 1) киерге, кирге; 2) *сөйл.* пәрдә
gergin *с.* киреңке
gergince *рәв.* киреңке рәвештә
gerginlik *и.* киреңкелек
geri 1. *и.* 1) арт, арткы як; 2) калган өлеш. 2. *с.* артта калган, 3. *рәв.* кире, артка таба (*китү һ. б.*) □ **geri almak** кире алу; **geri çevirmek** кире кайтару; **geri dönmek** кире кайту; **geri kalmak** артта калу; **geri koymak** кичектерү; **geri vermek** кире бирү
gerilmek *ф.* киерелү
gerici I *с.* киерә торган, киергеч (*мускул*)
gerici II *с. и.* искелек тарафдары, кадимче
gericilik *и.* кадимчелек, реакционлык
gerilemek *ф.* 1) кире чигенү, кире борылу; 2) түбәнәю; 3) артта калу
gerileyici *с.* кире чигенүче; регрессив
gerili *с.* киерүле, киерелгән
gerilik *и.* кирелек; артта калганлык
gerinmek *ф.* 1) киерелү (*кеше тур.*); 2) *күч.* рәхәтлек тою
germanistik *и.* германистика,
gerundium *и.* рәвеш фигыль, герундий
getirmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* китерү; 2) килештерү, яраштыру; килешле, ярашлы итү; 3) *күч.* китерү; *hatıra getirmek* хәтергә китерү; *dünyaya getirmek* дөньяга китерү
getiri *и.* керем, табыш
getiriş *и.* китереш
gevmek *ф.* чәйнәү; күшәү
geven *и. бот.* күгән
geveze *с.* 1) телдәр, лыгырдык, телчән; 2) *күч.* сертотмас
gevher *и.* 1) гәүһәр, кыйммәтле таш; 2) *күч.* җәүһәр, гаять кыйммәтле нәрсә
geviş *и.* күшәү (*хайваннар тур.*); □ **geviş getirmek** күшәп тору
gevrek *с. и.* 1) кетердек; уалучан; 2) *күч.* сөенечле (*көлү тур.*); 3) уалучан печенье (*төре*)
gevremek, **givremek** *ф.* 1) куырылу; кетердәрлек булып кибү; 2) *сөйл.* (иген) өлгерү
gevşemek *ф.* 1) бушау; 2) сүлпәнәю
gevşek *с.* 1) буш; 2) *күч.* сүлпән, салмак, җансыз
geyik *и.* болан, киек *диал.*
geyikdili *и. бот.* сыер теле
geyikotu *и. бот.* сәдәф уты

gez I *и.* 1) укның керешкә куела торган киртеге, киз; 2) төзәгеч (*мылтыкта һ. б.*)
gez II *и.* 1) төенле бау (*җир үлчәү өчен*); 2) (*төзелештә балта осталары тарафыңнан кулланыла торган*) үлчәгеч
gezdirmek *ф.* 1) гиздерү; 2) өләшү, тарату
gezegen *и.* планета
gezelemek *ф.* 1) әйләнү, тулгану; 2) аптырап тору
gezenti *и. с.* йөремсәк
gezgin 1) *к.*: **gezginci**; 2) *с.* йөрүчән, хәрәкәтчән
gezginci *с.* илгизәр; сәяхәтче
gezi I *и.* сәяхәт
gezi II *и.* мамык һәм ефәкне кушыл тукылган тукыма төре
gezinti *и.*) сәйран; тамаша итеп йөрү; 2) гизеләчәк җир, сәйран урыны, тамашалык; 3) коридор, йөренерлек мәйдан; 4) *муз.* көйдән көйгә күчү
gıcık *и.* 1) тамак төбе кымыржуы; 2) *күч.* котыртучы, тәңкәгә тиюче
gıcırdamak *ф.* шыгырдау, чыгырдау
gıda *и.* ашамлык, туклану әйбере; аш-су; тәгамь; азык-төлек
gıdaklamak *ф.* кытаклау
gıdalanmak *ф.* туклану, тәгамьләнү
gıdalı *с.* туклыклы
gıdasız *с.* туклыксыз
gıdıklamak *ф.* 1) кытыклау; 2) *күч.* күңелгә хуш килә торган сүзләр сөйләү
gıpta *и.* көнчелек; □ **gıpta etmek** көнчелек хисе кичерү, көнләшү
gırgır *и.* 1) дәвамлы һәм тупас тавыш; 2) ыгы-зыгы, вак-төяк чәйнәшү
gırnata *и. муз.* кларнет
gırt *иярт.* кырт; *gırt gırt* кырт-кырт, кытыр-кытыр
gırtlak *и.* 1) сулыш юлы, бронх; 2) бугаз; 3) *күч.* ашап-эчү
gırtlaklamak *ф.* бугаздан буу
gıyaben *рәв.* 1) үзе югында; 2) кеше аркылы, үзен күрмичә
gibi *бәйл.* кебек, кеби *иск.*; шикелле
gibilerden *бәйл.* шуның ише(ләрне)
gicişmek *ф.* кычыну
gider *и.* чыгым
gidermek *ф.* китәрү, бетерү
giderayak *рәв.* чыгып китәргә торганда
giderek *рәв.* әкренләп; тора-бара
gidici *с.* китүче, китәчәк (*кеше*)
girmek *ф. төрле мәгъ.* керү **girgin** *с.* елгыр, һәр җиргә керүчән
giriş I *и.* кереш, керү рәвеше (процессы)
giriş *и.* кереш, сүз башы, мөкаддимә *иск.*
girişim *и.* (*бер эшкә*) керешү
girişimci *и.* инициатор
girişken *с.* елгыр, һәркем белән танышучан
girişmek *ф.* 1) (*бер эшкә*) керешү, тотыну; 2) *күч.* бәрелешү, кыйнаша башлау
girmelik *и.* керү акчасы
gişe *и.* билет сату (акча өләшү һ. б.) кассасы
git gide *рәв.* тора-бара
gitar *и.* гитара
gitarcı *и.* гитарачы
gittikçe *рәв.* тора-бара
giymek *ф.* 1) кию; 2) *күч.* (*авыр сүз һ. б.га*) түзү; дәшмичә үткәрү
giyecek *и.* кием-салым
giyim *и.* кием □ **giyim kuşam** кием-салым, өс-баш; **giyim evi** кием-салым кибете

giyinmek *ф.* 1) киенү; 2) (киемне) билгеле бер кибеттән генә алу, билгеле бер ательеда гына тектерү □ **giyinip kuşanmak** киенү-ясану
giyinik *с.* киенгән
giyinti *и.* кием-салым
giyotin *и.* гильотина
giysi *и.* өс-баш, кием-салым
giz I *и.* сер
giz II *и. диңг.* корабның койрык өлешендәге авыштырып куелган байрак терәге
gizlemek *ф.* яшерү
gizlenmek *ф.* яшеренү
gizli *с.* яшерен
gizlice *рәв.* яшерен
gizli gizli *рәв.* яшертен
glikoz *и. хим.* глюкоза
gliserin *и.* глицерин
goblen *и.* гобелен
gocunmak *ф.* борчылу
gofret *и.* вафля (*печенье төре*)
gol *и.* (*футболда һ. б. ш. уеннарда*) гол; туп кертү
golcü *и.* туп кертүче
golf *и.* гольф (*спорт уены төре*)
goril *и.* 1) *зоол.* горилла; 2) *күч.* сакчы, каравылчы
göbek *и.* 1) кендек; 2) *күч.* үзәк
göçmek *ф.* күчү, күченү
göçebe *и. с.* күчмә
göçer *с.* күчмә
göçermek *ф.* күчерү
göçmen 1. *и.* эмигрант; качак; мөһаҗир. 2. *с.* күчмә, сәйяр (*мәс., кошлар*)
göçücü *и. с.* күчүче, күченүче
göçünmek *ф.* күченү
göçürmek *ф.* күчерү
göçüş *и.* күчеш
göden *и. анат.* күтән
göğem *с.* күгелҗем, күксел
göğüs *и.* 1) күкрәк; 2) көймәнең алды (күкрәге) ◊ **göğüs geçirmek** ah-вah итү; **göğüs germek** күкрәк киереп каршы тору
göğüslü *с.* күкрәкле, киң күкрәкле
gök I *с.* күк
gök *и.* күк, күк йөзе; **gök ekseni** җир күчәре ◊ **göke çıkmak** 1) күккә ашу; 2) күтәрелеп бәрелү, бик ачулану; **gökden inmek** күктән төшү (иңү)
gökçe *с.* күгелҗем
gökçek *с.* гүзәл
gökçül *с.* аксыл күк, күксел
gökdelen *и.* күксөзәр (небоскреб)
gökkuşağı *и.* салават күпере
gökküresi *и.* күк гөмбәзе
göktaşı *и.* метеор, күк ташы
göktürk *и. тар.* күктөрек (*740 елга кадер хәзерге Монголия территориясендә яшәп, соңыннан кара диңгездән Амур елгасына чаклы сузылган империя корган борынгы төрки халык*)
gökyakut *и.* сапфир
gökyofu *и.* Киекказ юлы

gökyüzü *и.* күк йөзе
göl *и.* кул; буа
gölek *и.* күлдәвек
gölet *и.* кечерәк буа, бөя
gölge *и.* 1) төрле мәгъ. күләгә; күләгәле җир; 2) ышык
gölgebalığı *и. зоол.* шамбы (жумба)
gölgelemek *ф.* күләгәләү
gölgeli *с.* күләгәле
gölgesiz *и.* күләгәсез
gömmek *ф.* күмү; күмелдерү
gömgök *с.* күм-күк, зәп-зәңгәр
gömlek *и.* 1) күлмәк; 2) сүрү, тышча; 3) династия, буын; 4) лампы куыгы; 5) папка ◊ **gömlek eskitmek** "чабата туздыру", мәгънәсезгә гомер уздыру
gömlekçi *и.* күлмәкче, күлмәк тегүче яисә сатучы
gömleklik *с. и.* күлмәклек
gömük *с.* күмелгән
gömüldürük *и.* (*атларга кидерелгән*) күкрәк каешы, күмелдерек (*ияр артка китмәсен өчен*)
gömültü *и.* аучыларның яшеренеп торуы өчен чокыр
gömülü *с.* күмүле, күмелгән
gön *и.* күн
göndermek *ф.* юллау, күндерү
gönenmek *ф.* кинәнү
gönendirmek *ф.* кинәндерү
gönül *и.* 1) *төрле мәгъ.* күңел; 2) горурлык ◊ **gönül açılmak** күңел ачылу; **gönül almak** (*кемнең дә булса*) күңелен ачу; **gönül bulanmak** күңел болгану; **gönül darlığı** күңел тарлыгы; **gönül eğlencesi** күңел юаткыч; **gönülü kalmak** күңеле калу; **gönülünce** (**gönülümce**) теләгәнчә (теләгәнемчә)
gönüllemek *ф.* көнләү, көнләшү; ачулану
gönüllü *с. и.* 1) күңелле; үз теләге белән эш итүче, үзихтыярый; 2) горур; 3) *сөйл.* сөекле, сөйгән
gönülsüz *с.* 1) теләксез; ихтыярсыз; 2) горурлыксыз, горурсыз
görmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* күрү; 2) күрешү, күрешеп сөйләшү ◊ **görmediğe dönmek** 1) тәмам савыгып җитү; 2) кайгы-хәсрәтне оныту
göre *бәйл.* 1) күрә, карап; *büyüklüğüne göre* зурлыгына күрә; 2) буенча; 3) =ча, чә кушымчасы белән тәрҗемә ителә; *bana göre* минемчә
görenek *и.* гадәт, йола
göreneksiz *с.* гадәтсез, йоласыз
görev *и.* (рәсми) вазыйфа; эш, эш күрү; эш урыны, хезмәт
görevlenmek *ф.* вазыйфа алу
görevlendirmek *ф*. вазыйфә бирү
görevli *с.* вазыйфалы, хезмәтле
görevsiz *с.* вазыйфасыз, эшсез
görgü *и.* 1) әдәп-инсаф; 2) эш тәҗрибәсе, тәҗрибәлелек
görgülü *с.* 1) дөнья күргән, тәҗрибәле; 2) инсафлы
görgüsüz *с.* 1) әдәп-инсафсыз; әдәп-хаясыз; 2) тәҗрибәсез
görünmek *ф.* күренү
görünüş *и.* күренеш, манзара
görüş *и.* 1) күрү; 2) *күч.* караш
görüşmek ф. күрешү
göstermek *ф. төрле мәгъ.*. күрсәтү
gösterge *и.* 1) *төрле мәгъ.* күрсәткеч; 2) күрсәтмә □ **gösterge bilimi** информатика

gösteri *и.* 1) смотр, демонстрация; 2) күргәзмә
göstermelik *и. с.* 1) күрсәтмәлек, үрнәк; 2) күрсәтү өчен хәзерләнгән
gösterme parmağı *и.* имән бармак
göstertmek *ф.* күрсәттерү
götürmek *ф.* 1) китерү, алып китерү; 2) алып китү; 3) *күч.* юкка чыгару; 4) *күч.* үтерү
götürü *рәв.* күмәртәләп, берьюлы, тоташ (*бәя биреп*)
götürüm *и. сөйл.* сабырлык
gövde *и.* 1) гәүдә; 2) түшкә; 3) кәүсә; 4) төп өлеш; 5) *гр.* сүз нигезе
gövem *и.* кигәвен
gövermek *ф.* 1) яшелләнү, яшәрү; 2) күгелҗемләнү
göverti *и. сөйл.* яшелчәләр
göymek *ф.* яндыру; ягу
göynümek *ф.* 1) көенү, хәсрәтләнү; 2) пешү, өлгерү (*җимешләр тур.*)
göynük *с. и.* 1) янган, көйгән; 2) кояшта янган; 3) ышна җире; 4) *күч.* кайгылы
göyük *и.* 1) янган; көйгән; көек; 2) төн кызу (*авырудан*)
göyünmek *ф.* көенү
göz *и.* 1) *төрле мәгъ.* күз; 2) чокырчык, күз *сөйл.*; 3) аерым тартма, бүлекчә, бүлемтек; 4) игътибар, күз *иск.*; 5) *сөйл.* урта төш □ **göz akı** күз агы; **göz bilimi** офтальмология ◊ **göz almak** күз камаштыру; **göz atmak** күз ату, карап алу яисә карап тору; **göz çıkarmak** күз чыгару; **göz değmek** күз тию; **göz dikmek** күз текәү; **göz evi** күз уемы, күз чокыры; **göz etmek** күз белән ымлау; **göz kapağı** күз кабагы; **göz karası** күз карасы; **göz kalmak** үзенә булдырасы килү; **göz açmak** 1) күз ачу, бераз тынычлану; 2) дөньяга килү; 3) кемнең дә булса күзен ачу, ачык аңлату; **göz ağrısı** дәрт, мавыгу; **göz(ü) açık** аңлы, аңлап торучы; тиз төшенүче; **göz kesmek** булдырачагына ышану; **göz önü** күз уңы, күз алды; **gözden düşmek** күздән төшү; **göze batmak** күзгә ташлану
gözbağcı *и.* күз буучы, сихерче
gözbağı *и.* күз буу
gözbebeği *и.* күз бәбәге, күз кешесе *сөйл.*
gözcü *и.* 1) каравылчы; 2) шымчы, күзәтче
gözcülük *и.* 1) каравылчылык; 2) шымчылык
gözdağı *и.* куркытып тору
gözde *с.* иң яратыла торган; популяр; модада булган
gözdişi *и.* азау теше
göze *и.* 1) күзәнәк; 2) кечкенә чишмә
gözemek *ф.* 1) тупчу, тишекне үреп ямау; 2) (*тигезсез тишелгән үсентене сирәк җирләренә*) күчереп утырту
gözebiltmi *и.* цитология (фәне)
gözene *и.* умартачы битлеге
gözenek *и.* 1) күзәнәк; 2) кечкенә уем, тишекчә, күзәнәк; 3) бидәр, рельефлы нәкыш
gözenekli *с.* 1) күзәнәкле; 2) тишекчәле
gözeneksiz *с.* күзәнәксез
gözer *и.* эре иләк, ындыр иләге
gözetmek *ф.* 1) күз-колак булу; 2) күз алдында тоту; игътибар итү; 3) көтү (*форсатны, вакытны һ. б.*)
gözetici *и.* 1) күз-колак булучы; 2) күзәтүче
gözetlemek *ф.* яшеренеп күзәтү
gözkapağı *и.* күз кабагы
gözlemek *ф.* 1) күзләү; көтү; 2) игътибар белән күзәтү; 3) тикшерү; 4) яшеренеп күзәтү

gözlü *с.* 1) күзле; 2) күзәнәкле, тишекле
gözlük *и.* күзлек
gözlükçü *и.* күзлекче
gözlüklü *с.* күзлекле;
gözlüklü yılan зоол. күзлекле елак;
göz yuvası күз оясы, күз уемы
gözsüz *с.* күзсез, сукыр
gözsüzlük *и.* күзсезлек
gözükmek *ф.* күренү
gözyaşı *и.* күз яше
gramer *и.* грамматика
gravür *и.* гравюра
gravürcü *и.* гравюрчы
grek *и.* борынгы грек кешесе
grekçe 1. *и.* борынгы грек теле. 2. *рәв.* борынгы грек телендә
gres, **gresyağı** *и.* машина мае
grev *и.* забастовка
grevci *и.* забастовкачы
gri *с.* соры, көл төсендәге
grip *и. мед.* грипп
guguk *и.* кәккүк, күке
guguklu *с.* күкеле (*сәгать*)
gulu gulu *иярт.* гол-гол, голдыр-голдыр (*күркә голдырдавы*)
gurbet *и.* горбәт, читтә йөрү
gurbetçi *и.* горбәттәге кеше, читтә йөрүче, зимагур
gurbetlik *и.* читтә булу
gurlamak *ф.* быгырдау
guruldamak *ф.* (*эч*) быгырдау
gurup *и.* 1) (*кояш, ай*) бату (баю); 2) *күч.* бетү, төкәнү, соңына килү
gurur *и.* горурлык, горур *иск.,* масаю
gururlanmak *ф.* горурлану
gururlu *с.* 1) горур; горурлы *иск.*; 2) масаюлы
gusto *и.* зәвык
gusül *и.* госел, ритуал коену
gusülhane *и.* госелханә, коену бүлмәсе
gübre *и.* 1) тирес; 2) ашлама
gübreböceği *и. зоол.* тирес корты
gübrelemek *ф.* тиресләү, ашлау
gübrelik *и.* тиреслек
gücenmek *ф.* үпкәләү, ачулану
gücendirmek *ф.* хәтерен калдыру, кәефен кыру, үпкәләтү
gücük *и.* 1) зәгыйфь, көчсез; 2) көтек, койрыгы кыскартылган ◊ **gücük ay** көтек ай, февраль
güç I *и.* 1) көч, куәт, кодрәт; 2) потенциал; 3) эшләү, мәшгульлек; 4) *күч.* уңдырыш
güç II *рәв. с.* 1) кыен, авыр, көчкә; 2) мөшкел, кыенлыклы ◊ **güçe sarmak** мөшкелләнү
guçbelâ *рәв.* көчкә, кыенлык белән
güçlenmek *ф.* көчәю
güçleşmek *ф.* авырлашу, кыенлашу
güçlü *с.* көчле
güçlük *и.* 1) кыенлык, авырлык; 2) тоткарлык, комачау
güçlülük *и.* көчлелек

güçsüz *с.* көчсез
güçsüzlük *и.* көчсезлек
güdü *и.* 1) инстинкт; 2) эчке психологик мотив
güdük *с.* 1) көтек, койрыксыз; 2) ярым-йорты
güdükleşmek *ф.* көтекләнү, көтекләшү
güdüklük *и.* көтеклек
güdülmek *ф.* 1) көтелү; 2) алга сөрелү
güdüm *и.* 1) идарә; 2) юнәлдерү; 3) көтелгән нәрсә; **güdüm bilimi** идарә гыйлеме
güdümcü *и.* идарәче
güdümlü *с.* 1) идарәле; 2) юнәлтелгән, юнәлдерешле
güfte *и.* җырның h. б. музыкаль әсәрнең сүзләре
güğüm *и.* саплы чүлмәк; бакыр комган
gül *и.* гел, роза
gülmek *ф. төрле мәгъ.* көлү
güldür güldür *иярт.* гөлдер-гөлдер; челтер-челтер
güldürmek *ф.* көлдерү
güldürücü *с.* көлдерүче; көлдергеч
güleç *с.* көләч
güleçlik *и.* көләчлек
gülgiller *и. бот.* розасыманнар
gülsuyu *и.* гөл (роза) суы; хушбуй
gülümsemek *ф.* көлемсерәү
gülünç *с.* көлке
gülünçleşmek ф. көлкегә әйләнү
gülünçlü *с.* көлкеле
gülüşmek *ф.* көлешү
gümbürdemek *ф.* гөмбердәү
güme *и.* куыш (*аучы, каравылчы һ. б. өчен*)
gümeç *и.* кәрәз
gümrük *и.* 1) тамгаханә (*таможня*); 2) баҗ (*пошлина*)
gümrükçü *и.* 1) таможня хезмәткәре; 2) баҗ җыючы, тамгаханәче, тамгачы
gümrüklemek *ф.* читтән кергән товарны тамгалау
gümrüklerimek *ф.* тамгалану (*читтән кергән товар турында*)
gümrüklü *с.* тамгаланган, тамгалы (*товар*)
gümrüksüz *с.* тамгаланмаган, тамгасыз (*товар*)
gümüş *и. с. төрле мәгъ.* көмеш
gümüşbalığı *и. зоол.* көмешбалык (*диңгез балыгы төре*)
gümüşçü *и.* көмешче
gümüşî, **gümüşü** *с.* көмеш төсендәге
gümüşlemek *ф.* көмешләү
gümüşlü *с.* көмешле
gümüşrengi *с.* көмеш төсле (төсендәге)
gümüşsü *с.* көмешсу; кемешсыман
gün I *и.* 1) *төрле мәгъ.,* кояш; көн; 2) көн, тәүлек; *gön aşın* көн аша, ике *көнгә* бер; *ertesi gön* берсекөн; **bir gün** бер көн, бер тапкыр; **gün batısı** көнбатыш; **gün doğusu** көнчыгыш; **günün birinde** көннәрдән бер көнне; **bugünkü günde** бүгенге (бүгенгесе) көндә; **günden güne** көннән-көн, көннән-көнгә ◊ **gün bu gün** нәкъ вакыты; **günü gününe görmek** үз вакытында башкарып (үтәп) бару
günah *и. с. төрле мәгъ.* гөнаһ
günahkâr *и.* гөнаһлы, гөнаһ эшләүче, гөнаһкяр
günahlı *с.* гөнаһлы
günahsız *с.* гөнаһсыз

günaydın *ы.* хәерле иртә; хәерле көн
günbatımı *и.* кояшбаеш
güncel *с.* көнүзәк
günçiçeği *и. сөйл.* көнбагыш
gündelik *и. с.* 1) көнлек эш хакы, көнлек; 2) көндәлек, һәркөнге
gündelikçi *и.* көнлекчә
gündem *и.* көн тәртибе (*җыелышка куелган мәсьәләләр*)
gündoğusu *и.* көнчыгыш
gündüz *рәв. төрле мәгъ.* көндез
göndüzcü *и.* көндез укучы; көндез эшләүче
gündüzün *рәв.* көндезен
günebakan *и.* көнбагыш
güneş *и.* (*күк җисеме буларак*) кояш ◊ **güneş gibi** 1) кояш кебек (нурлы, матур); 2) көн кебек (ачык, билгеле); **güneşi balçıkla sıvamak** ачык хакыйкатьне яшереп, бозып күрсәтергә маташу
güneşlenmek *ф.* 1) кояшта кибү; 2) кояшта кызыну
güneşletmek ф. кояшта киптерү
güneşli *с.* кояшлы
güneşsiz *с.* кояшсыз
güney *и.* көньяк
güneybatı *и.* көньяк-көнбатыш
güneydoğu *и.* көньяк-көнчыгыш
günlük I *и.* күнлек, ладан (*төтәсләү өчен кулланыла торган хушисле агач сагызы*)
günlük *с.* 1) көнлек, бер көнгә җитәрлек яисә бер көндә башкарылган; 2) билгеле көн яшәгән, булып узган һ. б. ш.; *beş günlük çocuk* биш көнлек бала; 3) көндәлек дәфтәре
günücü *и.* көнче
günücülük *и.* көнчелек
güpegündüz *рәв.* көпә-көндез
gür *с.* 1) күпләп (мул) үскән; куе; *gür saç* куе чәч; 2) көр
gürcü *и.* грузин
gürcüce 1. *и.* грузин теле. 2. *рәв.* грузин телендә, грузинча
güreş *и.* көрәш
güreşmek *ф.* көрәшү
güreşçi *и.* көрәшче
gürlemek *ф.* гөрләү, гөрелдәү
gürleşmek *ф.* көрәю
gürlük *и.* көрлек
gürüldemek *ф.* гөрелдәү
gürültü *и.* 1) гөрелте; 2) *күч.* тавыш-гауга
gürültücü *и.* тавышчан кеше
gürültülü *с.* гөрелтеле; шау-шулы
gürültüsüz *рәв. с.* 1) гөрелтесез; 2) тавыш-тынсыз
gütmek *ф.* 1) (*терлек*) көтү; 2) күч. (*берәр уйны, ниятне*) тормышка ашырырга омтылу (тырышу); *amaç gütmek* максатка омтылу
güve *и. зоол. көя*
göveç *и.* 1) керәч чүлмәк; 2) чүлмәк ашы
güvelenmek *ф.* көяләү
güven *и.* 1) ышаныч; 2) егетлек, батырлык □ **güven kazanmak** ышаныч казану; **güven vermek** ышаныч уяту, ышаныч бирү; **güveni sarsılmak** ышанычы төкәнү
güvenmek *ф.* ышану, таяну

güvence *и.* 1) әманәт, залог; 2) гарантия □ **güvence vermek** гарантия бирү
güvenceli *с.* гарантияле
güvencesiz *с.* гарантиясез
güvenç *и.* ышаныч
güvenli *с.* ышанычлы
güvensiz *с.* ышанычсыз
güvercin *и. зоол.* күгәрчен
güvercinboynu, **güvercingöğsü** *и.* яшел, зәңгәр һәм ал төсләрдә ялтыраган төс
güverte *и.* палуба
güverteli *с.* палубалы
güvey *и.* кияү
güvez *с.* шәмәхә кызыл
güya *кис.* гүя (ки)
güz *и. сир.* көз
güzel *с.* 1) гүзәл, матур; 2) кимчелексез, һәйбәт; 3) сөйгән яр, сөеше
güzelce *с.* әйбәт кенә, ярыйсы гына
güzelleşmek *ф.* матураю; яхшыру
güzellik *и.* гүзәллек, матурлык
güzergâh *и.* кичү, кичем; юл, трасса
güzey *и. геогр.* күләгәле як, кояшсыз як
güzide *с.* сайлап алынган
güzlemek *ф.* көзләү, көз үткәрү
güzlek *и.* 1) көзге яңгырлар; 2) көз үткәрү урыны
güzlük *с.* 1) көзен башкарылган; 2) көзен чәчелгән (*ашлык*)
güzün *рәв.* көзен

H

ha 1. *ы.* ha, haй-haй, (*гаҗәпләнүне белдерә*). 2. *кис.* ә, йә; *sen geldin ha?* син килдең, ә?. 3. *терк.* я (йә); *ha bu gün, ha yarın* я бүген, я иртәгә
habaset *и. иск.* 1) явызлык, усаллык; ачу; 2) начарлык, әшәкелек
habbe *и. иск.* бөртек ◊ **habbeyi kubbe yapmak** энәдән дөя ясау
haber *и.* хәбәр, яңалык □ ha**ber vermek** хәбәр итү ◊ **dış haberler** чит ил яңалыклары
haberci *и.* хәбәр китерүче, хәбәрче
haberdar *с.* хәбәрдар
haberleşmek *ф.* хәбәрләшү
habersiz *с.* хәбәрсез
habersizlik *и.* хәбәрсезлек
Habeş *и.* Эфиопиядә яшәүче төп халык
habis *с.* 1) *иск.* усал, ачулы; явыз, яман; 2) азгын, тиз төзәлми торган (*шеш, яра*); тиз үтми торган (*авыру, чир*)
habl *и.* 1) канат, аркан; 2) җепсел
hac *и.* хаҗ
haccetmek *ф.* хаҗ кылу
hacet *и. дини.* хаҗәт
hacı *и.* хаҗи
hacılarkuşağı *и.* салават купере
hacil *с.* тартынучан, оялчан
hacim *и.* 1) күләм; 2) зурлык
hacimli *с.* күләмле
haç *и.* хач, тәре; □ **haça germek** тәрегә кадаклау; **Kızıl Haç Cemiyeti** Кызыл Хач Җәмгыяте

haçlamak *ф.* тәрегә кадаклау
haçlı *с.* хач; тәреле
haçlılar *и.* төре походларында катнашкан кешеләр
haçvarî *и.* әвернә
had(**d**) *и.* чик, сызык, дәрәҗә ◊ **haddini aşmak** чиктән ашу; **haddini bildirmek** урынына утырту; **haddinden fazla** чиктән тыш
hâd(**d**) *с.* 1) үткен; 2) киеренке, кискен
hadde *и.* прокатлау станы
hademe *и.* җыештыручы, хезмәтче
hadım *и.* евнух, хәрәм агасы
hadımlaştırmak *ф.* печү
hadi *ы.* әйдә, әйдә әле, я ярый, яле; *hadi gidelim* әйдә киттек; *hadi yolun açık olsun!* я ярый, яхшы юл сиңа!
hadis *и.* хәдис, пәйгамбәр сүзе
hâdise *и.* вакыйга; гауга, инцидент
hâdiseli *с.* гаугалы, ызгышлы
hâdisesiz *с.* тыныч, ызгышсыз, җәнҗалсыз
hadsiz *с.* чикләнмәгән
haf *и. спорт.* ярымсакчы (*футболда*)
hafakan *и.* йөрәк тибеше тетрәү, калтырау
hafız *и.* хафиз, коръән хафиз
hafıza *и.* хәтер; **hafızasını kaybetmek** хәтерен югалту
hafızalı *с.* зиһенле, хәтерле
hafif *с.* 1) җиңел; 2) җилбәзәк, җиңел караучан; **hafif elbise** җиңелчә кием; **hafif gölge** ярым күләгә; **hafif endüstri** җиңел промышленность ◊ **hafif bir hareket** уйламыйча эшләгән эш
hafifçe *рәв.* җиңелчә
hafiflemek *ф.* җиңеләю
hafiye *и.* күзәтүче, яшерен агент
hafre *и.* казылмалар (*археологик*)
hafta *и.* атна; *hafta başı* атна башы; *geçen hafta* үткән атна
haftalık *с.* атналык
haftalıkçı *и.* атналап эшләүче
haftan *и.* кафтан
haftaym *и. спорт.* тайм (*футболда 45 минутлык уеннан соң 15 минутлык ял вакыты*)
haham *и.* раввин (*яһуд динендәге руханый*)
haile *и. театр.* трагедия
hain *и.* хаин, сатлык җан
hainleşmek *ф.* мәкерлек эшләү
haiz *с.* (*нәрсәгә дә булса*) ия булган
hak *и.* хак тәгалә, алла, ходай
hak *и.* хак, хаклык, хокук; □ **hak etmek** лаек булу; **hak eşitliği** тигезлек, тигез хокуклылык
hakan *и.* каган
hakanlık *и.* 1) каганлык, каганат; 2) каган булу
hakaret *и.* хәкарәт, хурлау, мыскыллау
hakem *и.* 1) судья, арбитр; 2) жюри
hakemlik *и.* арбитраж
hakikat *и.* хакыйкать, дөреслек; □ **hakikat olmak** чынга ашу
hakikatsiz *с.* аумакай
hakikî *с.* хакыйкый, чын, дөрес

hakim *и.* хәким, белгеч, галим, акыллы кеше
hâkim *и.* 1) хаким, өстен, югары; 2) хужа, түрә
hâkimiyet *и.* хакимият; хакимлек итү
hâkimlik *и.* хакимлек
hakir *с.* түбән, дәрәҗәсез
hakkâk *и.* гравер
hakkaniyet *и.* дөреслек, хаклык
hakketmek *ф.* лаек булу, ирешү, казану
hakkında *и.* хакында, турында
haklamak *ф.* тар-мар итү; вату, җимерү
haklaşmak *ф.* исәпләшү; исәп-хисапны өзү
haklı *с.* хаклы; *haklı talepler* хаклы таләпләр
haklılık *и.* хаклык, хаклылык
haksız *с.* хаксыз
hâl I *и.* хәл, халәт, торыш; *baygın hâlde* аңсыз хәлдә; *hâl hatır sormak* хәл сорашу; *hava hal/һава* торышы
hal II *и. иск.* карар, нәтиҗә □ **hal etmek** хәл итү
hâl *и.* түбәсе ябылган базар
hala *и.* апа (*әтинең сеңпесе яисә апасы*)
hâlâ *рәв.* хәзергә кадәр; әле дә; ***hâlâ*** *ödemedi* хәзергә кадәр түләмәде
halat *и.* аркан, канат
halâvet *с.* татлы, баллы ◊ **sözde halâvet** тәмле сүзле
halayık *и.* 1) кол; 2) ялчы, хезмәтче
halazade *и.* әтинең сеңлесенең (яисә апасының) кызы (яисә улы)
halef *и.* дәвам иттерүче, алмашка килүче
halel *и.* зарар, зыян
halen *рәв.* хәзер, хәзерге вакытта
halı *и.* келәм, палас
halıcı *и.* келәмче, келәм тукучы
halıcılık *и.* келәм тукучылык
halife *и.* хәлиф
halifelik *и.* 1) хәлифәт; 2) хәлиф булу
halis *и.* кушылмаган, саф
halisane *рәв.* чын йөрәктән, эчкерсез
halita *и.* катнашма, кушылма
halk *и.* халык; □ **halk ağzı** сөйләш (*диалект эчендәге*)*′*, **halk oyu** референдум, халык фикере
halka *и.* бөжра, алка
halkalamak *ф.* 1) бөжра хәленә китерү; 2) коршау
halkalanmak *ф.* бөжралану
halkalı *с.* бөжралы
halkavi *с.* бөжра рәвешендә булган
halkçılık *и.* халыкчанлык
hallaç *и.* мамык тараучы (тәрәшләүче)
hallaçlamak *ф.* тәрәшләү, тарау (мамыкны)
halletmek *ф.* хәл итү
halli *с.* хәлле, мул тормышлы
halsiz *с.* хәлсез, хәрәкәтсез
halsizlik *и.* хәлсезлек; мохтаҗлык
halt *и.* күңелгә ятмаган эш
halter *и. спорт.* 1) штанга; гантель; 2) авыр атлетика
halterci *и.* штангачы

halvet *и.* 1) *иск.* кешеләрдән читләшү, ялгызлык; 2) *иск.* аулак җир; 3) мунчада эссе салу бүлмәсе ◊ **halvet gibi** бик эссе (*бүлмә*)
ham *с.* 1) өлгермәгән, пешмәгән; 2) чи, эшкәртелмәгән; 3) *күч.* тормышка ашмый торган, буш
hamak *и.* гамак, үрмә ятак
hamakat *и. иск.* ахмаклык, юләрлек
hamal *и.* йөк ташучы
hamam *и.* мунча; □ **hamam yapmak** мунча керү
hamamböceği *и.* кара таракан
hamarat *с.* уңган, җитез (*хатын*)
hamasî *с.* героик, легендар (*дастан, шигырь*)
hamaylı *и.* бөти, амулет, талисман
hamel *и.* Хәмәл йолдызлыгы
hamhalat *с.* тупас, ямьсез
hamil 1. *с.* төялгән; *kömür hamil vapur* күмер төялгән пароход. 2. *и.* ия, хуҗа, биләүче
hamile *с.* йөкле, авырлы (*хатын*)
hamilelik *и.* йөклелек, балага узганлык
hamiş *и.* хат тәмамланганнан соң өстәп язылган язу (*post scriptum*)
hamiyet *и.* патриотизм, гражданлык
hamla *и. диңг.* 1) ишкәк ишү; 2) көймә койрыгындагы утыргыч
hamlamak *ф.* көчсезләнү, хәлсезләнү (*хәрәкәтсезлектән*)
hamlacı *и.* (*зур көймәнең койрыгында утырган*) ишкәкче
hamur *и.* камыр; □ **hamur açmak** камыр җәю; **hamur işi** камыр ризыклары
hamurlaşmak *ф.* камырлану; йомшару
hamursuz *с.* төче; *hamursuz ekmek* төче күмәч
hamut *и.* камыт
han I *и.* хан; *han soyu хан* нәселе
han II *и.* юлаучылар йорты; караван-сарай ◊ **han gibi** сарай кебек киң
hançer *и.* хәнҗәр
hançere *и.* бугаз □ **hançere sesleri** бугаз тартыклары
hançerlemek *ф.* хәнҗәр белән кадау
hane *и.* 1) өй; *hane halkı* өйдәгеләр; 2) бүлмә; 3) шакмак (*шахмат тактасында һ. б.*); бүлек; 4) *мат.* санның урыны
hanedan 1. *и. тар.* династия, нәсел, буын. 2. *с. күч.* кунакчыл
hangar *и.* япма, лапас
hangi *а.* кайсы, нинди?
hangisi *с.* кайсысы
hanım *и.* ханым
hanımböceği *и.* камка, чуар таракан
hani *кис.* 1) кая; кая соң; 2) иде бит; *hani geçen gün yanımda oturuyordu işte* □ *adam* кичә янымда утыра иде бит, менә шул кеше; 3) һич булмаса, ичмаса; 4) дөресен әйткәндә
hanlık *и.* ханлык
hantal *с.* шыксыз, килбәтсез, шөкәтсез
hantallaşmak *ф.* шыксызлану, ямьсезләнү
hap *и.* 1) таблетка, дару сәдәбе, пилюля; *hap almak* дару эчү; *uyku hapı* йокы даруы; 2) *арго.* әфьюн
hapçı *и.* наркоман
hapır hapır, **hapır hupur** *иярт.* хапыр-хопыр
hapis *ф. и.* тоткын, кулга алынган □ **hapis yatmak** төрмәдә утыру
hapishane *и.* төрмә

hapsetmek *ф.* 1) кулга алу, төрмәгә утырту; 2) *күч.* тоткарлау
hapşırmak *ф.* төчкерү
har I *иярт.* шабыр-шыбыр; *har har akıyor* (*su*) шабыр-шыбыр ага (*су*)
har II *и.* эссе, кызулык ◊ **harı geçmek** тынычлану, сүрелү
hara *и.* ат заводы
harabe *и.* хәрабә, җимерек, җимереклек
harabelik *и.* хәрабәлек
haraç *и. тар.* ясак
haram *с.* хәрәм, тыелган; *haram mal* хәрәм мал
harami *с. иск.* юлбасар, талаучы; *kırk harami* кырык юлбасар
harap *с.* 1) харап, җимерелгән; 2) таркалган
haraplaşmak *ф.* җимерелү, тузу
haraplık *и.* җимереклек
hararet *и.* кызу(лык); җы-лы(лык), температура; *güneşin hararet/кояш* җылысы; *hastanın hararet/авыруның* тән кызулыгы
hararetlenmek *ф.* эсселәү, тән кызу
haraza *и.* талаш, ызгыш, кычкырыш; □ **haraza etmek** кычкырышу, талашу
harbi I *и.* шомпол
harbi II *с.* хәрби
Harbiye *и.* хәрби академия □ **Harbiye mektebi** хәрби училище
harbiyeli *и.* курсант
harcamak *ф.* акча туздыру, акча сарыф итү
harcıâlem *с.* арзан, һәркем алырлык
harcırah *и.* юл чыгымы
harç I *и.* чыгым
harç *и.* (*төзелеш өчен*) измә
harçlı I *с.* чыгымлы
harçlı *с.* штукатурланган; измә ярдәмендә ясалган; *harçlı duvar* штукатурланган дивар
harçlık *и.* кесә акчасы □ һәг**çlık etmek** акчаны вак-төяккә тотып бетерү
hardal *и.* горчица □ **hardal yakısı** горчичник
hare *и.* дулкынсыман бизәк
harekât *и.* хәрәкәт (*сугыш хәрәкәте*)
hareke *и.* хәрәкә (*гарәп язуында*)
hareketlenmek *ф.* хәрәкәтләнү
harekeli *с.* хәрәкәле
harekesiz *с.* хәрәкәсез
hareket *и.* хәрәкәт; *el hareketi* кул хәрәкәте □ **hareket etmek** 1) хәрәкәт итү; 2) гәүдәне хәрәкәтләндерү; 3) юлга чыгу
harem *и. тар.* гарем; хәрәм ◊ **harem ağası** хәрәм *агасы*
haremlik *и.* 1) *тар.* хатын-кызлар ягы (*өйнең*); 2) җәмәгать, иптәш
harf *и.* хәреф; *büyük harf* баш хәреф; *küçük harf* юл хәрефе ◊ **harf atmak** сүз кушу (*таныш булмаган хатын кызга*); **harfi harfine** сүзгә сүз, төгәл итеп, җиренә җиткереп
harfiyen *рәв.* сүзгә сүз
harıl harıl *с.* әзлексез, туктаусыз, дәвамлы
harılanmak *ф.* пырдымсызлану, чыгымчылау (*хайван тур.*)
harıltı *и.* гөрелте, шау, тавыш
harın *с.* 1) чыгымчы, тискәре; 2) *күч.* холыксыз
harınlamak *ф.* киреләнү, тискәреләнү
haricen *с.* тышкы
hariç *и.* 1) тыш, тышкы як; чит, кырый; 2) чит ил; *hariçte kalmak* чит илдә яшәү;

3) *бәйл.* башка (тыш); *Turgut hariç hepimiz* Тургуттан башка һәммәбез; *evin harla* өйнең тышкы ягы

harika 1. *и.* искитәрлек күренеш, могҗиза. 2. *с.* искиткеч яхшы

harikulâde *с.* ише булмаган, искиткеч

harita *и.* карта; *harita çantası* планшет; *Avrupa haritası* Европа картасы ◊ **haritada olmak** игътибар үзәгендә булу

haritacı *и.* картограф

haritalamak ф. картага төшерү

harlamak *ф.* шарт-шорт килү, чытырдау (*ут*)

harlatmak *ф.* кабызу, яндырып җибәрү

harman *и.* 1) уру, сугу, игеннәрне җыеп алу эше; 2) ындыр табагы; *harman makinesi* ашлык сугу машинасы □ **harman savurmak** җилгәрү; **harman dövmek** ашлык сугу ◊ **harman çorman** тәртипсез, төрле җирдә аунау; **harman etmek** бер төр әйбернең төрле сортларныннан аз-аз алып бергә кушу

harmancı *и.* ашлык сугучы

harmoni *и.* гармония

harp *и.* сугыш □ **harp** *suçları* хәрби җинаятьчеләр; **harp etmek** сугышу

harpa *и.* арфа

has *с.* 1) хас; *bu memlekete has bir âdet* бу якларга хас бер гадәт; 2) чын, кушылмаган; *has gümüş* саф көмеш; *has mal* яхшы мал

hasar *и.* зыян, зарар

hasat *и.* урак өсте, уру; *hasat yakti урак* өсте ◊ **hasat etmek** уру

haseki kupesi *и. бот.* суҗыяр

haset *и.* хөсет, көнчелек; □ **haset etmek** көнләшү

hasetlik *и.* хөсетлек

hâsıl *и.* хасил, бар булу □

hâsıl olmak хасил булу

hâsıla *и.* нәтиҗә, ахыр

hâsılat *и.* файда, табыш

hâsılatlı *с.* табышлы.

hasım *и.* дошман, яу

hasımlık *и.* дошманлык

hasır 1. *с.* үреп ясалган әйбер, үрмә; *hasır şapka* салам эшләпә. 2. чыпта □ **hasır otu** камыш, җикән

hasırcı *и.* үрүче, бәйләүче

hasırlamak *ф.* чыпта сугу, бәйләү, үрү

hasret *и.* хәсрәт, бәхетсезлек

hasretli *с.* хәсрәтле, сагышлы

hasretlik *и.* хәсрәтлелек

hassa 1. *с.* үзенчәлекле. 2. *и.* гвардия; *hassa askeri* сакчы гаскәр

hassas *с.*1) сизгер; 2) хисле

hassasiyet *и.* сизгерлек

hasta *и.* хаста, авыру; □ **hasta olmak** авыру, авырып китү

hastane *и.* хастаханә

hastalanmak *ф.* авыру

hastalık *и.* хасталык

haşarı *с.* 1) тәртипсез, йөгәнсез, бозык; 2) иркә

haşarılaşmak *ф.* кулдан ычкыну, тыңламый башлау

haşere *и.* бөҗәк

haşhaş *и.* мәк

haşiş *и.* гашиш

haşiye *и.* 1) билге, тамга; 2) кыска гына язма

haşlamak *ф.* 1) парда пешерү; 2) пешекләү; 3) кайнату; 4) чеметү (*суык*); 5) яндыру (*борыч*)
haşmet *и.* күркәмлек
haşmetli *с.* күркәм
hata *и.* хата; *gramer hatası* грамматик хата □ **hata etmek** хаталану, ялгышу
hatalı *с.* хаталы
hatasız *с.* хатасыз, ялгышсыз
hatır *и.* хәтер; □ **hatırından çıkarmak** исеннән (хәтереннән) чыгару, оныту; **hatıra getirmek** исенә төшерү
hatıra *и.* хатирә, истәлек; *hatıra defteri* истәлек дәфтәре; *hatıra levhası* мемориаль такта
hatırlamak *ф.* хәтерләү, искә төшерү
hatırlatmak *ф.* хәтерләтү, искә төшерү
hatırlı *с.* хөрмәтле, абруйлы
hatırsız *с.* дәрәҗәсез, абруйсыз
hatim *и.* 1) хәтем, коръәнне башыннан ахырына кадәр уку; 2) тәмамлау
hatime *и.* 1) *иск.* ахыр, соң; 2) эпилог
hatip *и.* оста телле оратор, телдар
hatta *кис.* хәтта
hattat *и.* хәттат, каллиграф
hav *и.* мамык, йон
hava *и.* 1) һава; *havaya atmak* һавага чөю; 2) һава торышы, көн; *hava açmak көн* аязу; *hava bozmak* һава бозылу; *havanın hali* һава торышы; 3) климат; *hava değiştirmek* климат алыштыру; *havası sert* кырыс климат □ **hava kuvvetleri** һава көчләре; **hava üssü** авиабаза; **hava alanı** аэропорт; **hava gazı** газ; **hava küre** атмосфера
havacı *и.* авиатор
havadar *с.* җилләнә торган
havadis *и.* яңалык, хәбәр
havaî *с.* 1) һава белән бәйле; 2) күк төстә; 3) *күч.* җилбәзәк
havaîlik *с.* җилбәзәклек
havalanmak *ф.* 1) җилләнү, җилләтелү; 2) һавага күтәрелү; 3) *күч.* һавалану
havale *и.* 1) йөкләмә, вазыйфә; 2) җибәрелгән акча
havalı *с.* һавалы, саф һавалы
havan *и.* 1) киле; 2) *иск.* миномет ◊ **havanda su dövmek** юкны бушка аудару
havasız *с.* 1) һавасыз, һава булмаган, тынчу; 2) *күч.* ямьсез, җансыз
havayolu *и.* һава юлы
havlamak *ф.* һаулау, өрү (*эт тур.*) ◊ **havlayan köpek ısırmaz** өргән эт тешләми
havlı *с.* йонлы, мамыклы
havlu *и.* сөлге
havra *и.* синагога (*яһүдләр гыйбадәтханәсе*)
havsala *и. анат.* 1) оча сөяге; 2) *күч.* зирәклек, тиз төшенүчәнлек
havuç *и.* кишер
havuz *и.* 1) сулык, бассейн, буа; 2) *диңг.* док
havuzcuk *и. анат.* бөер лаканчыгы
havuzlamak *ф.* ремонтлау өчен докка кую
havya *и.* паяльник (*эретеп ябыштыручы корал*)
havyar *и.* уылдык, икра; *siyah havyar кара* икра
havza *и.* бассейн; мәйдан; *boşaltma havzası* елга бассейны
haya *и.* оят
hayal *и.* хыял; *hayal kurmak* хыяллар кору, хыяллану
hayalci *и.* хыялланучы

hayalet *и.* 1) өрәк; 2) шәйләнгән нәрсә, ачык күренмәгән нәрсә
hayâlı *с.* оялчан, әдәпле
hayalî *с.* хыялый
hayâsız *с.* оятсыз
hayat *и.* хәят, тормыш, тереклек; **hayat ağacı** шәҗәрә ◊ **hayat baharı** тормыш язы
hayatî *с.* 1) тормышка бәйле; 2) мөһим, әһәмиятле
hayatiyet *и.* яшәү көче
haydalamak *ф.* куалау, ашыктыру, әйдәләү
haydi *ы. и.* әйдә, ягез, я әле, ярый; *haydi gidelik* әйдә киттек!; *haydi git* ярый, кит
haydut *и.* юлбасар, талаучы
haydutluk *и.* талау, юл кисү, бандитлык
hayır I *мод. сүз.* юк; *hayır, görmedim* юк, күрмәдем
hayır *с.* хәерле, яхшы, изге; *hayır haber яхшы* хәбәр
hayırdua *и.* хәер-дога
hayırhah *с.* хәерхаһ, яхшы теләк
hayırlaşmak *ф.* килешү, бер фикергә килү (*сәүдә эшендә*)
hayırlı *с.* хәерле, файдалы, уңышлы
hayırsever *и.* шәфкать итүче, игелек күрсәтүче
hayırsız *с.* хәерсез; уңышсыз, файдасыз
haykırmak *ф.* кычкыру, кычкырып җибәрү
haylaz *и.* 1) юньсез; 2) ялкау
haylazlaşmak *ф.* ялкаулану, эшсез йөрү
hayli *рәв.* шактый; *hayli yoruldum* шактый арыдым
hayran *с.*1) хәйран калган; 2) сокланучы; □ **hayran olmak** соклану
hayrat *и.* саваплы эш, изгелек
hayret 1. *и.* аптырау, каушау. 2. *ы*. гаҗәп! □ **hayret etmek** шаккату
hayvan *и.* хайван, терлек; *büyük baş hayvan* мөгезле эре терлек
hayvanca *с.* хайванын, тупас
hayvancılık *и.* терлекчелек
hayvanlaşmak *ф.* хайванга әйләнү, кешелек сыйфатын югалту
haz *и.* рәхәт, ләззәт, хозурлык
hazım *и.* сеңдерү, үзләштерү
hazımlı *с. күч.* 1) киң күңелле; тыныч холыклы; 2) үзләштерә алган
hazımsız *с.* 1) тотрыксыз, холыксыз; 2) үзләштерә алмаган
hazır *с.* әзер; *hazır elbise* әзер кием; *gitmeye hazırız* без китәргә әзер; *yemek hazır mı?* аш әзерме?
hazırcevap *с.* тапкыр
hazırlamak *ф.* 1) әзерләү; 2) хәзерләү
hazırlanmak *ф.* әзерләнү, хәзерләнү
hazırlatmak *ф.* хәзерләтү
hazırlık *и.* хәзерлек
hazırlıklı *с.* хәзерлекле
hazırlıksız *с.* хәзерлексез
hazırlop *и.* пешкән йомырка
hazine *и.* хәзинә, байлык; *devlet hazinesi* дәүләт байлыгы; *tükenmez hazineler* бетмәс-төкәнмәс хәзинәләр □ **kelime hazinesi** сүз байлыгы
haziran *и.* июнь, июнь ае
hazret *и.* хәзрәт; изге
heba *с.* файдасыз, әрәмгә киткән; □ **heba etmek** юкка әрәм итү
hece *и.* иҗек
hecelemek *ф.* иҗекләп уку
heceli *с.* иҗекле

hedef *и.* 1) мишень; 2) максат, морад
heder *и.* югалту, зыян, зарар ◊ **heder etmek** әрәм итү
hediye *и.* бүләк; *hediye vermek* бүләк бирү
hediyelik *с.* бүләк өчен, бүләккә
hekim *и.* врач, доктор, табиб
hektar *и.* гектар
hektolitre *и.* гектолитр
hektometre *и.* гектометр
helâ *и.* бәдрәф
helâk *и.* һәлак булу, үлү; □ **helâk etmek** һәлак итү
helâl *с.* 1) хәләл; 2) никахлы; 3) намуслы
helâllaşmak *ф.* килешү
hele *кис.* 1) бигрәк, бигрәк тә, тагын; 2) ахыр чиктә, ниһаять; 3) әле; яле
helezon *и.* спираль
helezonî *с.* спиральсыман
helikopter *и.* вертолет
helke *и.* саплы чүлмәк, чиләк
helva *и.* хәлвә
helvacı *и.* хәлвәче
helvacıkabağı *и.* баллы кабак
helyograf *и.* гелиограф
helyoterapi *и.* гелиотерапия
helyum *и. хим.* гелий
hem *бәйл.* һәм
hemcins *и.* бер җенестән булган
hemen *рәв.* хәзер, хәзер үк, бик тиз, шунда ук, тиздән
hemoglobin *и.* гемоглобин
hendek *и.* чокыр, канау
hengâm, **hengâme** *и.* гөрелте, шау-шу, тавыш-гауга
hentbol *и.* гандбол
henüz *кис.* яңа гына, әле генә; әле дә, әле һаман
hep *а.* 1) бары(сы), бөтен(есе); *hepimiz gördük* барыбыз да күрдек; 2) һәрвакыт; *hep seni düşünüyorum* һәрвакыт сине уйлыйм
hepsi *а.* барысы
hepten *рәв.* тулысынча
her *а.* һәр; *her yıl* һәр ел; **her dem taze** (**ağaçlar**) мәңге яшел (агачлар); **her halde** һәр хәлдә
hercümerç *и. ыгы-зыгы,* мәхшәр
herek *и.* колга, киртә (*үрмәле үсемлекләр өчен*)
hereklemek *ф.* колгага ныгыту (бәйләү)
hergele *и.* 1) ат яисә ишәк көтүе; 2) *күч.* тәрбиясезлек
hergeleci *и.* ат көтүчесе, елкычы
herhangi *а.* теләсә нинди, теләсә кайсы; ниндидер бер
herkes *а.* һәркем
herze *с.* мәгънәсез, буш, юк-бар
hesap *и.* хисап
hesapçı *и.* хисапчы
hesaplamak *ф.* хисаплау
hesaplaşmak *ф.* хисаплашу
hesaplı *с.* хисаплы; экономияле
hesapsız *с.* хисапсыз
heva *и.* теләк, дәрт

heves *с.* һәвәс
hey *ы.* һай, һәй
heybe *и.* 1) ат аркасына салына ала торган ике бүлекле капчык; 2) иң башына асыла торган сумка
heybet *с.* мәһабәт, күркәм
heyecan *и.* дулкынлану халәте; тәэсирләнү; кызыксыну
heyecanlanmak *ф.* дулкынлану, тәэсирләнү
heyecanlı *с.* 1) дулкынланучан, ярсучан; 2) дулкынландыргыч; 3) ярсулы; тәэсирле
heyelân *и.* убылу, ишелү (*туфрак тур.*)
heyet *и.* делегация, комиссия, коллегия
heyhat *кер. сүз.* кызганыч, кызганыч ки
heykel *и.* һәйкәл
heykelci *и.* скульптор
heykeltıraş *и.* скульптор
hezimet *и.* җиңелү, паника
hıçkırmak *ф.* 1) очкылык тоту; 2) үксеп елау
hıçkırık *и.* 1) очкылык; 2) үксү, үксеп елау □ **hıçkırık tutmak** очкылык тоту
hıfzısıhha *и.* гигиена, санитария
hımbıl *с.* ялкау
hımhım *с.* тыңкыш
hımhımlamak ф. тыңкышлап сөйләшү
hıncahınç *с. рәв.* шыгрым тулы
hınç *и.* нәфрәт, үч, ачу
hınçlı *с.* ачулы, үчле
hınzır *и.* 1) *иск.* дуңгыз; 2) *күч.* явыз ниятле кеше
hınzırlık *и. күч.* дуңгызлык, явыз ниятлелек
hır *и.* гауга, талаш
hıra *с.* зәгыйфь, ябык
hırbo *с. и. сөйл.* аңгыра, миңгерәү
hırçın *с.* кызу канлы
hırçınlaşmak *ф.* кабынып китү, ярсу
hırçınlık *и.* кызулык, кызу канлылык
hırdavat *и.* тимер-томыр әйберләр
hırgür *и.* ызгыш, талаш
hırıldamak *ф.* хырылдау
hırıltı *и.* 1) хырылты; 2) *күч.* гауга
hırıltıcı *и.* гаугачы, җәнҗалчы
hırızma *и.* бөжра, алка (*борынга кидерелә торган*)
hırka *и.* бишмәт (*сырган*)
hırlamak *ф.* 1) хырылдау; 2) ырылдау (*эт тур.*)
hırpalamak *ф.* 1) яраксыз хәлгә китерү, таушалдыру; туздыру; 2) *күч.* кагу, кимсетү
hırpanî *с.* тузган, искергән
hırs *с.* саран, карун
hırsız *и.* карак
hırsızlama *с.* урланган
hırsızlık *и.* караклык
hırslanmak *ф.* 1) бик нык теләү; 2) кабыну, кызып китү
hırslı *с.* 1) комсыз, саран; 2) ачулы, үпкәле
hırtı pırtı *и.* иске-москы, чүп-чар
hısım *и.* туган □ **hısım akraba** туган-тумача
hısımlık *и.* туганлык

hışıldamak *ф.* кыштырдау
hışım *ф.* ачу, ярсу
hışımlarımak *ф.* ачулану
hışırdamak *ф.* шыштырдау
hışırdatmak *ф.* шыштырдату
hıyar *и.* кыяр
hız *и.* тизлек; *hız kesmek* тизлекне киметү
hızar *и.* зур пычкы
hızarcı *и.* пычкычы
hızlanmak *ф.* кызулау, көчәю, шәбәю
hızlandırmak *ф.* тизләтү, кызулату, көчәйтү
hızlı *с.* тиз
hızlılık *и.* тизлек
hibe *и.* багышлап бирү, бүләк итеп бирү
hicap *и.* оят, кыенсыну, тартыну
hicran *и.* 1) аерылу; 2) аерылу сагышы
hicret *и.* һиҗрәт; күчү
hicrî *и.* һиҗри
hiç *а.* һич
hiçbir *а.* һичбер
hiçlik *и.* сукыр бер тиенлек
hiddet *и.* үпкә, ачу, ярсу
hiddetlenmak *ф.* ачулану, ярсу, кызу
hiddetlendirmak *ф.* ачуландыру
hiddetli *с.* кызу канлы, ярсу
hiddetsiz *с.* салмак
hidrat *и.* гидрат
hidrojen *и.* водород ◊ **hidrojen bombası** водород бомбасы
hidroliz *и.* гидролиз
hikâye *и.* хикәя; □ **hikâye etmek** хикәяләү
hikâyeci *и.* хикәяче
hikmet *и.* хикмәт
hilâf *и.* 1) каршы, аркылы; 2) *сөйл.* ялган
hilâfet *и. тар.* хәлифәлек
hilâl *и.* һилал, яңа туган ай
hile *и.* хәйлә
hileci *и.* хәйләче, хәйлә коручы
hilekâr *и.* хәйләкәр
hilekârlık *и.* хәйләкәрлек
hileli *с.* хәйләле
hilesiz *с.* хәйләсез
himaye *и.* химая (*кемне дә булса*) канат астына алу
himayeli *с.* химаяле, якпаулы
himmet *и.* һиммәт, теләккә омтылучанлык, тырышлык
himn *и.* гимн
hindi *и.* күркә
Hindistan *и.* Һиндыстан
Hindu *и.* һинд теле (*рәсми тел*)
hintbezelyesi *и.* борчак (*бер төре*)
hindiba *и. бот.* һиндыба
hintdornuzu *и.* 1) диңгез күсесе, свинка; 2) һинд дуңгызы
hintkamışı *и.* бамбук

hintkeneviri *и.* киндер (*бер төре*)
hintkestanesi *и.* кәстәнә, каштан (*агачы*)
hintkirazı *и.* манго
Hintli *и.* 1) һинд, һинд кешесе; 2) индеец
hintyağı *и.* касторка мае
hiperbol *и. мат.* гипербола
hipermetrop *с.* ерактан яхшы күрүче
hipertansiyon *и.* югары кан басымы
hipodrom *и.* ипподром
hipotansiyon *и.* түбән кан басымы
hipotenüs *и. мат.* гипотенуза (*геометрик термин*)
hipotez *и.* гипотеза, фараз
his *и.* хис, тойгы
hislenmek *ф.* хисләнү
hisli *с.* хисле
hisse *и.* 1) өлеш; 2) акция; 3) сабак □ **hisse senedi** акция
hissedar *и.* акционер
hisseleşmek *ф.* үзара бүлешү
hisseli *с.* өлеше булган
hissî *с.* хисчән
hitap *и.* мөрәҗәгать; □ **hitap etmek** мөрәҗәгать итү
hitit *и. тар.* хетт (*халык исеме*)
hiza *и.* тигезлек **hizmet** *и.* хезмәт; *hizmetine bakmak* хезмәт күрсәтү; *yurda hizmet* ватанга хезмәт
hizmetçi *и.* 1) хезмәт башкаручы; 2) хезмәтче хатын
hizmetçilik *и.* хезмәтчелек
hizmetkâr *и.* хезмәткәр
hoca *и.* 1) укытучы; 2) мулла
hocalık *и.* 1) укытучылык; 2) муллалык
hohlamak *ф.* 1) тын өрү; 2) тын белән җылыту
hokey *и.* хоккей
hokkabaz *и.* 1) фокусчы, жонглер; 2) *күч.* жулик, алдакчы
hol *и.* холл, фойе, алгы бүлмә
hollanda *и.* Голландия
hollandalı *и.* голланд, голландияле
homoseksüel *с.* гомосексуаль
homurdanmak *ф.* мыгырдану
homur homur *иярт.* мыгыр-мыгыр
hoparlör *и.* репродуктор, динамик
hoplamak *ф.* сикерү (*сөенечтән, куркудан һ. б.*)
hoplatmak *ф.* сикертү
hoppa *с.* җилбәзәк, җилкуар
hoppalık *и.* җиңел акыллылык
hopurdatmak *ф.* хопырдату
hor *с.* түбән дәрәҗәле; бәясе төшкән, кадерсез
horlamak *ф.* кимсетү, рәнҗетү
hormon *и.* гормон
horon *и.* хоран (*төрек халык биюе*)
horoz *и.* 1) әтәч; *horoz dövüşü* әтәч сугышы; 2) курок, чакма
horozlanmak *ф.* әтәчләнү
horozmantan *и.* әтәч гөмбәсе
hortlamak *ф.* 1) өрәккә әйләнү; 2) *күч.* (*ниндидер бер мәсьәлә*) яңадан калкып чыгу

hortlak *и.* өрәк, вампир
hortum *и.* 1) хортум (*филдә*); 2) борын (*кайбер бөҗәкләрдә*); 3) шланг, резин эчәк **hortumlu** *с.* хортумлы
hoş *с.* хуш □ **hoş bulduk** хуш булдык (*хуш килдегез! сүзенә җавап*); **hoş geldiniz** хуш килдегез; **hoşuma gitti** бик ошады
hoşaf *и.* компот ◊ **hoşaf gibi** бик арыган; **hoşafın yağı kesilmek** югалып калу
hoşça *с.* яхшы ◊ **hoşça kalın** (**kal**) сау булыгыз
hoşgörü *и.* түземлек; яхшы мөгамәлә
hoşgörülü *с.* түземле; яхшы мөгамәләле
hoşgörüsüz *с.* түземсез; *яхшы* мөгамәлә күрсәтмәгән
hoşgörüsüzlük *и.* түземсезлек
hoşlanmak *ф.* хушлану, рәхәтлек хис итү
hoşlaşmak *ф.* хуш күрү, ошату
hoşluk *и.* хушлык, рәхәтлек
hoşnut *и.* канәгать
hoşnutsuzluk *и.* канәгатьсезлек
hoşt *ы.* чәбә (*этләрне куу ымлыгы*)
hoşur *с.* тупас, әдәпсез
hotoz *и.* кикрик
hovarda *и. с.* типтерүче, азгын
hovardalaşmak *ф.* азып-тузып йөрү
hödük *с.* тупас
hödüklük *и.* тәрбиясезлек, тупаслык
höl *и.* дым, дымлылык
hörgüç *и.* өркәч
hörguçlü *с.* өркәчле
höyük *и.* калкулык, үр
hububat *и.* бөртеклеләр
hudut *и.* чик; *hududu geçmek* чикне бозу
hudutlarıdırmak *ф.* чикләү
hudutlu *с.* чикле
hudutsuz *с.* чиксез
hukuk *и.* хокук
hukukçu *и.* юрист, хокук белгече
hukukî *с.* юридик, хокукый
hulâsa *и.* 1) йомгак, нәтиҗә, резюме; 2) *хим.* экстракт; 3) *көр. сүз.* кыскача әйткәндә
hulâsaten *рәв.* кыскача
huluskârlık *и.* ихласлык
hulya *и.* татлы хыял
humma *и.* бизгәк, калтырау
humus I *и.* үсемлекләр черемәсе
humus II *и.* фасольне төеп, (*яшелчәләр кушып*) хәзерләнгән ашамлык
huni *и.* бүрәнкә
hurafe *и.* хорафат
hurda *и.* вак-төяк, иске-москы
hurdacı *и.* вак-төяк белән сату итүче
hurdahaş *рәв.* челпәрәмә □ **hurdahaş etmek** челпәрәмә китерү
hurma *и.* хөрмә
husul *и.* тормышка ашу, барлыкка килү
husumet *и.* дошманлык
huş *и.* каен агачы

hutbe *и.* хөтбә
huy *и.* 1) холык, табигать, характер; 2) гадәт
huylanmak *ф.* 1) вәсвәсәләнү (*кеше тур.*); 2) өркү (*хайван тур.*)
huylu *с.* 1) холыклы; *kötü huylu* начар холыклы; 2) вәсвәсәле; 3) өркәк (*хайван*)
huysuz *с.* холыксыз, начар холыклы
huysuzlanmak *ф.* хәвефләнү, шикләнү
huzur *и.* 1) хозур, тынычлык; *huzurunu bozmak* тынычлыгын бозу; 2) хозур(ына); *huzuruna almak* янына алу; *huzuruna çağırmak* хозурына (янына) чакыру
huzurlu *с.* күңелле, хозурлы
huzursuz *с.* борчулы, хәвефле
huzursuzluk *и.* борчу
hücre *и.* 1) күзәнәк; 2) хөҗрә, кечкенә бүлмә; **hücre bilimi** цитология
hücum *и.* һөҗүм, штурм; □ **hücum etmek** һөҗүм итү
hükmen *рәв.* судья карары буенча
hüküm *и.* хөкем
hükümdar *и.* хөкемдар
hükümdarlık *и.* хөкемдарлык
hükümet *и.* хөкүмәт
hümanist *с.* гуманист
hümanizm *и.* гуманизм
hüner *и.* һөнәр
hüngürdemek *ф.* сулкылдап елау
hüngürtü *и.* сулкылдау
hür *с.* хөр, азат
hürmet *и.* хөрмәт □ **hürmet etmek** хөрмәт итү
hürmetsizlik *и.* хөрмәтсезлек
hürriyet *и.* хөррият
hüthüt *и.* Һөдһөд
hüviyet *и.* шәхес □ **hüviyet cüzdanı** шәхес таныклыгы
hüzün *и.* моң, борчу, сагыш
hüzünlerimek *ф.* моңлану, борчылу
hüzünlü *с.* ямансу, моңсу

I

ıcığı cıcığı *и.* эче-тышы ◊ **ıcığı cıcığını çıkarmak** 1) эчен-тышын тикшерү; 2) нечкәлекләренә кадәр тикшерү
ığrıp *и.* 1) ятьмә, челтәр; 2) *күч.* ялган, хәйлә
ıh *ы. дөяне* чүктерү өчен әйтелә
ıhmak *ф.* чүгү (*дөя тур.*)
ıhı *ы.* менә шул
ıhlamak *ф.* аһылдау, уфылдау
ıhlamur *и.* юкә; *ıhlamur çayı* юкә чәе
ıkınmak *ф.* 1) сулышны тоткарлау; көчәнү; 2) тын бетү, тын кысылу
ıklamak *ф.* 1) авыр сулыш алу, тын кысылу; 2) сулкылдау, үксү *аз* **ıklaya sıklaya** көч-хәл белән
ıklım tıklım *с.* туп-тулы
ılgamak *ф.* атны куу (*җайдак тур.*)
ılgar *и.* 1) ат чабуы; 2) *мар.* атлы һөҗүм
ılgarlamak *ф.* атлы һөҗүм ясау
ılgım *и.* чагым, мираж □ **ılgım salgım** күренер-күренмәс., беленер-беленмәс
ılgıncar *и.* кыргый чия
ılıca *и.* кайнар (минераль) чишмә

ılık *с.* җылы; талгын
ılıklaşmak *ф.* җылыну, талгынлану
ılıklaştırmak *ф.* җылыту
ılıklık *и.* җылылык
ılıman *с. геогр.* уртача; *ılıman iklim* уртача климат
ılımlı *с.* тыныч, басынкы
ılınmak *ф.* җылыну
ılıtmak *ф.* җылыту
ıpıslak *с.* юпь-юеш
ırak *с.* ерак
ıraklaştırmak *ф.* ераклаштыру
ıraklık *и.* ераклык
ıraksamak *ф.* (булачагына) ышанып җитмәү
ıraksak *с. физ. мат.* бер-беренән ераклашучы
ıralamak *ф.* сыйфатлау, билгеләү, чагылдыру
ırgalamak *ф.* селкетү
ırgat *и.* көнлекме, ялланып эшләүче
ırk *и.* ыруг, нәсел, раса; *beyaz ırk* ак раса; *sarı ırk* сары раса
ırkçı *и.* расист
ırkçılık *и.* расачылык
ırkî *и.* раса белән бәйле
ırkiyat *и.* этнология
ırktaş *и.* кабиләдәш
ırmak *и.* елга, дәрья □ **ırmak ayağı** кушылдык
ırz *и.* намус ◊ **ırzına dokunmak** намуска кагылу; **ırzına geçmek** намусын таптау; көчләү
ırzlı *с.* намуслы, әдәпле
ısı *и. физ.* 1) җылылык; 2) температура □ **ısı iletilmesi** җылы-бирешь; **ısı kapasitesi** җылысыешлык; **ısı alan** эндотермик
ısıl *и.* җылытудыргыч
ısın *и.* калория
ısınmak *ф.* 1) җылыну; 2) *күч.* күнегү, ияләнү
ısındırmak *ф.* 1) җылыту; 2) *күч.* сыендыру
ısıölçer *и.* калориметр
ısırmak *ф.* 1) тешләү, чәйнәү; *dudak ısırmak* иренне тешләү; *kalemi ısırmak* каләмне чәйнәү; 2) *күч.* яманлау, гайбәтен сөйләү
ısırgan *и. бот.* кычыткан
ısırık *и.* 1) тешләнгән урын (әз); 2) тешләм, кабым
ısırılmak *ф.* тешләнү
ısırtmak *ф.* тешләтү
ısıtmak *ф.* җылыту
ısıtıcı *с.* кыздыручы
ısıveren *и. физ. хим.* экзотермик, җылы бирүче
ıska *и.* тидерә алмау
ıskala *и.* 1) *муз.* гамма; *ıskala yapmak гамма* уйнау; 2) шкала
ıskarça *и.* артык төялгәнлек
ıskonto *и.* 1) ташлама; 2) *фин.* дисконт
ıskuna *и. диңг.* шхуна, җилкәнле судно
ıslamak *ф.* юешләү, чылату
ıslah *и.* ислах, реформа; төзәтү, үзгәртү, төзәтмә, үзгәреш □ **ıslah etmek** төзәтмәләр кертү; **ıslah evi** хезмәт белән төзәтү колониясе
ıslahatçı *и.* ислахчы, реформачы, үзгәрешләр кертү тарафдары

ıslak *с.* юеш, дымлы; *ıslak bez* юеш чүпрәк; *ıslak yer* дымлы җир ◊ **ıslak kargaya dönmek** манма су булу
ıslaklık *и.* юешлек, дымлылык
ıslık *и.* 1) сызгыру, сызгырган тавыш; 2) ысылдау; *yılan gibi ıslık çalıyor* елан кебек ысылдый □ **ıslık çalmak** сызгыру
ıslıklamak *ф.* сызгыру; сызгырып куу
ısmarlamak ф. 1) заказ бирү; 2) йомыш тапшыру; 3) киңәш бирү □ **Allaha ısmarladık** Аллага тапшырдык
ıspanak *и.* шпинат
ıspatula *и.* калак, гипостель
ıspavli *и.* тросс
ıspazmoz *и.* 1) спазм; тән тартышу; 2) буылу, бугаз кысылу
ısrar *и.* үз сүзендә тору □ **ısrar etmek** үзенекен итү
ısrarlı *с.* катгый, ныклы
ıssız *с.* хуҗасыз, ташландык; аулак (*җир*)
ıssızlaşmak *ф.* кешесез калу
ıssızlık *и.* 1) кеше яшәми торган җир; 2) ялгызлык
ıstakoz *и.* омар, диңгез кысласы
ıstampa *и.* калып; мөһер, тамга
ıstanbol *и.* сюртук
istavroz *и.* тәре □ **istavroz çıkarmak** чукыну
ıstırap *и.* газап, җәфа
ıstıraplı *с.* газаплы, интегүле
ıstırar *с.* мәҗбүри; **ıstırarında kalmak** мәҗбүр булу
ışımak *ф.* балку, нурлану, яктыру
ışık *и.* яктылык, нур
ışıklanmak *ф.* яктыру, таң ату
ışıklandırmak *ф.* яктырту
ışıklı *с.* якты, нурлы
ışıklılık *и.* яктылык
ışıksız *с.* яктыртылмаган, караңгы
ışıldamak *ф.* җемелдәү, ялтырау
ışıldak *и.* яктырткыч, прожектор
ışıldatmak *ф.* яктырту, нурландыру
ışıltı *и.* яктылык, балкыш, нурланыш
ışın *и.* нур □ **ışın hastalığı** нур авыруы
ışınım *и.* радиация, нурланыш
ışıtmak *ф.* яктырту, балкыту
ışkı *и.* ышкы
ıtır *и.* хуш ис
ıtırlı *с.* хуш исле
ıtnap *и.* күп сөйләү, лыгырдау
ıtriyat *и.* хушбуйлар, ислемайлар
ıtriyatçı *и.* парфюмерия әйберләре сатучы
ıvır zıvır *и. с.* вак-төяк, ыбыр-чыбыр
ızbandut *и.* әшәке адәм, бандит
ızgara 1. *и.* тимер учак, мангал, рашпер. 2. *с.* тимер учакта кыздырыл хәзерләнгән

İ

iade *и.* 1) кайтару, кайтарып бирү; 2) кире кагу; 3) элекке хәленә китерү
ibadet *и.* гыйбадәт
ibadethane *и.* гыйбадәтханә

ibare *и.* гыйбарә, өзек
ibaret *с.* гыйбарәт, эченә алган
ibibik *и.* һөдһөд (*кош*)
ibik *и.* кикрик
ibikli *с.* кикрикле
ibiş *и.* ибис (*кош*)
iblis *и.* иблис
ibra *и.* аклау
ibre *и.* 1) энә, ук; *pusula ibresi* компас угы; 2) ылыс
ibret *и.* гыйбрәт, сабак □ **ibret almak** гыйбрәт алу
ibreten *рәв.* гыйбрәт өчен
ibretli *с.* гыйбрәтле
ibrik *и.* чүлмәк, кувшин; *toprak ibrik* балчык чүлмәк
ibrişim *и.* калын ефәк җеп □ **ibrişim kurdu** ефәк корты
icabet *и.* килешү, ризалык □ **icabet etmek** чакыруны кабул итү
icap *и.* кирәклек, хаҗәт, зарурлык
icat *и.* 1) ижат, ачыш; 2) тудыру, барлыкка китерү; □ **icat etmek** ижат итү ◊ **icat çıkarmak** мөгез чыгару
icra *и.* 1) үтәү, башкару; 2) (*музыка әсәрен*) башкару; 3) хөкем карарын тормышка ашыру
iç 1. *и.* 1) эч; *şehrin içinde* шәһәр эчендә; 2) эч, корсак; *iç hastalıklarım* авырулары; 3) күңел, йөрәк; *içimde* эчемдә (күңелемдә); *iç ferahlığı* күңел күтәрәнкелеге; 4) эче, төш; *fındık içi* чикләвек теше. 2. *с.* 1) эчке; *iç **â**lem* эчке (рухый) дөнья; *iç çamaşırı* эчке кием; 2) эчке эшләр белән бәйле; *iç politika* эчке сәясәт □ **iç asalak** *биол,* эндопаразит; **iç başkalaşım** *геол.* эндоморфизм; **iç ses** *лингв.* синкопа; **iç ses türemesi** эпентеза ◊ **içi dış**» **birdir** эчендәге тышында; **içim açıldı** күңелем күтәрелде; **içi sıkılıyor** эче поша; **içini boşatmak** эчен бушату
içmek *ф.* 1) эчү; 2) тарту; 3) сеңдерү
içbükey *с.* батынкы; *içbükey mercek* батынкы линза; *içbükey ayna* батынкы көзге
içcümle *и.* туры сөйләм
içderi *и. бот.* эндодерма
içecek 1. *и.* эчемлек. 2. *с.* эчәргә яраклы; *içecek su* эчәргә яраклы су
içedönüktük *с.* йомык, аралашмый торган
içek *и. лингв.* инфикс, эчкушымча
içeri *с.* эчке, эчкәре
içerik *и.* эчтәлек
içerlemek *ф.* ачу тоту, ачу саклау
içgüdü *и.* инстинкт, эчке сизем, тойгы
içgüvey *и.* кияү (*хатынының атасы йортында яшәүче*)
içici *и.* эчкече
içicilik *и.* эчкечелек
içim *и.* 1) эчем, йотым; 2) эчемлек; 3) тәмәке тарту
için *бәйл.* өчен; *annem için* әнием өчен
içinde бәйл. суз. эчендә
içirmek *ф.* 1) эчерү; 2) тарттыру; **boyayı içirmek** буяуны сеңдерү
içirilmek *ф.* эчерелү
içişleri *и.* эчке эшләр; **içişleri bakanı** эчке эшләр министры
içitmek *ф.* укол кадау; прививка ясау
içitim *и.* прививка, укол
içki *и.* исерткеч; **içki hastalığı** алкоголизм
içkicilik *и.* эчкечелек
içkili *с.* сәрхуш, исерек

içkin *с. фәлс.* эчке, имманент
içkisiz *с.* 1) эчкесез; 2) аек
içlem *и.* төшенчә
içlenmek *ф.* дулкынлану, тынычсызлану, борчылу
içli *с.* 1) эчендә әйбер булган, төшле; 2) *күч.* хисле; борчулы; 3) *күч.* үпкәчел
içlidışlı *с.* эчкерсез, чын күңелдән булган
içlik *и.* эчке кием
içplazma *и.* эндоплазма
içsalgı *и.* эчке бизләр; эчке секреция
içsel *с. төрле мәгъ.* эчке, эчтәге
içten *рәв.* чын күңелдән, йөрәктән
içtima *и.* тупланма
içtimaî *с.* иҗтимагый
içtimaiyat *и.* җәмгыять белеме, социология
içtimaiyatçı *и.* социолог
içtüzük *и.* эчке тәртип
içyağı *и.* эч мае
içyüz *и.* асылы, нигезе
idam *и.* үлем җәзасы; *idama mahkûm edilmek* үлем җәзасына хөкем ителү
idamlık *и.* үлем җәзасы алган кеше
idare *и.* идарә; □ **idare etmek** идарә итү
idareci *и.* җитәкче
idaresizlik *и.* хуҗасызлык, хуҗалыкны алып бара белмәү
iddia *и.* 1) раслау; 2) дәгъва
iddiacı *с.* кире, үзсүзле
iddiacılık *и.* үзсүзлелек, кирелек
iddialaşmek *ф.* дәгъвалау
iddiasız *с.* гади, дәгъвасыз, тыйнак
ide, **idea** *и.* фикер, идея
ideal 1. *и.* идеал, бөек максат. 2. *с.* идеаль
idealist *и.* идеалист, хыялый
idealleştirmek *ф.* идеаллаштыру
ideolog *и.* идеолог
ideoloji *и.* идеология
idil *и.* идиллия
idiopati *и.* психопатия
idman *и.* 1) күнегү, тренировка; гимнастика; 2) *күч.* күнегү, ияләнү
idmancı *и.* спорт күнегүләре ясаучы
idmanlı *с.* өйрәнгән, күнеккән
idmansız *с.* күнекмәсез
idrak *и.* тану, төшенү, белү, аңлау; *idrak kabiliyeti* таныл-белү сәләте
idraksiz *с.* аңсыз, аңгыра
idrar *и.* сидек
idrisağacı *и.* шомырт агачы
ifa *и.* тормышка ашыру, башкару
ifade *и.* 1) чагылыш; белдерелү, белдерү; *ifadesini bulmak* чагылышын табу; 2) әйтем, тәгъбир; *güzel bir ifade* образлы тәгъбир
ifadelendirmek *ф.* чагылдыру, гәүдәләндерү
iffet *и.* гыйффәт, намуслылык
iffetli, **iffetlû** *с.* гыйффәтле, саф
ifildemek *ф.* калтырау, дерелдәү
iflâh *и.* иминлек, тынычлык

iflâs *с.* 1) бурычларын түләргә хәле җитмәгән, белгән; 2) *күч.* җиңелгән
ifrat *рәв.* чамадан тыш, ифрат ◊ **ifrata vardırmak** артыгын кылану
ifrit *и.* гыйфрит
ifşa *и.* фаш итү
iftar *и.* ифтар, уразада авыз ачу
iftarlık *и.* авыз ачу өчен әзерләнгән ризык
iftihar *и.* куаныч, горурлык □ **iftihar etmek** горурлану, куану
iftira *и.* яла, гайбәт
iftiracı *и.* ялганчы
iğ *и.* орчык
iğdiş *с.* печелгән
iğne *и.* 1) әнә; *iğne deliği* энә күзе; 2) тел; *saat iğnesi* сәгать теле; 3) энә, ук; *iğnesini batırmak* угын батыру; 4) кармак; *balık iğnesi* кармак; 5) укол; *iğne vurmak* укол кадау ◊ **iğne deliğine kaçmak** җир тишегенә керердәй булу; **iğne üstünde oturmak** әнә өстендә утыру
iğnelemek *ф.* кадау
iğneleyici *с.* кадалучан
iğneli *с.* энәле
iğneyaprak *и.* ылыслы агач
iğrenmek *ф.* җирәнү
iğrenç *с.* җирәнгеч
iğrendirmek *ф.* җирәндерү
ihale *и.* йөкләмә, тапшырылган эш
ihbar *и.* хәбәр □ **ihbar etmek** хәбәр итү
ihbarname *и.* рәсми хәбәр
ihlâl *и.* бозу, зарар китерү
ihmal *и.* игътибар итмәү, ильтифатсызлык күрсәтү
ihracat *и.* экспорт, чит илгә чыгару
ihracatçı *и.* экспортер
ihracatçılık *и.* экспорт
ihraç *и.* 1) чыгарылу; 2) чит илгә товар чыгару; □ **ihraç edilmek** чыгарылу; **partiden ihraç edildi** партиядән чыгарылды
ihsan *и.* игелек, шәфкать
ihsas *и.* 1) тойгы, хис; 2) читләтеп әйтү, ишарә итү, сиздерү
ihtar *и.* искәртү, кисәтү
ihtilâf *и.* бәхәс, фикер каршылыгы
ihtilâl *и.* 1) ихтилал, революция; 2) фетнә
ihtilâlci *и.* революционер
ihtimal *рәв.* ихтимал, фараз
ihtimam *и.* игътибар, кайгырту
ihtira *и.* ачыш, уйлап табу
ihtiram *и.* ихтирам, хөрмәт
ihtiras *и.* көчле теләк
ihtisas I *и.* тойгы
ihtisas *и.* белгечлек
ihtişam *и.* күркәмлек, һәйбәтлек
ihtiva *и.* үз эченә алу
ihtiyaç *и.* ихтыяҗ, зарурлык
ihtiyar I *с.* карт; *ihtiyar adam* карт кеше
ihtiyar II *и. иск.* (*үз ихтыяры белән*) сайлап алу
ihtiyarî *с.* ихтыяри, ирекле
ihtiyarlamak *ф.* картаю

ihtiyarlık *и.* картлык
ihtiyat *и.* 1) саклык; *ihtiyat tedbirleri* саклану чаралары; 2) запас, хәстәрлек
ihtiyatlı *с.* сакчыл
ihtiyatsız *с.* саксыз
ihvan *и.* фикердәш
ikame *с.* урнашкан; □ **ikame etmek** 1) урнаштыру; 2) аягүрә тору; 3) судка бирү
ikamet *и.* билгеле бер җирдә яшәү
ikametgâh *и.* яшәү урыны, тору урыны
ikaz *и.* игътибарын җәлеп итү
ikbal *и.* уңыш, бәхет
ikdam *и.* нык тору, тырышу □ **ikdam etmek** бөтен көчен салу
ikebana *и.* икебана, чәчәк тезү сәнгате
iken *кис.* икән
iki *сан.* ике; *ikimiz* икебез
ikicanlı *с.* авырлы, йөкле
ikici *и.* дуалист
ikicilik *и.* дуализм
iki çenetli *с.* ике якка ачылмалы (*җимеш*)
iki eşeyli *с.* ике җенесле
ikilemek *ф.* икеләтү, ике тапкыр арттыру
ikilem *и.* дилемма
ikili *с.* икеле, ике өлештән торган
ikindi *и.* икенде, төштән соңгы вакыт
ikiyüzlü *с.* ике йөзле
ikiz *и.* игез; *ikiz doğmak* игез бала туу
ikizkenar *с.* тигезьяклы
iklim *и.* 1) климат; 2) өлкә
ikmal *и.* 1) тәмамлау, бетерү; 2) тулыландыру; 3) камиллек
ikna *и.* ышаныч казану
ikona *и.* икона
ikram *и.* 1) хөрмәт, кадер; 2) сый, хөрмәт □ **ikram buyurmak** сыйлау; кунакка ни дә булса бирү; 2) сатып алучыга яхшылык йөзеннән товарның бераз бәясен киметү
ikramcı *с.* кунакчыл
ikrar *и.* тану, танылу
iksir *и.* эликсир □ **hayat iksiri** тереклек суы
iktidar *и.* 1) куәт, егәр; 2) хакимлек, власть
iktisadî *с.* икътисадый
iktisat *и.* икътисад
iktisatçı *и.* экономист, икътисадчы
il *и.* губерна, вилаять
ilmek *ф.* бәйләп кую, тоташтыру; элəктереп кую, элəктерү
ilâç *и.* 1) дару; 2) *күч.* чара
ilâçlamak *ф.* дарулау, дару сөртү, бәлзәмләү
ilâçlı *с.* дару катнаштырылган; даруланган
ilâçsız *с.* 1) дәвалап булмый торган; 2) дарусыз
ilâh *и.* илаһ, алла, тәңре
ilâhe *и.* алиһә
ilâhî *с.* илаһи
ilâhiyat *и.* илаһият, теология
ilâhiyatçı *и.* теолог, дин белгече
ilâm *и.* хөкем, суд карары; □ **ilâm almak** хөкем карары язылган документны алу

ilân *и.* игълан, хәбәр
ilâve *и.* 1) өстәмә; 2) кушымта □ **ilâve etmek** өстәү
ilçe *и.* илчә (*Төркиядә административ берәмлек*)
ile *бәйл.* белән; *dostuyla* (*dostu ile*) дусты белән; *baba ile oğul* атасы белән улы
ilenmek *ф.* каргау, каһәрләү
ilenç *и.* каргыш, каһәр, ләгънәт
ileri *и. с.* 1) ал, алгы (як); 2) ал, киләчәк; 3) алгы; *ileri hat* алгы сызык; 4) алдагы, әүвәлге; 5) алда; *saat beş dakika ileridir* сәгать биш минутка алда; 6) *күч.* алга киткән, алдынгы; *ileri fikirler* алдынгы фикерләр ◊ **ileri gelenler** алдынгы карашлы кешеләр
ilerici *с.* алдынгы карашлы, яңалык яклы
ilericilik *с.* прогрессивлык, алдынгы карашлылык
ilerlemek *ф.* алга бару, үсү
iletmek *ф.* 1) илтү; 2) *физ.* үткәрү
iletim *и.* үткәрүчәнлек
iletken *и.* 1) хәбәр итүче; 2) уздыручы; 3) үткәргеч
iletkenlik *и.* үткәрүчәнлек
iletki *и.* транспортир
ilgeç *и.* элгеч
ilgi *и.* мөнәсәбәт, бәйләнеш
ilgilenmek *ф.* кызыксыну
ilgilendirmek *ф.* кызыксындыру, кагылу; *bu beni ilgilendirmez* бу миңа кагылмый
ilgili *с.* бәйләнешле
ilginç *с.* кызыксыну уята торган
ilgisiz *с.* бәйләнешсез, кагылышы булмаган
ilgisizlik *и.* ваемсызлык
ilham *и.* илһам, рух
ilik I *и.* элмәк (*төймәләү өчен*)
ilik II *и.* җелек ◊ **iliklerine geçmek** җелекләренә үтү; **iliğini kurutmak** җелеген корыту
iliklemek *ф.* эләктерү
ilim *и.* гыйлем, фән □ **ilim adamı** галим; **ilimler akademisi** фәннәр академиясе; **hukuk ilmi** юриспруденция, хокук фәне
ilinti *и.* мөнәсәбәт, бәйләнеш
ilintili *с.* катнашы булган
ilişmek *ф.* ябышу, эләгү, тию
ilişik 1. *с.* 1) эләктерелгән, беркетелгән, тагылган; 2) мөнәсәбәтле, бәйләнешле. 2. *и.* 1) мөнәсәбәт, бәйлелек; 2) кушымта
iliştirmek *ф.* эләктерү; ялгау
ilk *с.* башлангыч, элек, беренче; *ilk adım* беренче адым
ilkbahar *и.* яз; *ilkbahar geldi* яз килде
ilkçağ *с.* борынгы заман, антик чор
ilke *и.* 1) беренче (төп, баш) сәбәп; 2) принцип, нигез
ilkel *с.* 1) башлангыч; 2) борынгы, артта калган; 3) гади
ilkin *рәв.* алдан, борын-борыннан килә торган
ilklik *и.* беренчелек
ilkokul *и.* башлангыч мәктәп
ilköğretim *и.* башлангыч белем
ilkönce *рәв.* башта, иң элек
ilkyaz *и.* яз
ille *кис.* иллә, бигрәк тә, иллә мәгәр
illet *и.* авыру, чир, хаста □ **illet etmek** 1) тәңкәгә тию; 2) имгәтү, гарипләү; **illet**

olmak ярсу, нервылану
illetli *с.* 1) чирләшкә; 2) *күч.* кабат-кабат хаталанучы
illüstrasyon *и.* иллюстрация
illüzyon *и.* иллюзия
illüzyonist *и.* иллюзионист
ilmek *и.* элмәк
ilmî *с.* гыйльми; *ilmî araştırma* гыйльми тикшеренү
ilmik *и.* элмәк, күз; *ilmik sökmek* күзе китү (сүтелү)
ilmiklemek *ф.* элмәкләп бәйләү
ilmühaber *и.* таныклык
iltica *и.* яшеренер урын, ышык урын
iltifat *и.* илтифат
iltifatlı *с.* илтифатлы
iltihabî *с.* ялкынсынган
iltihap *и.* ялкынсынган урын (*тәндә*)
iltihaplanmak *ф.* ялкынсыну; эренләү
iltimas *и.* яклау, яклашу
iltimasçı *и.* яклаучы
iltimaslı *с.* яклаучысы булган (*кеше*)
ilzam *и.* җавап кайтармаслык итү (*бәхәстә*), авызын томалау
im *и.* билге, тамга
ima *и.* 1) читләтеп әйтү, сиздерү, ишарәтләү; 2) читләтеп әйтелгән сүз; □ **ima etmek** читләтеп әйтү
imal *и.* 1) җитештерү; эшләп чыгару; 2) ясау, эшләү; *ayakkabı imal etmek* аяк киеме эшләп чыгару
imalât *и.* җитештерелгән продукция
imalâtçı *и.* җитештерүче, эшләп чыгаручы (*кеше яисә предприятие*)
imalı *с.* кинаяле, читләтеп әйтелгән
imam *и.* имам, мәхәллә башлыгы
imambayıldı *и.* бадымҗаннан хәзерләнгән ризык
imamlık *и.* имамлык
iman *и.* иман, ышаныч
imanlı *с.* иманлы
imansız *с.* имансыз
imansızca *рәв.* ерткычларча, вәхшиләрчә
imansızlık *и.* имансызлык, динсезлек
imar *и.* 1) тезү, салу; 2) төзекләндерү
imaret *и.* хәйрия җәмгыяте
imbat *и.* җәйге муссон, диңгез җиле
imbik *и.* дистилляцияләү, сафландыру (*суны*)
imdat 1. *и.* ярдәм, коткару. 2. *ы.* коткарыгыз!
imdi *терк.* шулай итеп
imece *и.* күмәк хезмәт, өмә
imge *и.* хыял
imgelem *и.* хыялыйлык
imha *и.* юк итү, кыру
imik *и.* бугаз
imkân *и.* мөмкинлек, ихтималлык; *imkân bulundukça* мөмкин кадәр □ **imkânı yok** мөмкин түгел
imkânsız *с.* мөмкин булмаган, тормышка ашыра алмаслык
imkânsızlaşmak *ф.* мөмкин булмау
imkânsızlık *и.* мөмкин түгеллек

imlâ I *и.* тутыру
imlâ il *и.* имла, сүзләрне дөрес язуда кабул ителгән тәртип, орфография
imlemek *ф.* 1) билгеләү; тамгалау; 2) ымлау, ым кагу
imparator *и.* император
imparatorluk *и.* империя, монархия □ **Osmanlı imparatorluğu** Госманлы империясе
imren *и.* кызыгу
imrenmek *ф.* 1) теләү; 2) көнләшү, кызыгу
imrenti *и.* 1) теләк; 2) көнчелек **imsak** *и.* тыелу; тыйнаклык □ **imsak etmek** ашаудан тыелу
imtihan *и.* имтихан, сынау
imtiyaz *и.* өстенлек, аерым хокук
imtiyazlı *с.* өстен булган, өстенлекле
imza *и.* имза □ (**bir şeye**) **imza atmak**, (**bir şeyi**) **imza etmek** имза кую, кул кую
imzalamak *ф.* кул кую
imzalı *с.* кул куелган, имзалы
imzasız *с.* имзасыз
in I *и.* 1) өн; 2) мәгарә ◊ **in gibi** тар һәм караңгы (урын)
in II *и. сир.* инсан, кеше □ **in misin**, **cin misin**? кешеме син, җенме син? (*әкиятләрдә*)
inmek *ф.* 1) *төрле мәгъ.* төшү; 2) (*кунакханәгә*) урнашу; 3) чигенү, кимү (*су, шеш һ. б.*); 4) иңү, чүгү
inadına *рәв.* 1) киреләнеп, каршы, исәпләшмичә; 2) киресенчә
inak *и.* догма, кагыйдә, канун
inal *и.* ышанычлы кеше
inan *и.* инану, ышаныч
inanmak *ф.* инану, ышану
inanç *и.* ышаныч, гарантия
inançlı *с.* 1) ышанычлы; 2) динле, диндар
inançsız *с.* 1) ышанычсыз; 2) динсез
inandırmak *ф.* ышандыру, инандыру
inanılmaz *с.* кеше ышанмаслык, акылга сыймаслык
inanlı *с.* диндар, тәкъвә, динле
inansız *с.* 1) инанмаган; 2) динсез, алласыз
inat 1. *и.* киреләнү. 2. *с.* кире, үзсүзле
inatçı *с.* кире, тискәре
inatlaşmak *ф.* киреләнү, карышу
ince *с.* 1) юка; 2) нәфис, нечкә; 3) *күч.* нәфис, күңелгә ятышлы; *ince bir karşılık* әдәпле җавап; *ince zevk* нечкә зәвык
incelemek *ф.* 1) бөртекләп (җентекләп) эшләү; 2) җентекләп тикшерү (карау)
incelik *и.* 1) нечкәлек, нәзеклек, юкалык; 2) әдәплелек, нәзакәтлелек; 3) үткенлек; 4) нечкәлек
incelmek *ф.* 1) нечкәрү, юкару, нәзегәю; 2) ябыгу; 3) *күч.* нәзакәтләнү; 4) сыегаю (*куе сыеклык тур.)*
inceltmek *ф.* нечкәртү, юкарту
inci *и.* энҗе; *inci gerdanlık* энҗе муенса
inciçiçeği *и.* энҗе чәчәк
incik I *с.* бәрелгән, сыдырылган
incik II *и.* тез, балтыр сөяге
İncil *и.* Инҗил, Евангелие
incinmek *ф.* имгәнү
incir *и.* инҗир

incitmek *ф.* 1) имгәтү, җәрәхәтләү; 2) үпкәләтү
inç *и.* (*инглизләрдә*) 2,540 см га тигез булган үлчәү берәмлеге
indikatör *и.* индикатор
indirmek *ф.* төшерү, аска ию
indirgemek *ф.* иң уңайлы хәлгә китерү
indirim *и.* ташлама
indirilmek *ф.* төшерү, түбәнәйтү
individüalist *и.* индивидуалист
individüalizm *и.* индивидуализм
inek *и.* сыер; *inek ahırı* сыер абзары
inekçi *и.* 1) көтүче, мал караучы; 2) мал хуҗасы
inekçilik *и.* терлекчелек
infaz *и.* үтәлү, тормышка ашу
infial *и.* ярсу, ачу, тәэсирләнү
infilâk *и.* шартлау, ярылу
İngiliz *и.* инглиз
İngilizce 1. *и.* инглиз теле. 2. *рәв.* инглиз телендә, инглизчә
ingin *с.* түбән
inginlik *и.* 1) түбәнлек, иңкүлек; 2) картлык
inhisar *и.* 1) чикләү; 2) монополия
inhisarcı *и.* монополист
ini *и.* каен эне, кайниш
inik *с.* төшкән, иңгән
inikâs *и.* кайтаргыч, чагылдыргыч
inilmek *ф.* төшү, иңү
inildemek *ф.* ыңгырашу, иңрәү
iniş *и.* төшү; кире чүгү
inişli *с.* төшеп торган, сөзәк
inkâr *и.* инкяр □ **inkâr etmek** инкяр итү
inkılâp *и.* 1) инкыйлап, революция; 2) үзгәреш
inkılâpçı *и.* инкыйлапчы, революционер
inkıraz *и. иск.* инкыйраз, бетү, һәлакәт, юк булу
inkişaf *и.* ачылу, фаш булу
inlemek *ф.* ыңгырашу, иңрәү
inme *и.* 1) су чигенүе; 2) паралич
inmeli *с.* паралич суккан
inorganik *с.* органик булмаган
insaf *с.* инсаф
insaflı *с.* инсафлы, тәүфикълы, тыйнак
insan *и.* инсан, кеше
insaniyet *и.* инсаният, кешелек, кешелек дөньясы
insaniyetli *с.* инсаниятле, кешелекле, мәрхәмәтле
insanlık *и.* 1) кешелек дөньясы; 2) кешелек ◊ **insanlıktan çıkarmak** кешелектән чыгару
insanoğlu *и.* адәм баласы
insanüstü *с.* кеше кулыннан килмәслек
inşa *и.* төзелеш, корылма
inşaat *и.* төзелеш (эшләре)
inşaatçı *и.* төзүче
inşallah *кер. сүз.* иншалла, алла кушса, алла боерса
intan *и.* йогышлы авыру
intanî *с.* инфекцион, йогышлы

integral *и.* интеграл
intibah *и.* уяну
intibak *и.* туры килү, яраклашу
intihar *и.* 1) үзен-үзе үтерү, үз-үзенә кул салу; 2) *күч.* үзен-үзе куркыныч астына кую
intikal *и.* күчү, күчеш
intikam *и.* үч
intikamcı *с.* үчле, үч алучан
intişar *и.* 1) таралу, җәелү; 2) басылып чыгу, нәшер ителү
intizam *и.* тәртип
intizamlı *с.* тәртипле, оешкан
intizamsız *с.* тәртипсез, буталчык
intizar *и.* интизар, зарыгу
inzal *и.* 1) төшерү; 2) бушату
inzibat *и.* тәртип, дисциплина
inzibatî *с.* дисциплинар
inzibatsız *с.* тәртипсез
inziva *и.* ялгыз яшәү; үз эченә бикләнү
ip *и.* җеп, бау, канат, аркан ◊ **ipe çekmek** асып кую; **ip çözmek** араны өзү; **ip ucu** җеп очы, дәлил, эз
ipek *и.* ефәк; **ipek böceği** ефәк корты; **ipek kozası** ефәк кузысы
ipekçilik *и.* ефәклелек, ефәк корты үрчетү
ipekhane *и.* ефәк урау эшханәсе
ipekli *с.* ефәк ...; *ipekli gömlek* ефәк күлмәк
ipipullah *и.* ярлы, хәерче кеше
iplemek *ф.* җеп чорнау
ipliklerimek *ф.* сүсәрү, тузу
ipnotize, **hipnotize** *с.* гипнозланган; **ipnotize etmek** гипнозлау
ipnoz, **hipnoz** *и.* гипноз
ipotetik *с.* фаразый
ipsi *с.* җепсыман
ipsiz *с.* 1) җепсез; 2) бәйсез; 3) *күч.* сукбай
iptal *и.* бетерү, юкка чыгару, гамәлдән чыгару
irade *и.* 1) ихтыяр көче; 2) Ирадә, теләк, омтылыш
iradecilik *и. фәлс.* волюнтаризм
iradeli *с.* нигезле
İranlı *с.* иранлы, фарсы
irat *и.* табыш, төшем
irdelemek *ф.* тикшерү, өйрәнү
irfan *и.* 1) белем; 2) алдан күрү
iri *с.* зур, эре
irilik *и.* эрелек, зурлык
irili ufaklı *с.* эреле-ваклы
irin *и.* эрен
irinlenmek *ф.* эренләү
irinli *с.* эренле
iris *и. анат.* күзнең төсле катламы
iriş *и.* беләк
iriyarı *с.* эре, таза, зур гәүдәле
irkilmek *ф.* 1) *мед.* ялкынсыну; 2) сискәнеп китү, куркып калу
irmik *и.* ярма, эре итеп тартылган он
irrasyonalizm *и.* иррационализм

irtibat *и.* элемтә, бәйләнеш
irticai *и.* импровизация, алдан хәзерләнмәгән чыгыш
irtifa *и.* 1) биеклек; 2) *геогр.* үр
is *и.* корым, серем
isabet 1. *и.* 1) максатка ирешү; 2) отыш; 3) туры килү. 2. *ы.* бик яхшы!
isabetli *с.* урынлы, вакытлы
isabetsiz *с.* урынсыз, ялгыш
ise *кис.* исә
İsevî *и.* христиан, христиан динендәге кеше
isfendan *и.* чаган, өрәңге
isim *и.* исем ◊ **ismin cismine uysun** исемең җисемеңә туры килсен
isimli *с.* исемле
isimsiz *с.* исемсез, билгесез; *isimsiz kahraman* билгесез батыр
iskân *и.* урнашу
iskandil *и.* лот (*прибор*)
İskandinavyalı *и.* Скандинавия кешесе
iskarpela *и.* өтерге
iskarpin *и.* туфли; *ökçeli iskarpin* үкчәле туфли
iskele *и.* пристань
iskelet *и.* 1) скелет; 2) каркас
iskemle *и.* утыргыч, урындык, эскәмия
İskoç *и.* шотландияле
İslâm *и.* ислам
islâmlaşmak *ф.* ислам динен кабул итү
islemek *ф.* ыслау, каклау; *balık islemek* балык ыслау
islenmek *ф.* 1) ыслану; 2) көю (*мәс., сөт*)
isli *с.* ысланган, какланган
ismen *рәв.* атап, исемен әйтеп
isnat *и.* 1) (*берәр эшне, фикерне һ. б.*) башка берәүгә тагу, аныкы дип күрсәтү; 2) яла, гайбәт
İspanyol *и.* испан, испанияле
İspanyolca 1. *и.* испан теле. 2. *рәв.* испан телендә, испанча
ispat *и.* исбат, дәлил □ **ispat etmek** исбат итү
ispatlamak *ф.* исбатлау
ispatlanmak *ф.* исбатлану
ispermeçet *и.* спермацет □ **ispermeçet balinası** кашалот
ispir *и.* ат караучы
ispirto *и.* спирт
ispirtolu *с.* спиртлы
ispirtosuz *с.* алкогольсез, спиртсыз
ispiyon *и.* шпион, шымчы
ispiyonlamak *ф.* шпионлык итү, шымчылык итү
ispritizma *и.* спиритизм
israf *и.* исраф, әрәм-шәрәм
istasyon *и.* станция, вокзал
istatistik *и.* статистика
istavroz *и.* тәре □ **istavroz çıkarmak** чукыну
istemek *ф.* 1) теләү; 2) сорау; *kitap istedi* китап сорады
istek *и.* 1) теләк, үтенеч; 2) таләп; 3) *гр.* теләк наклонениесе
istektendirmek *ф.* теләк кузгату (уяту)
istekli *с.* көчле теләкле, ашкынулы
isteksiz *с.* теләксез

ister *и.* кирәклек, зарурлык, хаҗәт
yaka *и.* 1) яка; *gömlek yakası* күлмәк якасы; 2) як, чит, кырый; 3) *диңг.* җилкәннең читләре һәм почмаклары ◊ **yakasına asılmak** (**yapışmak**) якасына ябышу, якасыннан алу; **yakayı kurtarmak** (**sıyırmak**) котылу
yakacak *и.* ягулык
yakalamak *ф.* кулга алу, эләктерү, тоту
yakalanmak *ф.* 1) кулга алыну, тотылу; 2) эләгү (*мәс., яңгырга*)
yakarmak ф. ялварып сорау, үтенү
yakarı, **yakarış** *и.* ялвару, үтенү
yakı *и.* җылытып дәвалау чарасы □ **hardal yakısı** горчичник
yakıcı *с.* 1) яндыручы, яндыра торган; 2) *күч.* тәэсирле
yakın *с.* якын; *yakın dost* якын дус; *beyaza yakın renk* акка якын төс; *yakın oturuyor* якын тора (яши); *yakın gelecekte* якын киләчәктә
yakında *рәв.* 1) якында; 2) тиздән; *yakında görüşürüz* тиздән күрешербез
yakından *рәв.* якыннан; *yakın-nan bilmek* якыннан белү
yakınlaşmak *ф.* якынлашу
yakınlık *и.* 1) якынлык; 2) якынлык, якын кардәшлек
yakışmak *ф.* килешү, килешеп тору; туры килү
yakışık *и.*1) сөйкемлелек; 2) туры килү; яраклы булу □ **yakışık almak** яраклы булу
yakışıklı *с.* 1) сөйкемле, күркәм; 2) яраклы; килешле
yakışıksız *с.* 1) сөйкемсез, матур түгел; 2) яраксыз, килешсез
yakıt *и.* ягулык
yaklaşmak *ф.* 1) якынаю, якынлашу; 2) охшау, хәтерләтү
yaklaşık *с.* якынча; *yaklaşık bir sayı* якынча бер сан
yaklaştırmak *ф.* якынайту
yakşı *с.* яхшы
yakut *и.* якут, якут кешесе
yakut *и.* якут (*асылташ*)
yakutça 1. *и.* якут теле. 2. *рәв.* якут телендә, якутча
yalamak *ф.* ялау, ялап алу
yalabık 1. *с.* ялтыравыклы. 2. 1) *и.* ялтырау, ялкынлану; 2) елдырым
yalak *и.* 1) тагарак, ялгаш (*терлекләргә су эчертү өчен*); 2) чишмә бурасы
yalaka *и. сөйл.* ялагай
yalan *и. с.* ялган, алдау □ **yalan atmak** ялганлау; **yalan çıkarmak** 1) гайбәт тарату, ялган сөйләп йөрү; 2) ялганга чыгару, юкка чыгару, кире кагу; **yalan söylemek** ялган сөйләү; **yalan yok** алдамыйча, ялганламыйча
yalanmak *ф.* ялану

yalancı *и. с.* 1) ялганчы; алдакчы; 2) ясалма, чын булмаган; *yalancı elmas* ялган алмаз; *yalancı inci* ясалма энҗе
yalancılık *и.* ялган; алдау; ялган сүзләр
yalanlamak *ф.* юкка чыгару, кире кагу, ялган икәнен белдерү
yalapşap *рәв.* әштер-өштер
yalaz *и. сөйл.* ялкын
yalçın *с.* текә; *yalçın kaya* текә кыя
yaldırak *с.* ялтырак
yaldız *и.* 1) (*берәр нәрсә өстенә*) йөгертелгән алтын (яки көмеш); алтын (яки көмеш) йөгертелгән кәгазь; 2) тышкы матурлык, ялтыравык
yaldızcı *и.* алтынлаучы
yaldızlamak *ф.* алтын (яки көмеш) йөгертү
yaldızlı *с.* 1) алтын (яки көмеш) йөгертелгән; 2) *күч.* тышкы матурлыклы, ялтыравыклы
yalı *и.* 1) яр (*диңгез яки елганыкы*); *yalı boyu* яр буе; 2) җәйге йорт, дача
yalım *и.* 1) ялкын; 2) (*кылыч, пычак һ. б. ш. да*) йөз
yalın I *и. сөйл.* ялкын
yalın *с.* 1) ялангач; 2) гади, бизәксез (*сүз, язу һ. б.*)
yalınayak 1. *с.* яланаяклы. 2. *рәв.* яланаяк, яланаяк килеш
yalıncak *с. сөйл.* ялангач
yalınç *с.* ялгыз; гади
yalınlaşmak *ф.* 1) ялангачлану; 2) гадиләшү
yallah *ы.* әй, бара бир(егез); кит(егез); әйдә, әйдәгез
yalnız I *кис.* тик, бары, гына; әмма; *güzel, yalnız biraz renksiz* матур, әмма бераз тоныграк
yalnız *с.* 1) үзе бер, берәү, бердәнбер; *yalnız bırakmak* үзең генә калдыру; 2) мөстәкыйль
yalpak *с.* йөдәтүчән; бәйләнчек
yaltak , **yaltakçı** *с.* ялагай
yaltakçılık *и.* ялагайлык
yaltaklanmak *ф.* ялагайлану
yaltaklık *и.* ялагайлык
yalvarmak *ф.* үтенү, сорау, ялвару
yama *и.* ямау; *yama vurmak* ямау салу
yamamak *ф.* 1) ямау, ямау салу; 2) *күч.* (*начар, түбән сыйфатлы әйберне*) сатып җибәрү, биреп җибәрү
yamak *и.* ярдәмче; йомышчы малай
yamalı *с.* ямаулы **yamaç** *и.* сөзәклек, тау итәге
yaman *с.* 1) искиткеч, таңкалдыргыч; шаккатыргыч; *yaman bir iş* искиткеч бер эш; 2) яман, начар; усал; *yaman bir kişi* яман бер кеше
yamçı *и.* җиңсез тула чикмән
yampiri *с.* какре-бөкре
yamrulmak *ф.* кәкре-бөкре булу, чалыш-чолыш булу
yamru yumru *с.* чалыш-чолыш
yamuk 1. *с.* чалыш, кыек. 2. *и. мат.* трапеция
yamulmak *ф.* бөгелү
yan *и.* 1) як, ян; тараф; *öte yandan* башка яктан; 2) фланг; 3) профиль; *yan cep* ян кесә; *yan kapı* ян капка □ **yanma almak** үзе белән алу; **yanı sıra** аның белән бергә, бер рәттән; **bu yanına** бирегә, бу ягына; **her yanda** һәр җирдә, һәр тарафта; **hiç bir yanda** бер кайда да ◊ **yanına varılmaz** бик кыйммәт, сатып алырлык түгел **yanmak** *ф.* 1) яну, янып китү; кабыну; *lâmba yandı* лампа кабынды; 2) көю, янып чыгу; *ekmek yandı* икмәк көйде; 3) пешү; *eli yandı*

купы пеште; 4) кызу; кызышу; *bedenim yanıyor* тәнем кыза
yanak *и.* яңак; *yanak çukuru* бит чокыры
yanardağ *и.* янартау, вулкан
yanaşmak *ф.* 1) якынлашу, якынлашып килү; 2) *күч.* кызыксыну
yanaşık *с.* якын; аралаш
yanaşılmak *ф.* якынлашу, якынлашып килү
yanaştık *и.* пристань
yanaşma *и.* 1) якынлашу; 2) хезмәтче; батрак
yanay *и. мат.* вертикаль кисем
yandaş *и.* тарафдар
yandırmak *ф.* яндыру
yangı *и.* ялкынсыну; *boğaz yangısı* бугаз ялкынсынуы
yangılanmak *ф.* ялкынсыну
yangın *и.* 1) янгын; *yangın var!* янабыз; янгын!; 2) *сөйл.* югары температура (*авыруда*); 3) *күч.* кайнарлык; сөю ялкыны
yanık 1. *с.* 1) янган; 2) *күч.* ялкынлы, янган (*йөрәк*); 3) *күч.* кайгылы, хәсрәтле. 2. *и.* янган урын
yangıncı *и.* янгынчы
yanılmak *ф.* ялгышу; хаталану; *yanıldım* ялгыштым
yanılgı *и.* ялгышлык, хата
yanılış *и.* ялгыш, хата; ялгышу
yanılmaz *с.* ялгышсыз, хатасыз; ялгышмый торган
yanıltmak *ф.* ялгыштыру
yanıltı *и.* ялгышлык (*бик җитди булмаган*)
yanıltıcı *с.* ялгыштыручы
yanıt *и.* җавап
yanıtlamak *ф.* (*сорауга*) җавап бирү
yani терк. ягъни
yankesici *и.* кесә карагы
yankı *и.* яңгыраш, яңгырау; кайтаваз □ **yankı bilimi** акустика
yankılamak *ф.* яңгырау, кабатланып яңгырау
yanlı *и.* тарафдар
yanlış 1. *и.* хата, ялгыш; *yanlışı düzeltmek* ялгышны төзәтү. 2. *с.* хаталы, ялгышлы; □ **yanlışını çıkarmak** ялгышын күреп алу (күрсәтү)
yanlışlık *и.* ялгышлык, хата; *bir yanlışlık oldu* бер ялгышлык килеп чыкты
yansımak *ф.* чагылу (*яктылык*)
yansılamak 1) чагылдыру (*яктылыкны*); 2) гәүдәләндерү, чагылдыру; иярү
yansıtaç *и.* рефлектор
yansız *с.* битараф
yanşak *с.* лыгырдык, бытылдык, күп сөйләшүче
yap**ma**k *ф.* 1) эшләү, үтәү, башкару; *iş yapmak* эш башкару; 2) төзү, ясау; *resim yapmak* рәсем ясау 3) төзәтү, ремонтлау; 4) хәзерләү; 5) булышлык итү, сәбәпче булу; 6) эш итү, эш кылу; 7) булу; 8) булдыру, ясау □ **yapamamak** булдыра алмау; **ne yapalım**! нәрсә эшлисең! ни эшләмәк кирәк! **yapma**! китче! кит аннан! (*искитүне белдерә*)
yapalak *и. зоол.* ябалак
yapay *с.* ясалма □ **yapay dil** ясалма тел (*сөйләшү өчен*)
yapı *и.* 1) бина, корылма; *betonarme yapı* тимер-бетон корылма; 2) төзелеш; *yapı makineleri* тезелеш машиналары; 3) *лингв.* сүзьясалышы; *yapım eki* сүзьясалыш кушымчасы; 4) гәүдә, бәдән
yapıcı *и.* 1) төзүче; 2) ясаучы, башкаручы, барлыкка китерүче
yapıcılık *и.* тезелеш; архитектура

yapım *и.* җитештерү; тезелеш; ясау □ **yapım evi** ашханә, кырханә
yapınmak *ф.* ябыну
yapışmak *ф.* 1) ябышу; 2) ябышып тору; 3) *күч.* тагылу, көчләп тагылу
yapışık 1) ябышкан, ябыштырылган; ябышучан; 2) *күч.* бәйләнчек, йөдәтүчән
yapıştırmak *ф.* 1) ябыштыру; 2) *күч.* әйтеп салу, уйламыйча әйтү ◊ **bir tokat yapıştırmak** яңагына тондыру
yapıt *и.* әсәр, хезмәт; эш
yaprak *и.* 1) яфрак; *çam yaprağı* ылыс; *çiçek yaprağı* чәчәкнең таҗ яфракчыгы; 2) бит; *kitabın yaprakları* китапның битләре; 4) табак (*мәс., тимернең*)
yapraklanmak *ф.* яфраклану
yapraklı *с.* яфраклы
yapraksız *с.* яфраксыз
yar I *и.* ярдәмче (*сүзенең кыскартылмасы*); *yarmüdür* мөдир урынбасары; *yaröğretmen* укытучы ярдәмчесе
yar II *и.* яр, текә яр
yâr *и.* яр, дус, яраткан кеше
yarmak *ф.* яру; кисү
yara *и.* 1) яра, җәрәхәт, киселгән урын; *yara kabuğu* кутыр; *açık yara* ачык яра; *bıçak yarası* пычак ярасы; 2) тишек □ **yara almak** яралану
yaramak *ф.* 1) ярау; 2) файдалы булу; туры килү
yaradan *и.* тәңре, алла, яратучы
yaradılış *и.* 1) ярату, барлыкка китерү; 2) табигать, холык
yaradılıştan *рәв.* туганнан бирле
yaralamak ф. 1) яралау, җәрәхәтләү; 2) *күч.* тию, кагылу, хәтерен калдыру
yaralanmak *ф.* 1) яралану, җәрәхәтләнү; 2) *күч.* хәтер калу, рәнҗү
yaralı *с.* 1) яралы; *ağır yaralı* авыр яралы; 2) *күч.* кәефе киткән, күңелсезләнгән
yaramaz *с. и.* 1) наян, шук, шаян; 2) яраксыз, юньсез
yârân *и.* дус; яран
yarar 1. *и.* файда, яхшы нәтиҗә. 2. *с.* яраклы, ярардай
yararlanmak *ф.* файдалану; файда алу
yararlı *с.* яраклы, файдалы
yararsız *с.* яраксыз, файдасыз
yarasa *и. ярканат*
yaraşmak *ф. төрле мәгъ.* килешү; *böyle konuşmak sana yaraşmıyor* болай сөйләшү сиңа килешми
yaraştırmak *ф.* яраштыру, туры китерү
yaratmak *ф.* ярату, барлыкка китерү, китереп чыгару
yaratıcı *и.* яратучы, барлыкка китерүче
yaratık *и.* зат, мәхлук, җан иясе
yarbay *и.* подполковник
yardım *и.* ярдәм, булышу; *yardım göstermek* ярдәм күрсәтү; *yardım ve işbirliği anlaşması* үзара ярдәмләшү һәм хезмәттәшлек турында килешү; *ilkyardım* беренче ярдәм; *maddi ve manevi yardım* матди һәм мораль ярдәм □ **yardım etmek** ярдәм итү
yardımcı *и.* ярдәмче, урынбасар, булышчы □ **yardımcı cümle** *гр.* иярчен җөмлә; **yardımcı fiil** *гр.* ярдәмче фигыль
yardımlaşmak *ф.* ярдәмләшү
yaren *и.* иптәш, дус
yarenlik *и.* дуслык
yargı *и.* 1) *фәлс.* хөкем; 2) *юр.* нәтиҗә, карар
yargıcı *и.* арбитр, судья
yargılamak *ф.* хөкем итү

yarı *и.* ярты, ярым □ **yarı çıplak** ярым ялангач; **yarı çöl** ярым чүл; **yarı gece** ярты төн; ярты төндә; **yarı yolda** ярты юлда; **yarıda kalmak** уртада калу
yarıcı *и.* кисүче; яручы
yarık 1. *и.* ярык. 2. *с.* ярылган; киселгән
yarılmak *ф.* ярылу
yarılamak *ф.* уртасына җитү, яртысын бетерү
yarım *с.* 1) ярым; ярты; 2) тулы түгел, тәмамланмаган; *yarım otomatik* ярым автоматик; *yarım saat* ярты сәгать; *yarım yuvarlak* ярым түгәрәк
yarımada *и.* ярым утрау
yarımay *и.* ярым ай
yarın 1. *и.* иртәгесе көн. 2. *рәв.* иртәгә; *yarın sabah* иртәгә иртән
yarış *и.* 1) ярыш; *yarışa kalkmak* ярышырга тотыну (керешү); *yarış kaybetmek ярышта* җиңелү; *yarışı kazanmak* ярышта җиңү; 2) конкуренция; 3) чабышу; узышу
yarışmak *ф.* 1) ярышу; узышу; 2) ярышташ булу
yarışçı *и.* 1) ярышучы; 2) ярышташ, көндәш
yarlık *и. тар.* ярлык, фәрман
yas *и.* матәм; траур
yasmak *ф.* тигезләү; яссы итү
yasa *и.* канун; закон
yasamak *ф.* 1) тәртипкә китерү; 2) закон(нар) чыгару
yasak 1. *и.* тыю, рөхсәт итмәү; *av yasağı* ауны тыю. 2. *с.* тыелган; *yasaktır* тыелган, рөхсәт ителми; ярамый; *bu yoldan geçmek yasaktır* бу юлдан йөрү тыелган
yasaklamak *ф.* тыю, рөхсәт итмәү
yasemin *и. бот.* ясмин
yaslamak *ф.* терәк булу, терәп тору
yaslanmak I *ф. төрле мәгъ.* таяну
yaslanmak II *ф.* траурда булу
yasmık *и.* ясмык
yassı *с.* яссы; *yassı çakıl* яссы чуерташ
yassılanmak *ф.* яссылану
yastağaç *и. сөйл.* куна тактасы
yastık *и.* 1) ястык, мендәр; *yastık kılıfı* (*yüzü*) мендәр тышы; 2) түтәл
yaş I *и.* яшь; *çocuk on yaşında* бала ун яшендә; *yaş günü* туган көн
yaş 1. *и.* яшь, күз яше; *yaş akıtmak* елау*, gözyaşı* күз яше. 2. *с.* чи, дымлы; юеш; *yaş otun* чи утын; *yaş çamaşır* юеш кер
yaşa, **yaşasın** *ы.* 1) яшә, афәрин; 2) исәнлеккә, исәнлеккә-саулыкка
yaşamak *ф.* 1) яшәү, тору; *köyde yaşamak* авылда яшәү; 2) *күч.* типтереп яшәү
yaşantı *и.* тормыш, тормыш юлы
yaşarmak *ф.* дымлану, юешләнү **yaşayış** *и.* яшәеш, яшәү рәвеше
yaşıt *и. с.* яшьтәш
yaşlanmak *ф.* олыгаю, картаю
yaşlı I *с.* карт; олыгайган
yaşlı II *с.* яшьле (*күзләр*)
yaşlılık *и.* картлык, өлкәнлек
yatmak *ф.* 1) яту; *yan yatmak* ян белән яту; 2) риза булу; күңел яту; 3) куну; *açıkta yatmak* ачык һавада куну; 4) утыру (*төрмәдә*)
yatağan *и.* ятаган
yatak *и.* 1) урын-җир; карават; *yatak odası* йокы бүлмәсе; 2) үзән, юл; *nehir yatağı* елга юлы; 4) *күч.* притон (*каракларның*) □ **maden yatakları** мәгъдән ятмалары ◊ **yatağa yatmak** түшәккә калу; авырып китү
yatakhane *и.* тулай торак, интернат

yatay *с. мат.* горизонталь
yatırmak ф. 1) салу; *hastahaneye yatırmak* хастаханәгә салу; 2) сөрлектерү, егу; 3) салу, кертү; түләү (*акча*)
yatırım *и.* 1) капитал салу; инвестиция; 2) капитал; *yatırım yapmak капитан* салу
yatırımcı *и.* акча кертүче; инвестор
yatışmak *ф.* 1) тыну; тынычлану; туктау; *fırtına yatıştı* давыл тынды; 2) хәл ителү; *mesele yatıştı* мәсьәлә хәл ителде
yatıştırıcı *с.* тынычландыргыч (*дару*)
yatsı *и.* ястү; *yatsı namazı* ястү намазы
yavaş 1. *рәв.* 1) акрын; *yavaş bir yürüyüş* акрын бару; *yavaş konuş!* акрын сөйлә! 2. *с.* тыныч; акрын; *yavaş adam* тыныч кеше; *yavaş bir ses* акрын тавыш; ◊ **yavaş**! акрын! ашыкма! **yavaş yavaş** акрын гына
yavaşlamak *ф.* 1) акрынаю, әкренәю; 2) тыну; йомшару
yavaşlatmak *ф.* акрынайту, әкренәйтү
yavaşlık *и.* 1) акрынлык, әкренлек; 2) тынычлык, йомшаклык
yavru *и.* бала; *yavru köpek* көчек, эт баласы; *kedi yavrusu* мәче баласы; *kuş yavrusu кош* баласы □ **yavrum**! дустым! балакаем! (*эндәшү сүзе*)
yavrucuk *и.* 1) балакай; 2) кош баласы
yavrulamak *ф.* балалау, чагалау (*хайваннар тур.*)
yavşak *и.* серкә, бет серкәсе
yavşanotu *и.* әрем
yavuklamak *ф.* ярәшү (*өйләнү һәм кияүгә чыгу турында вәгъдәләшү*)
yavuklanmak *ф.* ярәшелү
yavuklu *с.* ярәшелгән
yavuz *с.* 1) кыю, батыр; 2) явыз, кырыс, каты күңелле
yavuzluk *и.* 1) кыюлык, батырлык; 2) явызлык, кырыслык
yay *и.* 1) җәя (*корал*); *yay kirişi* җәя кереше; 2) пружина; 3) дугасыман (җәясыман) нәрсә
yaymak *ф.* 1) җәю, киңәйтү; 2) тарату
yayan 1. *рәв.* җәяү. 2. *с.* мәгълүматсыз
yaygara *и.* шау-шу, тавыш
yaygın *с.* таралган, билгеле; киң таралаган; популяр
yaygınlaşmak *ф.* таралу
yayık I *и.* май язу җайланмасы; гөбе
yayık *с.* җәенке
yayılmak *ф.* 1) җәелү; 2) таралу
yayım *и.* 1) бастыру, бастырып чыгару; 2) тапшыру (*мәс., радио аша*)
yayımcı *и.* нәшер итүче, нәшир
yayımlamak *ф.* 1) бастыру, бастырып чыгару; 2) тапшыру (*мәс., телевизордан*)
yayın *и.* басма
yayınbalığı *и.* җәен
yayınevi *и.* басмаханә, типография
yayla *и.* җәйләү
yaylamak *и.* җәйне үткәрү (*тауларда, җәйләүдә*)
yaylak *и.* көтүлек
yayma *и.* күргәзмә (*сатыла торган әйберләрнең*)
yaymacı *и.* асламчы
yaz *и.* җәй; *yaz günü* җәй көне
yazmak I *ф.* 1) язу, язып кую, язып алу; 2) алу (*эшкә*)
yazmak II *ярдәмче ф.* язу; *düşe yazdı* егыла язды
yazar *и.* язучы, автор
yazarlık *и.* язучылык

yazı I *и.* 1) язу; *yazı kâğıdı* язу кәгазе; *yazı makinesi* язу машинкасы; *yazı masası* язу өстәле; *el yazıcı* кулъязма; 2) шрифт; 3) почерк, язу рәвеше; кул; 4) мәкалә □ **yazı dili** әдәби тел
yazı *и.* тигезлек, тигез җир
yazıcı *и.* сәркәтип, язу язучы
yazık *и.* 1) үкенеч; 2) гөнаһ, язык; 3) кызганыч (*ымлык функциясендә*) □ **yazık etmek** (**olmak**) зарар китерү
yazılmak *ф.* язылу; *çocuk okula yazıldı* бала мәктәпкә язылды
yazılı *с.* 1) язылган, язма, язулы; *yazılı emir* язылган боерык; 2) язмыш билгеләгән, язмыштан булган
yazın I *и.* җәен, җәйдә
yazın *и.* әдәбият
yazışmak *ф.* язышу
yazıt *и.* язулы таш
yazlamak *ф.* 1) җылыту, җылыну (*һава*); 2) җәй үткәрү
yazlık 1. *и.* 1) җәйге өй, дача; 2) җәйге кием. 2. *с.* җәйге; *yazlık giysi* җәйге кием
yazlı kışlı *рәв.* җәен-кышын
yazma 1. *и.* 1) язма; 2) кулъязма. 2. *с.* язылган (*кулдан*)
yazman *и.* секретарь, сәркәтип
yemak 1) ашау; 2) *күч.* исраф итү, туздыру, җилгә очыру; *miras yemek* мирасны җилгә очыру
yedek *и.* 1) запас, резерв; 2) җитәк, җитәктәге ат
yedekçi *и.* 1) атны җитактә йөртүче; 2) бурлак
yedi *сан.* җиде; *yedi defa* җиде кат (мәртәбә); *yedi saat* җиде сәгать; *saat yedi* сәгать җиде (*вакыт дәвамы*)
yedinci *сан.* җиденче
yedirmek *ф.* 1) ашату; туйдыру; 2) сеңдерү; 3) *күч.* ришвәт бирү
yedişer *сан.* җидешәр
yegâne *с.* бердәнбер
yeğ *с.* яхшырак, әйбәтрәк
yeğen *и.* бертуганның улы (яки кызы)
yeğin *с.* 1) көчле; куәтле; 2) *күч.* өстен
yeğinleşmek *ф.* 1) көчәю; 2) *күч.* өстенлек алу
yeğlemek *ф.* өстен күрү
yeğlik *и.* өстенлек
yeğni *с. сөйл.* 1) җиңел; 2) җитди булмаган
yeğnisemek *ф.* җитдигә санамау
yeis *и.* өметсезлек, рухый төшенкелек
yek *с.* бер, бердәнбер; *yek zarbdan* бер сугуда; берьюлы
yekinmek *ф.* урыныннан сикереп тору
yeknesaklık *и.* бертөрлелек
yekpare *с.* бөтен, тоташ
yekten *рәв.* 1) берьюлы; кинәт; 2) тиктомалга
yekûn *и.* барысы, җәмгысе
yel *и.* 1) җил; *yel değirmeni* җил тегермәне; 2) *сөйл.* ревматизм ◊ **yele vermek** җилгә җибәрү (*мәс., байлыкны*)
yelmek *ф.* җилү, элдертү
yele *и.* ял (*мәс., ат ялы*)
yeleç *с.* җиләс
yelek *и.* 1) казаки, жилет; 2) кош каурые
yelken *и.* җилкән □ **yelken açmak** 1) җилкәнне киерү; 2) диңгезгә чыгу
yelkenci *и.* 1) җилкән сатучы; 2) җилкәнче; матрос

yelkovan *и.* минут угы (*сәгатьнең*)
yellemek *ф.* җилпәзәләү
yelli 1) җилле (*урын, көн*); 2) ревматизмлы
yelpaze *и.* җилпәзә
yem *и.* 1) азык, терлек азыгы; җим; 2) алдавыч җим
yeme *и.* 1) туклану, ашау; 2) татым □ **yeme içme** ашау-эчү
yemek *и.* 1) ашамлык, ашау әйбере; *yemek listesi* меню; *yemek masası* аш өстәле; *yemek odası* аш бүлмәсе; *yemek tenceresi* кәстрүл; *akşam yemeği* кичке аш; *öğle yemeği* төшке аш; 2) аш (кунак ашы)
yemekhane *и.* ашханә
yemeklik *и.* 1) туклану акчасы; 2) ашарга яраклык нәрсә
yemeksiz *с.* ашау-эчү оештырылмаган
yemin *и.* ант □ **yemin bozmak** анты бозу; антны үтәмәү; **yemin vermek** ант итү
yemiş *и.* җимеш, җиләк-җимеш
yemlemek *ф.* 1) азык бирү, җим сибү; 2) *күч.* алдап кулга төшерү
yen I *и.* җиң (*киемдә*)
yen II *и.* Япониядәге акча берәмлеге
yenmek I *ф.* җиңү, җиңеп чыгу
yenmek II *ф.* ашарга ярый торган булу
yenge *и.* җиңги
yengeç *и.* кысла; краб
Yengeç *и. астр.* Кысла (*йолдызлык*)
yeni 1. *с.* яңа; *yeni usul* яңа ысул. 2. *рәв.* яңадан; яңа гына; күптән түгел; *yeni gelen яңа* гына килгән
yeniçeri *и.* янычар
yeniden *рәв.* яңадан, баштан; *yeniden yapmak* яңадан үзгәртеп эшләү
yenik I 1. *и.* тешләнгән эз, ашалган урын. 2. *с. геол.* ашалган
yenik II *с.* җиңелгән □ **yenik düşmek** җиңелү
yenilmek I *ф.* ашалу
yenilmek II *ф.* җиңелү
yenile-
yenilemek *ф.* 1) яңарту; төзәтү; 2) кабатлау
yenilenmek ф. 1) яңару, төзәлү; 2) кабатлану
yenilgi *и.* җиңелү
yenilik *и.* яңалык
yenilikçi *и.* яңалык тарафдары
yeniyetme *с.* балигъ булган
yeniyetmelik *и.* балигъ булу
yenli *с.* җиңле
yenme *и.* җиңү
yensiz *с.* җиңсез
yer *и.* 1) җир; *yerini sattı* җирен сатты; 2) урын; җир; *yer değiştirmek* урын алыштыру; 3) пункт, урын; *idare yeri* идарә пункты; 4) вакансия, эш урыны; 5) билге, эз; *bıçak yeri* пычак әзе; 6) роль, урын; әһәмият; *önemli yer* әһәмиятле урын □ **yer yurt** торган урын, йорт; **hiç bir yerde** беркайда да ◊ **yerine getirmek** үтәү, башкару; **yer kabul etmez** җир алмас, гөнаһка баткан
yermek *ф.* 1) хурлау, кимчелекләрен сөйләү; 2) яратмау, өнәмәү, җиксенү
yeraltı *и.* җирасты
yerbilimi *и.* геология
yerbilimci *и.* геолог
yerel *с.* җирле, урындагы
yergi *и.* сатира

yergici *и.* сатирик
yerinmek *ф.* кызгану, үкенү
yerinde *с.* урынлы, вакытлы
yerkatı *и.* аскы кат (подвал)
yeteneklilik
yerküre *и.* җир шары
yerleşmek *ф.* 1) урнашу, килеп урнашу; җирләшү; 2) урнашу (*эшкә*)
yerleştirmek *ф.* 1) урнаштыру (*квартирга, эшкә*); 2) *күч.* чәпәү, тондыру (*яңакка*)
yerli 1. *и.* җирле кеше; абориген. 2. *с.* 1) җирле; урындагы; *yerli mamulât* урындагы җитештерү; 2) стационар, күчми торган
yerlileşmek *ф.* җирләшү
yermumu *и.* озокерит, тау балавызы
yer sakızı *и.* битум
yer sarsıntısı *и.* җир тетрәү
yer sıçanı *и.* сукыр тычкан
yerüstü *и.* җир өсте
yeryuvarlağı *и.* җир шары
yeryüzü *и.* җир өслеге
yeşermek *ф.* 1) яшелләнү, яшәрү; 2) яфраклану
yeşertmek *ф.* яшелләндерү
yeşil *с.* 1) яшел; 2) яшел, өлгермәгән, пешеп җитмәгән; *yeşil domates* яшел помидор
yeşillenmek *ф.* яшелләнү
yeşillendirmek *ф.* 1) яшелгә буяу; 2) яшелләндерү
yeşillik *и.* 1) яшеллек; 2) яшелчә
yetmek *ф. төрле мәгъ.* җитү; *yetecek kadar* җиткән кадәр
yetenek *и.* сәләт
yetenekli *с.* сәләтле
yeteneklilik *и.* сәләтлелек
yeteneksiz *с.* сәләтсез
yeteneksizlik *и.* сәләтсезлек
yeter *с.* 1) җитәрлек; *yeteri kadar* җитәрлек дәрәҗәдә; 2) җитәр; *yeter, söyleme* җитәр, сөйләмә
yeterlik *и.* сәләтлелек, булганлык
yetersayı *и.* кворум
yetersiz *и.* сәләтсез; ким
yetersizlik *и.* кимчелек
yetim *и.* ятим (йәтим)
yetimhane *и.* ятимханә, приют, балалар йорты
yetimlik *и.* ятимлек
yetinmek *ф.* чикләнү, канәгать булу
yetirmek *ф.* 1) бетерү, тәмамлау; 2) үстерү (*баланы*); 3) тоту (*акчаны*)
yetişmek *ф.* 1) куып җитү; 2) килеп җитү; 3) тәмамлану; тәмам итү; 4) тию, кул җитү; 5) җитү, җитәрлек булу; 6) үсү; үрчү; 7) тәрбияләнү
yetişkin *с.* 1) зур; *yetişkin bir ağaç* зур агач; 2) балигъ булган
yetişme *и.* 1) үсү, арту; 2) балигъ булу; 3) пешеп җитү, өлгереп җитү
yetişmiş *с.* 1) үскән, балигъ булган; 2) пешкән; өлгереп җиткән
yetiştirmek *ф.* 1) китереп җиткерү; 2) хәбәр итү; тапшыру; 3) тәрбияләү, үстерү
yetiştirici *и.* җитештерүче
yetiştirme *с.* тәрбияләнүче, тәрбияләнгән □ **yetiştirme yurdu** (*ятим балаларны*) тәрбияләп үстерү йорты
yetki *и.* вәкаләт, хокуклылык, вәкаләтлелек, компетенция
yetkin *с.* камил; мөкәммәл

yetmiş *сан.* җитмеш
yetmişer *сан.* җитмешәр
yetmişinci *сан.* җитмешенче
yığmak *ф.* җыю; туплау
yığdırmak *ф.* җыйдыру
yığılmak *ф.* 1) җыелу, туплану; 2) егылу
yığılı *с.* җыелган
yığın *и.* өем
yıkmak *ф.* 1) җимерү, вату; 2) кырынайту; 3) түнтәрү, аудару
yıkamak *ф.* юу
yıkanmak *ф.* 1) юылу; 2) юыну
yıkayıcı *и.* юучы
yıkı *и.* хәрабә, җимерекләр
yıkıcı *и.* җимерүче, ватучы
yıkık *с.* җимерек
yıkılmak *ф.* 1) егылу; аву; 2) ишелү, җимерелү
yıkım *и.* 1) бәла-каза, каза; катастрофа; 2) банкротлык, бөлү; яфрак астына керү
yıl *и.* ел; *yıllarca* еллар буе, елларча; *artık yıl* кәбисә ел; *doğum yılı* туган елы; *öğretim yılı* уку елы
yılan *и.* 1) елан; *boğa yılanı* буар елан; 2) *күч.* мәкерле, әшәке кеше
yılbaşı *и.* Яңа ел
yıldıramak *ф.* ялтырау; елтырау
yıldırak *и.* яшен, елдырым
yıldırım *ф.* яшен; елдырым; *yıldırım düştü яшен* сукты
yıldırma *и.* террор
yıldız *и. төрле мәгъ.* йолдыз □ **yıldız akmak** (**kaymak**, **uçmak**) йолдыз атылу; **yıldız yağmuru** йолдыз яңгыры; **yıldız yeli** төньяк җиле ◊ **yıldız barışıklığı** янәшә тыныч яшәү; **yıldızı dişi** сөйкемле сөяге булган; **yıldızı düşük** бәхетсез, тәләйсез; **yıldızı sönmek** популярлыгын югалту
yıldızlamak *ф.* (*төнлә кук аязып*) йолдызлар күренә башлау
yıldızlı *с.* йолдызлы
yılgı *и.* көчле курку
yılgın *с.* бик нык курыккан
yılışmak *ф.* ялагайлану, куштанлану
yılışık *с.* 1) ябышкак; ябышучан; сыланучан; 2) бәйләнчек
yılkı *и.* ат өере
yıllamak *ф.* бер ел яшәү, бер ел тору
yıllık 1. *и.* еллык; еллык хезмәт хакы. 2. *с.* бер еллык; *yıllık kuzu бер* еллык бәрән
yılmaz *с.* курыкмас, кыю
yıprak *с.* искергән; таушалган, иске
yıpranmak *ф.* 1) тузу (*мәс., кием тур.*), искерү (*машина һ. б.*); 2) *күч.* какшау; таушалу (*кеше саулыгы һ. б. ш.*)
yırtmak *ф.* ерту
yırtıcı *с.* ерткыч; *yırtıcı hayvan* ерткыч хайван
yırtık *с.* ертык
yırtılmak *ф.* ертылу
yiğit 1. *и.* егет. 2. *с.* кыю, батыр
yiğitçe *рәв.* егетләрчә, батырларча
yiğitlik *и.* егетлек, кыюлык
yirmi *сан.* егерме
yirmilik *и.* егермелек
yirminci *сан.* егерменче

yirmişer *сан.* егермешәр
yitmek *ф.* 1) югалу; 2) исраф булу
yitik *с.* югалган
yitirmek *ф.* югалту
yiyecek *и.* ашамлык, азык
yiyici *с. и.* 1) ашаучы; 2) *күч.* ришвәтче ◊ **hazır yiyici** әрәмтамак
yiyim *и.* ашау, туклану уо *хаб. суз.* юк! кирәкмәс!
yogi *и.* йог
yoğalmak *ф.* югалу, юк булу
yoğaltmak *ф.* тоту, сарыф итү, куллану
yoğun *с.* куе, тыгыз
yoğurmak *ф.* изү (*камырны*)
yoğurt *и.* йогурт; катыкның бер төре (йогырт)
yoğurtlu *с.* йогуртлы, катыклы
yok *хәб. сүз.* юк; булмау; *parası yok* акчасы юк ◊ **yokuna** бушка, бик арзанга; *hiç yoktan* бер дә юктан
yoklamak *ф.* 1) тикшерү, карау; тентү; 2) белергә тырышу
yoklama *и.* тикшерү
yokluk *и.* 1) юклык, булмаганлык; 2) *күч.* фәкыйрьлек
yoksa терк. юкса, югыйсә
yoksul *и.* юксыл, фәкыйрь, ярлы
yoksullaşmak *ф.* фәкыйрьләнү, ярлылану; хәерчеләнү
yoksulluk *и.* фәкыйрьлек, ярлылык
yoksun *с.* мәхрүм
yoksunmak *ф.* мәхрүм булу
yokuş *и.* калкулык, үр
yol *и.* 1) юл; *yol inşa etmek* юл төзү; *yol tamiratı* юлны ремонтлау; *doğru yol* туры юл; *dört yol* юл чаты; *hava yolu* һава юлы; *su yolu* су юлы; 2) юл, чара; *bu işi yapmanın bir yolu vardır* бу эшне башкаруның бер юлы бар; 3) буй (*тукымада*); 4) мәртәбә, юл; *bu yolda* бу юлы ◊ **yol kesme** юл кисү, юлда талау; **yol vermek** юл бирү; **allah yolunu açık etsin**! хәерле юл!
yolmak *ф.* 1) йолку; 2) *күч.* алдап акчасын алу
yolak *и.* сукмак
yolcu *и.* юлчы; пассажир
yolculuk *и.* сәяхәт; юлга чыгу
yoldaş *и.* юлдаш
yollamak *ф.* җибәрү; юллау
yollu *с.* 1) буйлы (*тукыма*); 2) тиз йөрешле
yolluk *и.* юллык, юллык чыгым
yolsuz *с.* 1) юлсыз; 2) акрын йөрешле
yolsuzluk *и.* 1) юлсызлык; 2) *күч.* законсызлык
yoluk *с.* йолкынган
yolunmak *ф.* йолкыну
yom *и.* 1) бәхет; иминлек; 2) яхшы хәбәр
yonmak *ф.* юну; ышкылау
yonga *и.* юнгы, йомычка
yontmak *ф.* юну, ышкылау
yont kuşu *и. зоол.* сиртмәкойрык
yontu *и.* һәйкәл
yontucu *и.* һәйкәлче
yormak I *ф.* арыту; алҗыту
yormak II *ф.* юрау, дип санау

yordam *и.* өлгерлек, елгырлык
yordamlı *с.* 1) өлгер, елгыр; 2) тәҗрибәле
yordamsız *с.* 1) җебегән; 2) тәҗрибәсез
yorgalamak *ф.* юргалау
yorgan *и.* юрган; *yorgan çarşafi* юрган тышлыгы ◊ **yorgan döşek yatmak** бик нык авырып яту
yorgancı *и.* юрганчы, юрган сыручы һәм сатучы
yorganlık *и.* юрганлык
yorgun *с.* арыган, хәлсезләнгән, алҗыган
yorgunluk *и.* арыганлык
yorulmak *ф.* ару, алҗу
yorum *и.* аңлатма
yorumcu *и.* аңлатучы, комментатор
yorumlamak *ф.* аңлату, комментарийлар бирү
yosun *и.* мүк
yosunlanmak *ф.* мүкләнү
yoz *и.* сөрелмәгән җир; *yoz toprak* чирәм җир
yön *и.* 1) юнь, тараф; 2) юнәлеш ◊ **yönden** (*билгеле бер*) тарафтан
yönelmek *ф.* юнәлү
yöneltmek *ф.* 1) юнәлтү; 2) идарә итү
yönerge *и.* күрсәтмә, директива
yönetmek *ф.* идарә итү, җитәкләү
yönetim *и.* идарә, җитәкчелек
yönetmen *и.* җитәкче, идарәче; мөдир
yönetmenlik *и.* җитәкчелек, идарә, мөдирлек
yöntem *и.* метод, алым, ысул
yöntembilim *и.* методология
yöre *и.* 1) тараф; 2) мохит; 3) тирә-юнь
yudum *и.* йотым
yufka 1. *и.* җәйгән камыр; җәймә. 2. *с. күч.* юка, тиз ватылучан
yugoslav *и.* югослав
yugoslavyalı *и.* Югославияле
yukarı *с.* югары
yukarıda *рәв.* югарыда
yukarıdaki *с.* югарыдагы
yukarıdan *рәв.* югарыдан
yulaf солы; *yulaf unu* солы оны
yular *и.* нукта
yummak *ф.* йому; *gözünü yummak* күзен йому
yumak *и.* йомгак (*мәс., җепнеке*)
yumru 1 *и.* кабарык, *шеш.* 2. *с.* йомры
yumruk *и.*) йодрык; *yumruk kadar* йодрык кадәр; 2) тондыру (*йодрык белән*); ◊ **yumruk oyunu** бокс □ **yumruk oyuncusu** боксер
yumruklaşmak *ф.* йодрык белән сугышу
yumuk *с.* йомык, йомылган
yumulmak *ф.* йомылу
yumurta *и.* 1) йомырка; *yumurta akı* йомырка агы; *yumurta kabuğu* йомырка кабыгы; *yumurta sarısı* йомырка сарысы; 2) уылдык
yumurtlamak *ф.* 1) йомырка салу; 2) уылдык чәчү; 3) *күч.* буш сүз сөйләү
yumuşak *с.* йомшак; *yumuşak ağaç* йомшак агач ◊ **yumuşak adam** йомшак кеше; **yumuşak muamele** йомшак мөгамәлә
yumuşaklık *и.* йомшаклык

yumuşatmak *ф.* йомшату, йомшарту, йомшакландыру
yunan *и.* юнан, грек
yunanca *и.* 1. грек теле. 2. *рәв.* грек телендә, грекча
yunanlı *и.* грек; Грециядә яшәүче
yunus balığı *и.* дельфин
yurt *и.* 1) ил; 2) ватан, туган ил; 3) йорт; 4) тулай торак □ **öğrenci yurdu** интернат, **sağlık yurdu** шифаханә
yurtsever *и.* ватанпәрвәр, патриот, ватансөяр
yurttaş *и.* 1) ватандаш; 2) гражданин
yutmak *ф.* 1) йоту; 2) *күч.* йоту, үткәреп җибәрү; түзеп калу; 3) ышану; 4) оту (*уеңда*)
yutak *и.* йоткылык
yutkunmak ф. 1) йоту; 2) *күч.* чәчәү; *тынып* калу (*сөйләргәме, сөйләмәскәме дил тору*)
yuva *и.* 1) оя; *yuva yapmak* оя кору; 2) йорт; 3) балалар бакчасы; 4) *күч.* оя; *hırsız yuvası* караклар оясы ◊ **yuva kurmak** гаилә кору; **yuvayı yapan dişi kuştur** гаилә учагын саклаучы -хатын-кыз
yuvalamak *ф.* оя кору, оя ясау
yuvarlamak *ф.* 1) тәгәрәтү; 2) төрү; 3) егу; түнтәрү
yuvarlak 1. *и.* шар. 2. *с.* түгәрәк ◊ **yuvarlak sesler** *гр.* ирен авазлары
yuvarlatmak *ф.* 1) тәгәрәттерү; 2) түгәрәкләү
yüce *с.* 1) биек, югары; 2) күтәренке; бөек
yücelenmek *ф.* күтәрелү
yük *и.* йөк; авырлык; *vapur yüğünü boşalttı* пароход йөген бушатты; 2) вазыйфә, йөк; мәшәкать
yükçü *и.* йөкче
yüklemek *ф.* 1) төяү, йөк төяү; 2) *күч.* йөкләү, вазыйфа йөкләү
yüklem *и. гр.* хәбәр
yükletmek *ф.* төятү
yükleyici *и.* төяүче
yüklü *с.* 1) йөк төялгән, йөге булган, йөкле; 2) йөкле (*хатын*)
yüksek *с.* 1) биек; *yüksek dağ* биек тау; 2) югары (*тавыш*); 3) югары; *yüksek öğretim* югары белем; 4) абруйлы; камил □ **yüksek fiyat** югары бәя ◊ **yüksekten atmak** мактану
yükseklik *и.* 1) калкулык, биеклек, кашлак; 2) биеклек; *tepe yüksekliği* тау биеклеге
yüksekokul *и.* югары уку йорты, югары мәктәп
yükseköğrenim *и.* югары белем алу
yükseköğretim *и.* югары белем бирү
yükselmek *ф.* 1) күтәрелү, үсү, арту; 2) көчәю
yükseltmek *ф.* 1) күтәрү, арттыру; 2) *күч.* артык мактау, күккә күтәрү
yüksük *и.* уймак
yüksünmek *ф.* авыр йөк дип санау
yüküm *и.* 1) йөкләмә; 2) вазыйфә, бурыч
yülgü *и.* кырыну пәкесе
yün *и.* йон; *yün çorap* йон оек
yürek *и.* 1) йөрәк; 2) йөрәк, күңел; *yürekten teşekkür etmek* чын күңелдән рәхмәт әйтү; 3) кыюлык, батырлык, йөрәклелек ◊ **yürek kopmak** йөрәк кузгалу; **yürek sızlamak** йөрәк сызлау
yüreklenmek *ф.* рухлану; дәртләнү
yüreklendirmek *ф.* рухландыру, дәртләндерү
yürekli *с.* 1) кыю, батыр; 2) кызганучан
yüreklilik *и.* кыюлык, батырлык

yüreksiz *с.* куркак, кыюсыз
yürümek ф. 1) йөрү, атлау, хәрәкәт итү, бару; 2) гамәлгә керү (*мәс., закон*); 3) йөри башлау (*бала тур.*); 4) йөреп килү; 5) ашыгу; 6) җайлану (*эшләр*); 7) барып җитү
yürünmek *ф.* йөренү
yürürlük *и.* яшәеш, кулланылыш
yürütmek *ф.* 1) хәрәкәткә китерү, йөртү; 2) куллану; башкару; 3) әйтү
yürüyüş *и.* йөреш
yüz I *сан.* йөз; *yüz yıl* йөз ел; *yüzde yüz* йөз процент
yüz *и.* 1) йөз; бит; *genç yüz* яшь йөз; 2) өс(т), өслек, йөз; мәйдан; *deniz yüzü* диңгез өсте; 3) фасад, йөз ягы, бит; *binanın yüzü* бинаның йөзе; 4) мендәр (юрган) тышы; 5) яхшы мөнәсәбәт, яхшы йөз; *yüz göstermek* яхшы йөз күрсәтү; ◊ **yüzünden kan damlıyor** чиртсәң каны чыгарга тора; **yüz akı** намус
yüzmek I *ф.* йөзү, йөзеп йөрү
yüzmek II *ф.* тиресен тунау
yüzbaşı *и.* капитан
yüzde *и.* процент; *yüzde altı* алты процент
yüzdürmek I *ф.* йөздерү
yüzdürmek II *ф.* (тире) тунату
yüzey *и.* өслек; яссылык
yüzgeç *и.* 1) яхшы йөзүче (*кеше*); 2) канат (*балыкның*)
yüzkarası *и.* хурлык, мәсхәрә
yüzlemek *ф.* битәрләү, әрләү
yüzleşmek *ф.* 1) бәхәсләшү; 2) кара-каршы очрашу
yüzleştirmek *ф.* кара-каршы очраштыру
yüzlük *и.* йөзлек (*акча*)
yüzme *с.* йөзү...-ы; йөзә торган, йөзү өчен; *yüzme havuzu* йөзү бассейны
yüz numara *и.* туалет
yüzölçümü *и.* өслек мәйданы
yüzsuyu *и.* йөз суы; намус
yüzsüz *с.* оятсыз
yüzsüzleşmek *ф.* оятсызлану; оятсызга әйләнү
yüzücü *и.* 1) йөзүче; 2) (тире) тунаучы
yüzük *и.* балдак, йөзек; *nişan yüzüğü* никахлашу балдагы
yüzükoyun *рәв.* Йөзтүбән
yüzük parmağı *и.* атсыз бармак
yüzüncü *сан.*йөзенче
yüzünden *бәйл.* сәбәпле, аркасында
yüzyıl *и.* йөзьеллык, гасыр; *yarım yüzyıl* ярты гасыр
yüzyıllık *с.* йөзьеллык; *yüzyıllık çam* йөзьеллык нарат

Z

zaaf *и.* көчсезлек; түземсезлек
zabıt *и.* 1) (*җыелыш, утырыш һ. б.ларда язылган*) беркетмә; 2) тартып алу, ия булу □ **zabıt tutmak** беркетмә язу
zabıta *и.* полиция; *ahlâk zabıtası* әхлак полициясе; *zabıta müdürü* полиция мөдире
zaç *и.* купорос □ **zaç yağı** күкерт
zafer *и.* җиңү; уңыш □ **zafer almak** (**kazanmak**, **bulmak**) җиңү, җиңүгә ирешү
zafiyet *и.* көчсезлек, арыклык
zağ *и.* кылчык (*металлда*)
zağanos *и. зоол.* каракош
zağar *и.* ау эте (*бер төре*)

zahir *и.* кыяфәт, тышкы күренеш □ **zahir olmak** ачылу, билгеле булу, килеп чыгу
zahire *и.* ашлык запасы; *zahire ambarı* ашлык келәте; *zahire borsası* иген биржасы
zahirî *с.* 1) тышкы; күренеп торган; 2) ясалма; чын күңелдән булмаган, уйлап чыгарылган
zahmet *и.* 1) авырлык, мәшәкать; 2) борчылу, кайгырту; *zahmet çektirmek* мәшәкатьләү, авырлык китерү; борчу; *size zahmet verdim* сезне мәшәкатьләдем □ **zahmet etmek** 1) борчылу, мәшәкатьләнү; 2) чыгымлану, чыгым чыгару; **zahmet etmeyiniz**! борчылмагыз!; **zahmet olmazsa** әгәр авыр булмаса
zahmetli *с.* авыр, мәшәкатьле; ялыктыргыч; *zahmetti iş* мәшәкатьле эш
zahmetsiz *с.* авыр булмаган, җиңел; көч сарыф итми торган
zalim *с.* залим, явыз; *zalim adam* явыз кеше
zalimlik *и.* залимлык, явызлык; гаделсезлек
zam *и.* 1) өстәмә, өстәү, арттыру; 2) кушу, китереп өстәү □ **zam yapmak** өстәү, арттыру
zaman *и.* 1) вакыт; *zamanında* вакытында; *zaman farkı* вакыт аермасы; *zaman geçirmek* вакыт үткәрү; *zaman kazanmak* вакытны оту; *aynı zamanda* бер үк вакытта; *uyku zamanı mm* вакыты; *uzun zaman* озак вакыт; *iş zamanı* эш вакыты; 2) чор, заман; *imparatorluk zamanında* императорлык заманында; 3)чор, вакыт; *çocukluk zamanı* балалык чоры; 4) *гр.* заман; *fiil zamanları* фигыль заманнары □ **az zaman sonra** тиздән; **bir zaman** бер заман, бервакыт; **ne zaman** кайчан; **ne** (**kadar**) **zamandan biri** кайчаннан бирле, кайвакыттан бирле
zamane *и.* замана; *zamane çocukları* замана балалары
zamanlı □ вакытлы □ **zamanlı zamansız** вакытлы-вакытсыз
zamansız *с.* вакытсыз **zambak** *и. бот* зәмбәкъ, лилия
zamir *и. гр.* алмашлык □ **soru zamiri** сорау алмашлыгы; **şahıs zamiri** зат алмашлыгы
zamk *и.* җилем, келәй
zamklamak *ф.* җилемләү, җилем белән ябыштыру
zamklı *с.* җилемле, җилемләнгән
zampara *и.* хатын-кыз белән күп чуалучы ир
zamparalık *и.* бозыклык, азгынлык
zan и. фикер; ышаныч; (*дин*) уйлау
zanaat *и.* һөнәр
zanaatçı *и.* һөнәрче
zangırdamak ф. теш тешкә тию (*туңудан һ. б. ш.*)
zannetmak ф. (*дин*) уйлау, (*дин*) санау; *böyle zannederim* мин шулай дип саныйм
zaptetmak *ф.* 1) яулап алу, басып алу; 2) конфискацияләү; *malını zaptetmişler* товарын конфискацияләгәннәр; 3) истә калдыру, үзләштерү (*дәресне*); 4) язып алу
zar *и.* 1) юка кабык (*мәс., суган кабыгы*); 2) *анат.* пәрдә; *göğüs zarı* күкрәк пәрдәсе
zarafet *и.* нәфислек, элегантлык
zarar *и.* зарар, зыян; *zararı dokunmak* зарары тию; *zarar görmek* зарар күрү; *zarar verici* зарар китерүче; *zarar vermek* зарар итү; *zarar yapmak* зарар итү, зарар китерү; *maddi zarar* матди зарар
zararcı *и.* зарар итүче
zararlı *с.* зарарлы; *zararlı böcekler* зарарлы бөҗәкләр; *zararlı iş* зарарлы эш
zararlılık *и.* зарарлылык, зыянлылык
zararsız *с.* 1) зарарсыз; 2) *күч.* яралык, начар түгел
zarf *и.* 1) футляр, сүрү; 2) конверт; 3) *гр.* рәвеш; *soru zarfı* сорау рәвеше; *yer zarfı* урын рәвеше; *zaman zarfı* вакыт рәвеше

zarflamak *ф.* конвертка салу; конвертны ябыштыру
zarif *с.* 1) нәфис, сылу, элегант; *zarif kadın* сылу хатын; 2) үткен акыллы; 3) нечкә зәвыклы
zarp *и.* 1) бәрү, сугу; 2) көчле тәэсир
zaruret *и.* 1) зарурлык, зарурият, мәҗбүрият; кирәклек; *zaruretindeyim* мин мәҗбүрмен; *zaruret halinde* кирәк булганда; 2) мохтаҗлык; хәерчелек; кыенлык
zaruri *с.* зарурый, кирәкле, мәҗбүри; *zaruri masraflar* мәҗбүри чыгымнар; *zaruri olarak* мәҗбүри буларак
zat *и.* зат, шәхес
zaten *рәв.* 1) асылда, чынында; 2) гомумән, бөтенләй; *kardeşini zaten bilmiyordu* туганын бөтенләй белми иде
zatülcenp *и. мед.* плеврит; үпкә пәрдәсенең ялкынсынуы
zatürree *и. мед.* үпкә ялкынсыну, пневмония
zavallı *с.* мескен, бичара; *zavallı çocuk* мескен бала
zayıf *с.* 1) ябык, арык; 2) көчсез, көчсезләнгән, зәгыйфь
zayıflamak *ф.* 1) ябыгу, арыклану; 2) көчсезләнү; зәгыйфьләнү
zayıflatmak *ф.* 1) ябыктыру, арыкландыру; 2) көчсезләндерү, зәгыйфьләндерү
zayıflık *и.* 1) ябыклык, арыклык; 2) көчсезлек, зәгыйфьлек
zayi *и.* югалту; зая итү □ **zayi etmek** зая итү, югалту; **zayi olmak** югалу
zebani *и.* зобаный
zebercet *и.* зөбәрҗәт
zedelemak *ф.* зарарлау; зарар итү; зарар китерү
zedelenmak *ф.* 1) зарарлану; 2) бозылу; 3) зарар күрү
zehir *и.* агу, зәһәр ◊ **zehir gibi** бик ачы
zehirlemak *ф.* агулау; агу эчерү
zehirlenmak *ф.* агулану, агу эчү
zehirli *с.* агулы, зәһәрле; *zehirli gazlar* агулы газлар
zehirsiz *с.* агусыз, агулы булмаган; *zehirsiz mantar* агусыз гөмбә
zekât *и.* зәкят (*керемнең кырыгынчы өлешеннән бирелә торган хәер*)
zeki *с.* зирәк, акыллы
zelzele *и.* җир тетрәү, зилзилә
zemberek *и.* пружина
zembil *и.* камыштан үрелгән сумка (кәрзин)
zemheri *и.* зәмһәрир, каты суык
zemin *и.* 1) туфрак, җир; 2) җирлек, нигез, фон; *zemini siyah bir basma* кара җирлекле тукыма; 3) *күч.* нигез; *bir anlaşma zemini bulunamadı* килешү өчен бер нигез табылмады
zenci *и.* негр
zengin *и.* бай; мул; *zengin bir adam* бай кеше; *zengin bir tabiat* бай табигать; *zengin mal çeşidi* товарларның бай ассортименты
zenginlik *и.* байлык; *ruh zenginliği* рухи байлык; *tabii zenginlikler* табигый байлыклар
zerdeva *и. зоол.* сусар
zerre *и.* кечкенә кисәкчә, тамчы; бөртек □ **zerre kadar** бик аз (*дәрәҗәдә*)
zerzevat *и.* яшелчә
zerzevatçı *и.* яшелчәче
zevk *и.* 1) зәвык; *zevk meselesi* зәвык мәсьәләсе; 2) ләззәт; күңел ачу; *zevk için* күңел ачу өчен; *zevkine gitmek* ошау
zevklenmak *ф.* ләззәтләнү, тәм табу
zevkli *с.* зәвыклы
zevksiz *с.* зәвыксыз

zeyrek *с.* зирәк, аңлы, зиһенле
zeyreklik *и.* зирәклелек, аңлылык, зиһенлелек
zeytin *и.* зәйтүн; *zeytin ağacı* зәйтүн агачы
zeytinci *и.* зәйтүнче (*үстерүче яки сатучы*)
zeytinlik *и.* зәйтүнлек, зәйтүн агачлары үскән урын
zeytinyağı *и.* зәйтүн мае
zıh *и.* кайма, кант; бау
zıkkım *и.* агу, агулы матдә
zımba *и.* 1) тишкеч; борау; 2) тишү
zımbalamak *ф.* 1) бораулап тишү, тишү; 2) билетны тиштерү, компостерлау
zımpara *и.* наждак; *zımpara kâğıdı* наждак кәгазе
zındık *с.* алласыз, аллага ышанмаучы
zıngıldamak *ф.* зыңгылдау
zıngırdamak *ф.* 1) калтырау, теш тешкә тию; 2) зыңгылдау (*мәс., пыяла*)
zıplamak *ф.* сикерү, сикерә-сикерә бару (тәгәрәү)
zıppadak *рәв.* кинәт, кинәттән; *zıppadak içeri giriverdi* кинәттән эчкә кереп китте
zırh 1) броня; 2) *иск.* көбә, көбә кием
ztrılda(n)mak *ф.* акыру, бакыру, кычкыру; чыелдау
zırıltı *и.* кычкырыш, тавыш, гауга
zırlak *с.* кычкырынучан; тавышлы
zırnık *и.* мышьяк
zırva *и.* буш сүзләр, лыгырдау, лаф
zırvalamak *ф.* буш сүзләр сөйләү, лаф ору, лыгырдау
zıt *и.* 1) капма-каршы булу; капма-каршылык; 2) каршылык, каршы булу; каршы сүз әйтү ◊ **zıddı olmak** канәгать булмау; **zıddına basmak** ачуландыру
zıtlaşmak *ф.* (*бер-береңә*) капма-каршы тору, каршылык күрсәтү
zıvana *и.* мөштек
zıvanalı *с.* мөштекле □ **zıvanalı sigara** папирос
zıvanasız *с.* мөштексез □ **zıvanasız sigara** сигарет
zıypak *с.* тайгак
zibidi *с.* килбәтсез
zifaf *и.* зөфаф; *zifaf gecesi* зөфаф киче
zift *и.* сумала; кара сагыз
ziftlemek сумалалау
zihin *и.* зиһен, акыл, аңлау; *zihinli* ачык зиһенле; *zihinim durdu* шаккаттым, нык гаҗәпләндем; *zihin hesabi* телдән санау; *zihinde tutmak* истә тоту ◊ zihnini **toplamak** акылны җыю; **zihinden çıkarmak** зиһеннән чыгару; оныту; **zihinden çıkmak** онытылу, истән чыгу
zikir *и.* искә төшү, искә төшерү
zikretmek *ф.* искә төшерү, билгеләп китү
zikzak *и.* зигзаг; *zikzak yol* зигзаг юл
zil *и.* кыңгырау; *zile basmak* шалтырату; *zil düğmesi* кыңгырау төймәсе; *elektrikli zil* электр кыңгыравы ◊ **karnım zil çalıyor** карным ачты
zillet *и.* хурлык, кимсетелү; түбәнсетелү
zilli *с.* 1) кыңгыраулы; 2) *күч.* әдәпсез (*хатын*)
zilsiz *с.* кыңгыраусыз
zilyet *и.* ия, хуҗа; биләүче
zilyetlik *и.* ия булу, биләү
zimmet *и.* (*бер сәүдә оешмасының*) бөтен бурычлары
zina *и.* зина, җенси азгынлык
zincir *и.*1) зынҗыр; муен зыңҗыры; 2) чылбыр; 3) *иск.* богау
zincirlemek *ф.* 1) чылбыр белән бәйләү; 2) *күч.* бер-бер артлы килү

zindan *и.* төрмә; *zindana atmak* төрмәгә утырту
zindancı *и.* төрмәче, зиндан каравылчысы
zinde *с.* 1) көчле, каты, куәтле; 2) җанлы, тере, дәртле
zira I *бәйл.* чөнки
zira II *и.* (*терсәктән урта бармак очына кадәрге*) озынлык үлчәү берәмлеге
ziraat *и.* игенчелек, авыл хуҗалыгы; *ziraat bankası* авып хуҗалыгы банкы; *ziraat sergisi* авыл хуҗалыгы күргәзмәсе
ziraatçı *и.* игенче
zirve *төрле мәгъ.* иң югарыгы нокта
ziyade *с.* күбрәк, зуррак, артыграк; *yarım saatten ziyade sürdü* ярты сәгатьтән артык дәвам итте
ziyadelemek, **ziyadeleşmek** *ф.* арту, күбәю
ziyafet *и.* 1) сый, сыйлау; 2) ашау-эчүле мәҗлес □ **ziyafet vermek** мәҗлес оештыру, кунаклар чакыру
ziyan *и.* зыян, зарар; *ziyanına* зыянга; *ziyan çekmek / görmek* зыян күрү ◊ **ziyanı yok**! зарар юк!
ziyanlı *с.* зыянлы, зарарлы
ziyansız *с.* 1) зыянсыз, зарарсыз; 2) *сөйл.* начар түгел, яхшы дип әйтерлек
ziyaret *и.* күрешергә (хәл белергә) килү
zoka *и.* зур кармак (*балыкка охшатып ясалган*)
zoolog *и.* зоолог, хайваннар белгече
zooloji *и.* зоология, хайваннар белеме
zor *и.* 1) мәҗбүрилек; *zorunda kalmak* мәҗбүр булу; 2) кыенлык, авырлык; газап; *zorun ne?* нәрсәдән газапланасың?. 2. *с.* 1) авыр, кыен, газаплы; *zor bir çalışma* авыр эш. 3. *рәв.* көч кулланып □ **zor alım** конфискация
zorba *и.* тиран, деспот; изүче, көчләүче
zorlamak *ф.* мәҗбүр итү, басым ясау
zorlaşmak *ф.* кыенлашу, авырлашу
zorlu *с.* 1) көчле, куәтле; каты; *zorlu bir yağmur* көчле яңгыр; 2) кыен, авыр
zorluk *и.* авырлык, кыенлык □ **zorluk çekmek** кыенлык кичерү
zorunlu *с.* мәҗбүри, кирәкле; котылгысыз □ **zorunlu kılmak** мәҗбүр итү
zorunluk *и.* мәҗбүрлек, кирәклек; котылгысызлык
zulüm *и.* золым, изү; гаделсезлек
zurna *и.* сорнай
zurnacı *и.* сорнайчы
züğürt *и.* акчасыз, ярлы □ **züğürt olmak** акчага мохтаж булу
züğürtlemek *ф.* акчасыз калу, ярлылану; бөлү
züğürtlük *и.* акчасызлык, ярлылык, мохтаҗлык
Zühal *и. астр.* Сатурн
Zühre *и. астр.* Зөһрә (Чулпан) йолдызы
zührevî *с.* венерик (*авыру*)
zükâm *и.* томау, салкын тию
zükâmlı *с.* салкын тигән, томаулы
zülüf *и.* чәч бөтеркәсе
zümre *и.* 1) төркем; 2) төр, төркем, катлау
zümrüt *и.* зөбәрҗәт
züppe *с.* франт, кием калыбыдай
zürafa *и.* жираф
zürriyet *и.* токым, бала-чага; *zürriyetsiz bir aile* бала-чагалары юк бер гаилә